

ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

# МӘҮЛА КОЛЫЙ ИҖАТЫ

## яңа табышлар

«МИЛЛИ КИТАП»

«ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ»

# МӘҮЛА КОЛЫЙ ИҖАТЫ

яңа табышлар

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2025

**УДК 821.512.14-1+930.2:821.512.14**
**ББК 84 (2=63)-5+63.212**
**К52**

*Төзүчесе, басмага әзерләүче*
*һәм махсус мәкаләләр авторы –*
*археограф, текстолог*
*Раиф Мәрданов*

К52 **Мәүла Колый иҗаты:** яңа табышлар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2025. – 216 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 36 нчы китап).

Китапта XVII гасыр татар шагыйре Мәүла Колыйның моңарчы билгесез булган бер поэмасы һәм бер хикмәте текстлары, электән билгеле әсәрләреннән 17 хикмәт-шигыренең әлегәчә фәнни әйләнешкә кермәгән 11 кульязмадан алынган вариантлары урын алды.

Мәүла Колыйның иҗади мирасы моңарчы 3700-дән артык яки 3800 шигъри юлга якын дип йөртелгән булса, аның хәзерге вакытка 4598 юлны тәшкил итүе ачыкланды.

Китапта М.Колыйныкы булулары ихтимал дип фаразланган өч хикмәт тексты да тәкъдим ителде.

ISBN 978–5–88473–112–7

**УДК 821.512.14-1+930.2:821.512.14**
**ББК 84 (2=63)-5+63.212**

© Мәрданов Р.Ф., 2025
© «Милли китап» нәшрияты, 2025

# БАЙ ИҖАТ ЯДКЯРЛӘРЕ

XVII гасырның икенче яртысында яшәгән һәм әсәрләр иҗат иткән күренекле татар шагыйре Мәүла Колыйның исеме әдәбият тарихында киң билгеле. Ул Әхмәт Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Кол Гали, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр кебек фикер ияләренең бай иҗатлары рухын дәвам итеп, үз шигъри дөньясын тудырган олы әдип.

Мәүла Колыйның үзе һәм иҗаты турында «Татар энциклопедиясе»ндә бирелгән мәгълүматта шагыйрьнең 1630 нчы елларда дөньяга килеп, XVIII гасыр башларына хәтле гомер иткәнлеге әйтелгән, галимнәр тарафыннан ачыкланган биографиясе тәкъдим ителгән[1]. Иҗаты гомуми бәяләнеп болай дип язылган: «Мәүла Колый – төрки суфи шагыйрьләр Ә.Ясәви һәм С.Бакыргани традицияләренең дәвамчысы. М.Колыйның бөтен иҗаты аларның идеяләре белән сугарылган. 20 йөз ахырында табылган «Береккәннәр сыйфаты» һәм «Хәләл нәфкъә эстәгәнләр сыйфаты» («Хәләл ризык эстәүчеләр») поэмаларының авторы. Әсәрләрнең икесе дә безнең көннәргә тулаем рәвештә килеп җитмәгән: беренчесенең берничә бите юк, икенчесенең баштагы өлеше генә сакланган. Мәүла Колыйның 100 дән артык шигыре (3800 юлга якын) мәгълүм. Алар биш күчермәсе сакланган «Хикмәтләр» исемле кулъязма җыентыкка кертелгән (1669–70; бүтән мәгълүматларга караганда, 1678–79)... Әсәрләренең теле гади, аңлаешлы. М.Колыйның тормышы һәм иҗаты Ф.К.Туйкин, Г.Г.Сәгъди, К.С.Дәүләтшин, Ш.Ш.Абилов, Х.Й.Миңнегулов, М.И.Әхмәтҗанов һ.б. тарафыннан өйрәнелә»[2].

---

[1] Татар энциклопедиясе. Т. 4: М–П. – Казан: Татар энцикл. ин-ты, 2014. – Б. 102.
[2] Шунда ук. – Б. 102–103.

Татар әдәбияты тарихында Мәүла Колый иҗатын өйрәнә башлауга бер гасыр вакыт үтте. Аның әсәрләре табылу турында беренче мәртәбә «Кызыл Татарстан» газетасының 1926 елгы 9 апрель санында Фазыл Туйкә хәбәр итә[3]. Шул вакыттан алып Мәүла Колый шигырь-хикмәтләренең яңадан-яңа күчермәләре табыла һәм өйрәнелә. Шагыйрьнең иҗатын төрле елларда барлап, фәнни тикшерүгә Ф.Туйкә, Габдрахман Сәгъди, Латыйф Җәләй, Шакир Абилов, Хәй Хисмәтуллин, Камил Дәүләтшин, Гайсә Хөсәенов, Марсель Әхмәтҗанов, Мәсгуд Гайнетдин һ.б. галимнәр зур өлеш керттеләр, Мәүла Колыйның кем булуы турында фикер-фаразлар белдерделәр, әдипнең нәсел шәҗәрәсен һәм тормыш юлын ачыкларга омтылдылар[4].

Соңгы елларда Мәүла Колыйның иҗатын һәм тормыш юлын өйрәнүгә игътибар тагын да артты, аңа багышланган махсус конференция үткәрелеп, докладлар һәм чыгышлар җыентыгы дөнья күрде[5]. Анда М.Колый әсәрләренең өйрәнелү тарихы, авторның суфичылык карашлары, туган урыны һ.б. турында галимнәр тикшергән мәгълүматлар бар. Дөрес, кайбер авторлар гаять бай гөман-фантазияләрен эшкә җигеп, төрле тарихи шәхесләргә бәйле фактларны тоташтырырга омтылып, ышанычлы дәлилләр белән расланмый тор-

---

[3] Туйкә Ф. Борынгы Болгар шагыйре // Кызыл Татарстан. – 1926. – 9 апрель (№81); Ф.Туйкәнең бу мәкаләсе «Шәхесләребез» сериясендә нәшер ителгән китапта хәзерге татар язуына күчерелеп яңадан басылды (Бертуган Туйкиннар: тарихи-документаль җыентык / төз.-авт. Э.Ханнанова-Галимҗанова. – Казан: Рухият; Җыен, 2007. – Б. 169–170).

[4] Матбугатта чыккан мәкаләләрнең һәм китапларның исемлекләре әдип иҗатына багышланган хезмәтләрдә күп кабатлана. Кайберләре безнең шушы китапта да искә алынганлыктан, монда һәммәсен дә күрсәтмәдек.

[5] «Человек и природа в бассейне реки Меша и Пестречинском Заказанье в историческом развитии. Уроженец Пестречинской земли Мауля Колый: жизнь, деятельность, наследие и его вклад в духовно-культурную жизнь татарского народа («Вторые Пестречинские научно-краеведческие чтения»). Материалы Всероссийской научно-практической, историко-краеведческой конференции. – Серия «Восток – Запад: диалог культур и цивилизаций Евразии». Вып. 22. Под ред. А.А.Бурханова. – Казань: Отечество, 2022. – С. 282–350.

ган нәтиҗәләр ясаган. Мәсәлән, филология фәннәре докторы Фәрит Яхин татар тарихында һәм борынгы әдәбияттагы кеше исемнәрен кулланган һәм «бернинди дә Мәүла Колый да, Һәмдәми дә юк. Алар бары тик имза-псевдонимнар гына. Җитмәсә – бер үк кешенекеләр...» дип, М.Колыйны Себердәге Тубыл шәһәренә нисбәт иткән дә куйган. (Бу карашның нигезсез икәнлеге турында шушы китап ахырында тәкъдим ителгән махсус мәкаләдә аңлатылды).

Энциклопедиядә шагыйрьнең «20 йөз ахырында табылган» дип белдерелгән ике поэмасы төгәл билгеле вакытта – 1990 елның гыйнвар аенда ачыкланган иде. Татар шагыйре Мәүла Колыйның берсе 238 шигъри юлдан, икенчесе 66 шигъри юлдан торган поэмалары табылу турында киң җәмәгатьчелеккә беренче мәртәбә 1995 елның 14 декабрендә Татарстан Милли китапханәсенең 130 еллык юбилее уңаеннан оештырылган «Кулъязма һәм борынгы басма китапларны туплау, саклау һәм өйрәнү мәсьәләләре» фәнни-гамәли конференциясендә хәбәр ителде[6]. Текстлары беренче мәртәбә 1996 елда басылып чыкты[7]. Аларны галим Миркасыйм Госманов үз вакытында «әдәби ачыш» дип бәяләде[8].

Шагыйрьнең поэмалары теркәлгән кулъязманың кайда, кемдә сакланганлыгы һәм аларның эчтәлекләре, фәнни һәм әдәби әһәмиятләре турында «Казан утлары» журналында (1996 ел) язылганнан тыш, текстлары аерым китапларда ике

---

[6] Мәрданов Р. Татарстан Милли китапханәсендә археография эшләренең торышы һәм бурычлары // Кулъязма һәм борынгы басма китапларны туплау, саклау һәм өйрәнү мәсьәләләре. - Казан, 1995. - Б. 15–17.

[7] Мәрданов Р. «Гасый җафи Мәүла Колый сүзли, дуслар» // Казан утлары. – 1996. – №10. – Б. 160–171.

[8] Госманов М. Тагын бер әдәби ачыш // Казан утлары. – 1996. – №10. – Б. 159–160; Мәкалә шул ук исем белән М.Госмановның «Гасырдан – гасырга» исемле җыентыгына да (төз. Җ.Миңнуллин. Казан, 2004) кертелгән (403–405 битләр).

мәртәбә нәшер ителде[9]. Татарстан Республикасының Милли китапханәсендәге «Татар археографиясе» дип аталган үзенчәлекле басмалар сериясе 2008 елда нәкъ менә «Мәүла Колый поэмалары» җыентыгы белән башланып киткән иде. Анда поэмаларның текстлары язылган кульязманың факсимилесы да урын алды, әдипнең тормыш юлы турындагы фаразлар һәм фикерләр дә бәян ителде.

Татар энциклопедиясендә әйтелгәнчә, Мәүла Колыйның «Хикмәтләр» (шигырьләр) җыентыкларының биш кульязма күчермәсе фәндә билгеле иде. Алардагы хикмәт-шигырьләрнең күләме төрлечә: Ф.Туйкә тапканында бер йөзгә якын, 1974 елда Башкортстан галимнәре тарафыннан табылганында 75 хикмәт, Казанда 1969 елда ачыкланганында 13 хикмәт, Ленинград (С.-Петербург) кульязмасы буларак искә алына торганында ике хикмәт, Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәрендә Казан галимнәре табып алганында бер хикмәт тексты язылган[10]. Бу истәлекләр Казан, Уфа һәм С.-Петербург шәһәрләрендәге гыйльми оешмаларда саклана.

Болардан тыш, XX гасыр ахырына кадәр шагыйрьнең фәнгә бөтенләй билгесез әсәрләренең 1754 елгы күчермәләре табылганнан соң, хикмәтләр авторы сыйфатында мәгълүм булган Мәүла Колыйның поэма жанрында да иҗат иткәнлеге ачыкланды. Сүз уңаеннан искәртик, бу

[9] Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты». – Казан: «Милли китап» нәшр., 2008. – 88 б.; Шул ук. Икенче басма. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2011. – 88 б. Соңгысы 2022 елда, шагыйрьгә багышлап уздырылган фәнни-гамәли конференция уңаеннан, өстәмә тираж буларак, тагын басылып чыкты.

[10] Абилов Ш. Шагыйрьнең исеме Мәүла Колыймы әллә Меллаголмы // Совет әдәбияты. – 1958. – №11. – Б. 107–110; Абилов Ш. Мәүла Колый хикмәтләренең яңа кульязмасы // Казан утлары. – 1971. – №6. – Б. 147–151; Абилов Ш. Әдәби ядкярләрне эзләү юлында // Урта гасыр татар әдәбияты тарихыннан. – Казан: СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы, 1981. – Б. 38–48; Хусаинов Г. Новонайденные рукописные хикметы Мавля Кулуя // Письменные памятники Башкирии: историко-филологическое исследование. – Уфа: Башкирский филиал АН СССР, 1982. – С. 152–162; Дәүләтшин К.С. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый: уку кулланмасы. – Уфа: РИЦ Баш ГУ, 2010. – Б. 4–6.

кульязма – татар археографиясендә башлангыч адымнарын ясаган, Казан университетының 5 нче курс студенты – без фәкыйрегезнең иң мөһим табышларыннан әүвәлгесе иде. Шул рәвешле, XVII гасыр татар әдибе Мәүла Колый әсәрләре моңарчы 6 кульязмада билгеле булып килде. Шагыйрь хикмәтләренең аерым фрагментларын да истә тотып булса кирәк, К.Дәүләтшинның мәкаләсендә «...төрле археографик экспедицияләр һәм галимнәрнең шәхси эзләнүләре нәтиҗәсендә Мәүла Колый әсәрләре теркәлгән дистәләгән кульязма мәҗмуга табылды»[11] диелгән. («Дистәләгән» дигән сүзнең төгәлрәк мәгънәсен искә төшерсәк – ул бер дистә чамасы дигәнне белдерә).

Мәүла Колыйның моңарчы билгеле булган әсәрләре, әйтеп үтелгән поэмалары китабыннан тыш, хәзерге вакытка өч җыентыкта тупланган. Аларның берсе – әдәбият галиме Мәсгуд Гайнетдин тарафыннан хәзерләнеп, 2001 елда ике йөз данә тираж белән басылган «Хикмәтләр» китабы[12]. Анда Фазыл Туйкә тарафыннан табылып һәм күчереп алынган җыентыктагы хикмәтләрнең текстлары урын алган. Китапның кереш мәкаләсендә М.Колыйның биографиясенә һәм башка мәсьәләләргә карата үзенчәлекле фикерләр әйтелгән. Кызганыч ки, бу басмада орфографик хаталар бик күп. Мәсәлән, бер йөзгә якын хикмәт-шигырь башларында кабатланган «Хикмәте хәким рәхмәтуллаһи галәйһи» гыйбарәсендәге соңгы сүз һәр очракта да «гәләйһи» дип басылган. Югыйсә, бу сүздәге беренче хәреф калын әйтелешле «гъ» булып, аннан соң килгән «ә» хәрефе аны йомшак «г» итеп үзгәрткән. Моннан тыш, хәреф һәм язылыш хаталары, кульязмадан ялгыш күчерелгән очраклар шактый. Шуны-

[11] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Т. 2: XV–XVIII гасырлар / төз. Р.Рахмани. – Казан: Татар. китап нәшр., 2014. – Б. 242; Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 2 т.: XV–XVIII гасырлар / төз. һәм фәнни мөх. Г.Дәүләтшин. – Яңарт. 2 нче басма. – Казан: Татар. китап нәшр., 2022. – Б. 244.

[12] Колый М. Хикмәтләр / төз. М.Гайнетдин. – Казан: «Иман» нәшр., 2001. – 136 б.

сын да әйтергә кирәк, китап текстында автор хикмәтләре саннар белән билгеләнеп, 44 нче сан язылмыйча, 43 нчедән соң 45 нче хикмәт дип, ялгыш номерланган. Нәтиҗәдә, андагы текстлар саны 97 нче хикмәт белән тәмамлана. Ә беренче хикмәт сан белән белдерелмичә, «кереш» дип кенә тәгаенләнгән. Әлеге китапның 2022 елда дөнья күргән икенче басмасында[13] саннардагы ялгыш төзәтелгән, барлыгы 96 хикмәт дип бирелгән. Ләкин текст хаталарының күбесе әүвәлге китаптагыча калган.

Шагыйрьнең иҗатын өйрәнүгә иң зур өлеш керткән, 1971 елда фәнни кандидатлык диссертациясе язып яклаган галим Камил Дәүләтшин Мәүла Колый хикмәтләрен 2002 елда Стәрлетамак шәһәрендә 500 данә тираж белән чыгарган иде[14]. Студентлар өчен уку-методик кулланма итеп хәзерләнгән әлеге китапта Ф.Туйкә күчермәсендәге хикмәтләргә өстәп, М.Колый әсәрләренең башка бер – 1974 елда Башкортстанда табылган кулъязмасындагы, элегрәк билгесез булган тагын җиде хикмәте – барлыгы 104 хикмәт текстлары бирелгән. К.Дәүләтшин тарафыннан Уфа шәһәрендә 2010 елда бастырылган җыентык[15] – Мәүла Колый әсәрләренең моңарчы чыккан иң тулысы. Анысында хикмәтләрдән тыш, ике поэмасының 2008 елда дөнья күргән текстлары да тулаем күчереп бирелгән. Тик шунысы кызганыч, әлеге китап нибарысы бер йөз данә генә чыккан.

Дәүләтшин 2010 елгы китапка М.Колый иҗатын өйрәнүгә багышланган мәкаләләрен, әсәрләрдә очраган гарәп һәм фарсы сүзләренең, шулай ук архаик төрки гыйбарәләрнең сүзлеген биргән, шагыйрь хикмәтләренең Ф.Туйкә тапкан һәм Башкортстанда табылган кулъязмаларының факсими-

[13] Колый М. Хикмәтләр / төз. М.Гайнетдин. – Казан–Питрәч, 2022. – 128 б.

[14] Дәүләтшин К.С. Борынгы татар әдәби мирасы. Мәүла Колый хикмәтләре ..., 2002. – 192 б.

[15] Дәүләтшин К.С. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый: уку кулланмасы. – Уфа: РИЦ Баш ГУ, 2010. – 400 б.

леларын дә керткән. Әлеге басмада Ф.Туйкә кульязмасының факсимилесындагы хикмәтләр галимнәр тарафыннан саннар белән билгеләнеп, алар барысы 97 икәнлеге күренә. (Монда саннар нумерациясе беренче хикмәттән үк башланган). Һәрхәлдә, хикмәтләрнең номерлары белән текстлары 2001 елгы Казан басмасына тәңгәл килми. Уфа басмасында орфографик хаталар да аз түгел. Бу китапның өстәмә тиражы, «Казан-Питрәч» басмасы буларак, 2022 елда дөнья күрде. Репринт дип әйтерлек бу басмада кайбер хаталар төзәтелгән. Шуны да искәртик, Казан каласындагы төп китап йортларында – Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә һәм Казан федераль университеты китапханәсендә Мәүла Колыйның Уфада 2010 елда басылган җыентыгы бөтенләй юк, ә 2022 елда кабатлап нәшер ителгәне икешәр нөсхәдә генә.

Әйтелгән китапларның хәреф-имля хаталарыннан тыш, мәгънәви һәм текстологик аермалары да шактый. Галимнәрнең бер үк чыганактагы бер үк хикмәттәге бер үк сүзне төрлечә танып, китапларда да төрле рәвештә биргәнлекләре күренә. Мәсәлән, Мәүла Колый әсәрләренең иң башындагы беренче юлы 2001 елгы китапта (12 нче биттә) «Хәмде кылып Хак адын әйтмәклеккә» – дип, ә 2010 елгы басмада (46 нчы биттә) «Хәмед кыйлыб, Хакъ йадини айтмакълыкъка» рәвешендә бирелгән. Бу сүзләрнең һәммәсенә дә тукталмыйча, «адын» һәм «йадини» дигән сүзләрнең дөресе 2010 елгы китапта урын алган факсимиледә (295 биттә) «йадын» дип ачык язылганын күрәбез. Гомумән, әлеге ике китапның да сыйфатлары кимчелекле, аларда тәңгәлсезлекләр һәм төгәлсезлекләр шактый.

Әдәбиятчы галимнәребез Мәүла Колый иҗатын фидакярләрчә өйрәнеп, аны халкыбызга таныту өчен зур тырышлык куйганнар, аларның хезмәтләре – хәзергәчә кулланыла торган төп китаплар. Әмма бай иҗади мирас калдырган, XVII гасыр татар әдәбияты тарихында бердәнбер шагыйрь

Мәүла Колый әсәрләренең заманча фәнни таләпләр югарылыгында камилләштерелгән тулы басмасы кичектермичә хәзерләп нәшер ителүе зарур. Моның өчен әдипнең шигырь-хикмәтләре һәм поэмалары сакланган кулъязма чыганаклар һәммәсе тәфсилләп өйрәнелергә тиеш.

***

«Татар археографиясе» сериясенең «Шигъри ядкярләр» исемле 27 нче китабында Мәүла Колый иҗаты турында бүлек бирелгән иде[16]. Анда шагыйрь әсәрләренең күчермәләре татарлар яши торган төбәкләрдә, сирәк булса да, хәзер дә табылып торуы әйтелде.

Әдипнең билгеле булган кайбер әсәрләренең күчермәләре археографлар тарафыннан табылып килүе белән бергә, моннан элегрәк – ярты гасыр әүвәл экспедицияләрдә юнәтелгән, ләкин фәнни әйләнешкә хәзергәчә кермәгәннәре барлыгы да ачыкланды. Нәтиҗәдә, Мәүла Колыйның иҗади мирасына караган, иске кулъязма истәлекләрдән соңгы вакытта үзебез тәгаенләгән әсәрләре шушы китапта бастырылды.

Хәзерге китап тулаем М.Колый әсәрләренә багышланганга күрә, 2021 елда дөнья күргән «Шигъри ядкярләр»дәге мәгълүматларны да тулыландырып монда өстәдек. Ул китапта Милли китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә XIX гасырдагы ике җыентыкта М.Колыйның аерым хикмәтләренең күчермәләре барлыгы турында язылып, күзәтү тәкъдим ителгән иде. Алардан берсе шагыйрьнең 23 нче хикмәте, ә икенчесе – 35 һәм 52 нче хикмәтләрнең үзенчәлекле кушылмасы икәнлеге бәян ителде. Шунда ук Мәүла Колыйга нисбәт ителгән бүтән бер хикмәтнең күпсанлы күчермәләре барлыгы, авторы чынлап та М.Колый булуы ихтимал икәнлеге, аның турында галимнәрнең төрле

[16] Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар / төз. Р. Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2021. – Б. 53–69.

фикерләре (шул исәптән, ачыктан-ачык ялгышлары) турында язылды.

Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлегендәге истәлекләрне 2024–2025 елларда тәфсилләбрәк өйрәнү дәвамында, андагы ядкярләр арасында 9 кульъязма җыентыкта М.Колыйның төрле шигъри әсәрләре барлыгын ачыкладык. Әдипнең моңарчы билгеле булган хикмәтләренең күчермә текстлары һәм иң мөһиме – элегәчә бөтенләй мәгълүм булмаган тагын бер поэмасы һәм бер шигыре табылды. Электән билгеле хикмәтләрне тулыландыра торганнары да булуы шулай ук әһәмиятле. Әлеге тугыз җыентыкның җидесе танылган археограф галим Альберт Фәтхи тарафыннан 1972–1977 еллардагы экспедицияләрдә Татарстанның Актаныш, Зәй, Мөслим, Сарман һәм Чаллы районнарындагы авылларда табылганнар. Бер кульъязма дәфтәр Казан университеты һәм Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Пермь өлкәсендә 2001 елда табылган. Бер җыентыкның кайчан һәм кайда табылганлыгы билгесез (үзендә теркәлмәгән)[17]. Кульъязмаларның җидесе XIX гасырның беренче яртысына нисбәтле.

Альберт Фәтхи үзе тапкан кульъязмалардагы әсәрләрне һәм аның авторы Мәүла Колый исемен, һичшиксез, күргән һәм белгән дип уйлыйбыз. Әмма аның басылып чыккан мәкаләләрендә нәкъ шул кульъязмалар турында берни дә әйтелмәгән. М.Колый әсәрләре теркәлгән җыентыклар табылган 1972–1977 нче еллардагы А.Фәтхи экспедицияләренең материаллары (хисаплары һәм баш-

[17] Кульъязма истәлекләрнең кәгазь читләренә кайдан, кемнән һәм кайчан алынганлыгы турындагы мәгълүматны татар археографлары тарафыннан кыскача теркәп кую гадәте – электән дәвам итеп килгән күренеш. Ләкин язма ядкярләрне тасвирлаганда кайвакытта үзара буталышкан кәгазь битләре берләштерелә яисә аерыла. Шул сәбәпле, кульъязма кәгазьләрдә алынган урыны һәм вакыты теркәлмичә калган очраклар бар.

ка төрдәге язмалары) арасында да М.Колый шигырьләре сакланган дәфтәрләр һәм ул истәлекләрне тапшырган кешеләргә бәйле бер сүз дә язылмаган. Гәрчә, А.Фәтхи археографик табышлар арасындагы кыйммәтле әдәби һәм тарихи ядкярләрне, авторларын күрсәтеп, махсус теркәп барган.

Мәүла Колый әсәрләре язылган җыентыкларның өчесендә әдипнең берничәшәр әсәре: «8687т» җыентыгында 1–5 нче хикмәтләре һәм Адәм пәйгамбәргә багышланган, моңа хәтле билгесез кыйсса, «8686т» шифрлы кулъязмада 16, 17, 25 нче һәм 68 нче хикмәтләре[18], «8688т» санлысында 16 нчы һәм 74 нче хикмәтләр урын алган. «8683т» кулъязмасында 35 нче һәм 52 нче хикмәтләрнең кушылмасы бар. Ә калган биш җыентыкта М.Колыйның моңа хәтле билгеле берәр хикмәте: «8685т» шифрлы кулъязмада 22 нче хикмәт, «6748т» санлыда 52 нче хикмәт, «8771т» кулъязмада 78 нче хикмәт, «8684т» шифрлысында 79 нчы хикмәт теркәлгән, ә «8689т» шифры белән саклана торган шигъри җыентыкта Мәүла Колыйның әлегәчә билгесез булган «Дәрвишләр сохбәтендә» шигыре язылган. Шул ук дәфтәрдә, аныкы булуы ихтимал дип без фаразлаган «Рухел-әмин» шигыре дә бар. Кулъязма җыентыкларның тулырак тасвирлары шушы китапта шигъри текстлар алдында бирелде.

Әйтелгәннәр арасында Мәүла Колыйның ике әсәре моңарчы әдәбият тарихында билгеле түгел иде. Алар – «Адәм пәйгамбәр кыйссасы» һәм «Дәрвишләр сохбәтендә» дип, безнең тарафтан шартлы исемнәр белән аталганнары. Аларның текстларында авторы – Мәүла Колый исеме төгәл күрсәтелгән.

Пәйгамбәр кыйссасының башы юк. Булган хәтле тексты 70 икеюллыктан артык. Шагыйрь аны ислам дине тарихында билгеле риваятьләргә нигезләнеп, баетып һәм бизәп, кызык-

[18] Автор хикмәтләренең мондый саннар белән билгеләнеше Уфа (2010 ел) басмасы буенча бирелә.

лы сюжетта иҗат иткән. Анда Аллаһы Тәгаләнең Җәбраил фәрештә аша Адәм пәйгамбәрне ут табарга, киенергә, тугры иманлы булырга һәм шөкер кылырга, Кәгъбәтуллада намаз укырга, бодай игәргә һәм игенчелек белән шөгыльләнергә, икмәк пешерергә, ураза тотарга өйрәтүе турында сүз бара. Мәүла Колый иҗат иткән Адәм пәйгамбәр кыйссасының үзәгендә береккәнлек мәсьәләсе тора. Автор бу сүзгә Аллаһы Тәгаләнең кушканнарына, изге ислам диненә берегү, ярдәмчеллек, бердәмлек турындагы олуг мәгънә салган. Береккәнлек темасы шагыйрьнең элегрәк ачыкланган әсәрендә дә тасвирланып, бер поэмасы аның үзе тарафыннан нәкъ шулай – «Береккәннәр сыйфаты» дип аталган. Димәк, шагыйрь әлеге теманы төрле сюжетлар эчендә кабат-кабат тасвирлаган.

Мәүла Колыйның хикмәтләре төрле шигъри үлчәмнәрдә язылганлыгы билгеле. Ә яңа ачыкланган поэмасы, моңарчы мәгълүм булган ике поэмасы кебек үк, унберәр иҗекле бәйтләр (икеюллыклар) кулланып иҗат ителгән.

«Дәрвишләр сохбәтендә» шигырен Мәүла Колый үзенең рухи остазлары – мәшһүр суфи әдипләр Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакырганиның шундый ук рефренлы хикмәтләре тәэсирендә, назыйрә итеп язган. М.Колый шигыре ун строфадан (дүртьюллыктан) тора, Ясәвинеке 8, Бакырганиныкы 6 строфалы.

Электән билгеле булган хикмәтләрнең яңа ачыкланган күчермәләре төрле сыйфатта һәм төрлечә күләмдә. Берничә хикмәтнең текстлары элек билгеле булган строфалар санын тагын да баета. Мәсәлән, «8684т» шифрлы кульязмада Мәүла Колыйның ун строфалы шигыре бар. Бу шигырь 2010 нчы елда чыккан җыентыкта, 79 нчы санлы хикмәт буларак, тугыз дүртьюллык күләмендә басылган. Ләкин яңа ачыкланган кульязмадагы текстның өч дүртьюллыгы гына басмадагы вариантка туры килә. Димәк, кульязмадагы текстның җиде строфасы моңарчы билгесез булган.

Бу очракта шагыйрьнең ике хикмәте бергә кушылгандыр дип уйларлык нигез дә юк. Чөнки строфаларның шигъри төзелеш үзенчәлекләре бер хикмәтне тәшкил итә. Нәтиҗәдә, ике кулъязмадагы строфаларның исәбен бергә кушып караганда, 79 нчы хикмәтнең тексты 16 строфаны тәшкил иткәнлеге һәм шулардан җидесе моңа хәтле билгесез булып килгәнлеге ачыклана.

Башка шигырь-хикмәтләрнең 2010 елда Уфада басылып чыккан М.Колый җыентыгындагы текстлардан аермалары зур түгел. Кайбер сүзләрнең һәм аерым гыйбарәләрнең бүтәнчәрәк икәнлеге генә күренә. Бу китапта урын алган шигырьләрдән 23 нче хикмәт, 2010 елда басылган китаптагы тексты белән чагыштырганда, иң күп аермалысы. Иске кулъязма текстларга хас хаталы язылышлар һәм өзеклекләр (сүзләрне, шигъри юлларны төшереп калдыру күренеше), кызганыч ки, әсәрләрнең автор иҗат иткән камиллеген какшата.

Яңа ачыкланган кулъязмалардагы текстларда төшеп калган өлешләрнең һәм артык өстәмәләрнең, хаталарның шактый булуы дәфтәр ияләренең генә ялгышлары түгел, әлбәттә. Сүз бара торган кулъязмалар Мәүла Колый вафат булганнан алып бер гасырдан артыграк һәм гасыр ярым чамасы соңрак вакытка нисбәтле. Димәк, әлеге шигъри җыентыклардагы текстлар берничә мәртәбә кабатлап күчерелгәннәр һәм, табигый, һәр күчерүче тарафыннан азмы-күпме дәрәҗәдә үзгәртүләргә дучар ителгәннәр. Текстларның бөтенлеге һәм сыйфатлары күчергән кешеләрнең аң-белеме, игътибарлыгы һәм пөхтәлеге кебек сыйфатларына да бәйле булган.

Бу җыентыкта Мәүла Колыйның моңарчы галимнәргә билгесез булган унбер кулъязмадан алынган төрле күләмдәге 17 хикмәте текстлары урын алды.

Китапта М.Колыйныкы булулары ихтимал дип фаразланган өч шигырь тексты да тәкъдим ителде. Берсе элеккерәк чор галимнәренең фаразы булса, икесе безнең тарафтан

гөман ителде. Беренчесенең дистәләрчә күчермәләрдәге вариантлары бар. Ә соңгы икесе бу китапта текстлары бирелгән Мәүла Колый хикмәтләре теркәлгән кулъязмалардан алынды. Алар икесе дә җыентыкларда М.Колый хикмәтләре белән янәшә битләрдә язылганнар.

Шагыйрьнең ике поэмасы текстлары саклanган 1754 елгы кулъязмадагы аерым шигъри парчаларның да Мәүла Колыйныкы булулары ихтимал дип элегрәк язган идек[19]. Аларны монда кабатлап тору ихтыяҗы күрелмәде.

Китапта текстлары кулланылган 11 кулъязма истәлекне М.Колыйның электән билгеле булган 6 күчермәсенә кушып, барысы бергә 17 берәмлеккә җиткәнлеген әйтү дә мөһим. Бу исә олуг фикер һәм иҗади сәләт иясе Мәүла Колыйның бай иҗат ядкярләре халык арасында кулдан күчерелеп киң таралганын һәм укылганын тагын бер кат раслый.

Мәкаләбезнең башында Мәүла Колый иҗаты турында 2014 елда басылган энциклопедиядәге белешмәдән өзек бирелгән иде. Анда шагыйрьнең «100-дән артык шигыре (3800 юлга якын) мәгълүм» диелгән мәгълүмат төзәтүне һәм тулыландыруны таләп итә. 1999 елгы китапта ук басылган[20] ул сан, тулы-төгәл түгеллегенә карамастан, соңгы елларгача кабатланып килә. Мәүла Колый әсәрләренең 2010 елда Уфада басылган тулы җыентыгының 4 нче битендә Ф.Туйкә тарафыннан табылган кулъязмада 3700-дән артык шигъри тезмә (ягъни, юл) булганлыгы белдерелгән[21]. Ул китапта 1–97 нче хикмәтләрнең текстлары Туйкә күчермәсе буенча бирелгән. Ә җиде шигырь (98–104 нче хикмәтләр) Башкортстанда табылган кулъязмадан өстәлгән. Ләкин соңгы җиде хикмәтнең һәм шул ук китапта урын алган ике поэманың

[19] Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар ..., 2021. – Б. 54–55.

[20] Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). – Казань: Фэн, 1999. – С. 163.

[21] «Татар әдәбияты тарихы»ның 2022 елда дөнья күргән яңартылган икенче басмасында да (икенче том, 244 нче бит) шул ук сан күрсәтелгән.

ничә шигъри юлдан торганлыклары 3700-дән артык дигән санга кушылмаган. Югыйсә, китап бер үк автор иҗатына багышланган бит. 2010 елгы басмада шигъри юллар алдында куелган саннар буенча исәпләгәч, 1–97 нче хикмәтләр барлыгы 3752[22], ә 98–104 нче хикмәтләр 296 юлны тәшкил итә. Шул ук китаптагы ике поэма текстлары 304 шигъри юлдан тора. Димәк, М.Колый иҗат иткән әсәрләр 2010 елгы Уфа басмасында 4352 шигъри юллык икәнлеге ачыклана.

Тик бу сан да төгәл үк түгел әле. Чөнки аны китаптагы шигъри юллар алдында куелган саннар нигезендә исәпләдек. Уфа басмасында поэтик төзелеше буенча юлларга дөрес бүленмәгән бер хикмәт барлыгын истә тотсак, чынбарлыкта бүтән сан килеп чыга. 23 нче хикмәтнең строфалары ул китаптагыча озын юллы итеп бирелүгә караганда, безнең шушы китаптагы кебек кыска дүртьюллыклар рәвешендә булганда үзеннән-үзе көйләнеп тора. Гомумән, хәзерге китапларда әүвәлге кульязмаларда язылган рәвештә (хәтта кайчакта бер строфаны бер юлда) бирү дөрес түгел. Ихтимал, элек көйләп укыганда шигъри юлларны озын итеп язу ярагандыр. Тик, хәзерге уку тексты буларак, аларны, яңгырашларына карап, ритмик үлчәм буенча бүлү кулайрак[23].

Мәүла Колый әсәрләренең 2010 елгы басмасындагы 23 нче хикмәтнең юлларын дөресләп (36 урынына 72 дип) исәпләгәндә, андагы 104 хикмәт һәм ике поэманың 4352 урынына 4388 шигъри юлны тәшкил иткәнлеге тәгаенләнә. Бу санга соңгы – менә шушы китаптагы 210 юлны[24] да куш-

---

[22] Менә шушы сан «3700-дән артык» яисә «3800 юлга якын» дип күрсәтеп йөртелгән.

[23] Татар текстологиясенең хәзергәчә хәл ителеп бетмәгән бу мәсьәләсенә элегрәк тукталган идек (Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар ..., 2021. – Б. 22, 158–165).

[24] Төгәл итеп әйтсәк, «Адәм пәйгамбәр кыйссасы»нда 141 юл, «Дәрвишләр сохбәтендә» исемле хикмәттә 39 юл, элек билгеле булган хикмәтләрнең яңа ачыкланган строфаларында: 79 нчы бәйттә өстәмә 28 юл һәм 22 нче бәйттә ике юл. М. Колыйныкы булулары ихтимал шигырьләрне бу исәпкә кертмәдек.

кач, Мәүла Колый иҗат иткән әсәрләрдән хәзерге вакытка билгеле булган хикмәтләр һәм өч поэма барлыгы 4598 шигъри юлны тәшкил итүе төгәл билгеле. Бу исә моңарчы язып йөртелгән саннардан күпкә артык.

***

Бу китапта басылган текстларның укылышын һәм аларны аңлауны җиңеләйтү өчен хәзерге татар алфавитында булмаган, калын әйтелешле авазларны белдерә торган өстәмә ике хәреф – «қ» һәм «ғ» кулланылды. Текстлардагы кайбер имля тотрыксызлыгы (мәсәлән, *кыл/кыйл, булур/улур, килеб/килүб, идеб/итеб* һ.б.) кулъязмаларның үзләрендәгечә, үзгәрешсез бирелде.

Поэманың тексты тулы булмаса да, сакланган шигъри юлларына бәйт саннарын куйдык, шулай ук хикмәтләрнең тулы һәм тулы түгел строфаларын саннар белән билгеләдек. Соңгылары бу басмадагы искәрмәләрне язганда кулайлык өчен кулланылды. Әсәр текстларының кулъязмаларда кайсы биткә туры килүләре дә күрсәтелде.

Мәүла Колый әсәрләренең бу китаптагы текстлары алдында кулъязма чыганакларның гомуми тасвирлары бирелде, шулай ук кыскача башка аңлатмалар һәм текст ахырларында искәрмәләр язылды. Текстлардагы бөтен тыныш билгеләре дә безнең тарафтан өстәлде.

Китап өч бүлектән тора: беренче бүлектә шагыйрьнең моңарчы мәгълүм булмаган әсәрләре, икенче бүлектә моңарчы басылган текстларның билгесез күчермәләре һәм өченче бүлектә Мәүла Колыйныкы булулары ихтимал шигырьләр тәкъдим ителде.

Авторның шушы китапта текстлары басылган аерым хикмәт-шигырьләре галим К.Дәүләтшин тарафыннан хәзерләнеп, 2010 елда Уфада дөнья күргән китаптагыча ук саннар белән билгеләнде.

Бу китапта Мәүла Колый әсәрләренең:

– кулъязма күчермәләренә гомуми тасвирламалар;

– хәзерге татар алфавитына «қ», «ғ» хәрефләре өстәлгән текстлары һәм аларга карата искәрмәләр;

– хәзерге татар әдәби теленә юлга-юл күчермәләре[25];

– кулъязмаларның факсимилеләре туплап бирелде.

***

Китапны басмага хәзерләгәндә күрсәткән ярдәмнәре өчен Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең директоры урынбасары Ирек Һадиевка, китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат Заһидуллинга, Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге мөдире Энҗе Сабировага, шул бүлек хезмәткәре Айрат Сәмигуллинга зур рәхмәтләремне белдерәм.

[25] Әсәрләрнең хәзерге телгә күчермәләрендә кайбер сүзләр, шигъри өслүбне саклау өчен, төп-төгәл мәгънәләрендә бирелмәгәнлеген искәртү зарур.

# БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК: МОҢАРЧЫ БИЛГЕСЕЗ БУЛГАН ӘСӘРЛӘР

## «Адәм пәйгамбәр кыйссасы»

Бу әсәрнең (поэманың) хәзергә бер күчермәсе ачыкланды. Текстының башы мәгълүм түгел, төп өлеше һәм ахыры бар. Башындагы билгесез күләме бик зур булмаган дип чамалана.

Әсәрнең үз исеме билгеле түгел, аны, эчтәлегенә күрә шартлы рәвештә, «Адәм пәйгамбәр кыйссасы» дип атадык.

Гомуми эчтәлегенең 73 бәйте билгеле дияргә мөмкин. Шулардан 5 бәйтнең берәр юлы гына мәгълүм, ә икенче юллары кульъязмада теркәлмәгән. Ягъни, күчерүче тарафыннан төшереп калдырылган.

Поэма тексты Россиядә XIX гасырның икенче чирегендә (филиграненда «1838» ел төшерелгән) эшләнгән, 10,5х17 см үлчәмле кәгазьдәге җыентыкта гарәп язуының нәстәгъликъ-шикәстә төрендә, ачык көрән төстәге язу карасы белән теркәлгән. Бу кульъязмада Мәүла Колыйның поэмасы текстыннан тыш, аның биш хикмәте дә бар. Мәүла Колыйның 1–5 нче хикмәтләренең текстлары шушы ук җыентыкта 29а-31б кәгазьләрдә, төрле күләмдә язылган. Кульъязма истәлекнең саклануш сыйфаты уртача диярлек, кызганычка, аерым урыннарындагы кәгазьләре җуелган.

Кульъязма җыентык хәзерге вакытта Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «8687т» шифры белән саклана. Аны Татарстанның Зәй районындагы Кушъелга авылында Гөлзаһирә Гыйлаҗетдин кызы Юнысовадан (1899 елда туган) археограф Альберт Фәтхи 1974 елда алган. Шуны белдергән

мәгълүмат кулъязманың 3а кәгазендә кызыл төстәге кара белән, гарәп хәрефләрендә «АЭ-74...» дип башлап, А.Фәтхи тарафыннан язып куелган.

Әсәрнең эчтәлеге ислам дине тарихындагы риваятьләргә нигезләнгән. Анда Адәм пәйгамбәрнең җәннәттән җиргә куылганнан соңгы хәлләре тасвирланган. Сакланган текстның «Булды суык, исте җилләр...» дип башлануы ук игътибарны җәлеп итә. Салкыннан туңган Адәм галәйһиссәлам суыктан котылу өчен Аллаһы Тәгаләдән ут бирүен сораган. Аллаһы Тәгалә аңа чакма ташы, коры үлән (ку) ярдәмендә ут табарсың дип әйтә. Адәм башта ялгышып таштан, кудан һәм чакмадан ут сорап ялварып интеккән. Шуннан соң чакма чагып, куга очкын элдерү ысулы белән ут табарга өйрәнгән. Пәйгамбәр Аллага шөкер әйтеп, «бу ут кыяматкә кадәр кирәк булачак», ди. Автор, шул рәвешчә, тимер ташы белән ку берлектә ут хасил иттеләр дип, һәр эшне береккәнлек (бердәмлек) җиңеләйтүен искәрткән. Аннан соң Адәм пәйгамбәр Кәгъбәгә юл тота һәм «ни кылыйм?» дип Аллаһыга мөрәҗәгать итә. Аллаһы Тәгалә Кәгъбәдә гыйбадәт-намаз кылырга өйрәтү өчен Җәбраил фәрештәне пәйгамбәр янына юллый. Шулай ук Җәбраилгә җәннәттән куйлар һәм бодай тапшыру да йөкләнә. Фәрештә, Аллаһы әмере белән, Адәмне бодай чәчеп-игәргә өйрәтә, берегеп эшләгәндә бу эшнең җиңелрәк булуын әйтә. Адәм пәйгамбәр үгез җигеп (текстта – «хайван» дип кенә аталган), җирне сөреп, бодай чәчә, Аллаһы Тәгаләгә шөкерләр укый. Аллаһы күккә әмер биреп яңгыр яудыра. Бодай үсеп җитешкәч, аны он итеп тартып, камыр хәзерләп һәм мич хәстәрләп Адәм галәйһиссәлам икмәк пешерә. Аллаһы Тәгалә Җәбраил фәрештә аша Адәмгә кичкә хәтле ураза тотарга, догаларшөкерләр кылырга кирәклеге турында әмерен ирештерә. «Гөнаһларын кичерәм, җәннәткә кертәм» дип сөендерә.

Адәм пәйгамбәр Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үти, «Береккәнлектән бу эшләр хасил булды» дип, шөкрана укый.

Автор поэманы «Береккәннәр эшен Аллаһ җиңел кыла» дип төгәлләгән.

Автор үз исемен ике урында белдергән. Берсе – 25 нче бәйттә:

Йа, Илаһи, күргүзгел берлек йулый,
Рәхмәтеңлә йарлыка Мәүла Колый,

– рәвешенчә һәм икенчесе 72 нче бәйттә:

Береккәнлек биргел сән Мәүла Кола,
Тагатеңне кыйлмага Изем гайна.

Болардан 25 нче бәйттәге юллары Мәүла Колыйның «Береккәннәр сыйфаты» дип шартлы исем белән аталган, моңарчы мәгълүм булган бүтән әсәренең ахырындагы бетем өлешенә охшаш. Анда (118 нче бәйттә) болай диелгән:

Әй, Ходайа, гасый җафи Мәүла Колый,
Рәхмәтеңлә биргел коллык юлы[1].

«Береккәннәр сыйфаты» поэмасының төп мәгънәсе Мәүла Колыйның Адәм пәйгамбәргә багышланган әсәрендәгечә үк. Ике текстта да автор береккәнлекне данлаган һәм уңышларга ирешүнең төп нигезе итеп тасвирлаган. «Береккәннәр сыйфаты» текстындагы:

Гакыйль адәм берегеб берлек кыйла,
Хак рәхмәте берлеккә якын була[2],

– бәйтендә һәм Адәм пәйгамбәр турындагы әсәрдә:

Береккәннең һәр эше бөйлә була,
Береккәннәр эшен Хак асан кыйла,

– дип язылган юллар бар. Гомумән, башка икеюллыкларда да охшашлыклар күренә.

«Береккәнлек, берегү, берекмәк» сүзләренә М.Колый ике төрле мәгънә салган дип аңлашыла. Берсе – берләшү, ярдәмләшү, бердәмлек күздә тотылган булса, икенчесе – иң мөһиме – Аллаһы Тәгалә күрсәткән хакыйкатькә берегү һәм

[1] Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2011. – Б. 36.
[2] Шунда ук. – Б. 35.

аннан аерылмау. Күрәсең, автор Коръәннең «Әлү Гыймран» сүрәсендәге 103 нче аятьнең «Вә игътәсаму би-хәблә Аллаһи вә лә тәфәррәку» («Барыгыз бергә Аллаһның арканына [Китабына һәм диненә] ныклап ябышыгыз һәм аерылмагыз»[3]) дигәнен күздә тоткандыр.

Мәүла Колый иҗат иткән Адәм пәйгамбәр турындагы әсәрнең әлегә билгеле тексты ике өлештән (гүяки, ике бүлектән) торган кебек. Беренчесе – ут табу турында тасвирланган сюжетның төп мәгънәсе – береккәнлек һәм ярдәмләшү 23 нче һәм 24 нче икеюллыкларда әйтелгән. 25 нче бәйттә автор үз исемен белдереп, 26 нчы икеюллыкта дога сүзләре белән төгәлләгән. Аннан соң 27 һәм 28 нче бәйтләрдә автор, «суыклыктан котылып, булды әман» дип, Адәм галәйһиссәламнең Кәгъбәгә китүе турындагы бүлекне хикәяли башлаган. Беренче өлешенең беренче строфасында салкын һәм каты искән җилдән «бөгелде Адәм» дип башланып, Аллаһы Тәгалә биргән ут белән җылынганнан соң, әсәрнең икенче өлеше «Торды Адәм...» дип хикәяләнеп киткәнлеге белән дә кызыклы. Бу – авторның шигъри тасвир куәтенең дәрәҗәсен ачык күрсәтә. М.Колыйның, шул рәвешле, Адәм пәйгамбәргә бәйле төрле вакыйгаларны берберсенә бәйләп тасвирлаганлыгы аңлашыла. Икенче өлешнең дә ахырында автор береккәнлекне олылап, нәтиҗә фикерен белдергән. Анысында да үз исемен күрсәтеп, дога сүзләре белән тәмамлаган.

Әсәрнең башы кулъязмада сакланмаган дигән идек. Җыентыкның ул урынында өч куш битле (алты кәгазьле) бер дәфтәрчегә җуелган. Тулаеммы, түгелме – әлеге дәфтәрчекнең күпмедер өлешендә шушы әсәр тексты язылган булуы аңлашыла. Ул өлешендә дә төп текстка бәйләнешле берничә бүлек булгандыр дип фаразларга мөмкин.

[3] Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә. – Казан: «Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты, 2020. – Б. 84.

Мәүла Колыйның элегрәк табылып ачыкланган ике поэмасының «Береккәннәр сыйфаты», «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» дип аталулары уңаеннан «Мәүла Колыйның мондый «сыйфатлау»лар рәвешендә язылган әсәрләре тагын да булып, алар бер циклны тәшкил иткәндер дип тә фаразларга мөмкин» дип язган идек. Шагыйрьнең соңгы ачыкланган Адәм пәйгамбәр турындагы әсәренең моңарчы билгеле төп темасы – береккәнлек мәсьәләсе булуы ягыннан караганда, авторның бер үк темага кабат-кабат мөрәҗәгать иткәнлеге аңлашыла. Ә «сыйфат» сүзен М.Колый «тема» мәгънәсендә башка әсәрләрендә дә кулланган, мәсәлән, шушы китаптагы 16 нчы хикмәтен соңгы строфасында «Ахыр заман сыйфатлары» дип атаган.

Әйтеп үткәнебезчә, бу поэма ислам динендәге әүвәлге риваятьләргә нигезләнеп язылган. Мәсәлән, Рабгузиның XIV гасыр әдәби истәлеге булган «Кыйсасел-әнбия» исемле һәм госманлы төрек авторлары Әхмәд Биҗан 1460 елда иҗат иткән «Әнварел-гашыйкыйн» исемле, шулай ук Мөхәммәд Чокрыкчызадә (1623 елда вафат) авторлыгындагы «Алты бармак»[4] дип аталган зур күләмле әсәрләрдә М.Колый тасвирлаганга охшаш урыннар бар. Аларда Адәм галәйһиссәламнең җиргә иңдерелгәч бик ачыккан булуы әйтелгән. Аллаһы Тәгаләнең әмере белән Җәбраил фәрештә Адәмгә бөтен нәрсәне һәм аларның исем-атамаларын өйрәткән, җәннәттән бодай китергән һәм чәчеп үстерү-җыю серләрен аңлаткан. Адәм пәйгамбәр үгез җигеп җир сөргән һәм бодай чәчкән, мул уңыш җыеп алган. Бодайны он итеп тарткан. Мич ясап, ут кабызган һәм икмәк пешергән.

Рабгузиның «Кыйсасел-әнбия» китабында Адәм пәйгамбәр турындагы бүлектә туфракка орлык чәчеп үсте-рүнең өстенлеге хикәяләнеп, «Әгәр бер уч богдай салсаң – ун гый-

[4] Бу китап – XV гасырда фарсы телендә язылган «Мәгарижен-нөбүвә фи мәдәриҗел-фөтувва» исемле әсәрнең төрек теленә тәрҗемәсе.

ваз бирүр, унга – йөз, йөзгә – мең»[5] дип язылган. Шулай ук «Изи Гыйззе вә Җәлл тәкъдир кыйлмыш ирде – дөнйада Адәм угланларының йийеме богдай булгусы торур»[6] диелгән.

Кәгъбәтулла турында Рабгузи әсәрендә болай диелгән: «Йәнә Адәм галәйһиссәлам Мәккә йиренә килеб бер өйү кубарды – йийезлеге күккә йитәр. Бер аты – Сарах, бер аты – Бәйтел-мәгъмүр. Ул өйүнең тигрәсендә тәваф кыйлды ирсә, Мәүля Тәгалә Адәм галәйһиссәламнең зилләтен кичерде. Качан Нух туфаны булды ирсә, Мәүля Тәгалә йарлыгы берлә Җәбраил галәйһиссәлам килеб, ул өйүне түртенче кат күккә чыкарды»[7]. Китапта, сүзне дәвам итеп, Адәм пәйгамбәрнең ике йөз ел елавы, шуннан соң Гарәфәт тавында Хаува белән кавышулары, Һиндстанга барулары, Аллаһы Тәгаләнең җәннәттән сигез куй җибәрүе, Адәм белән Хаува аларның йоннарын кыркып, аны тукып, кием итеп киюләре бәян ителгән. «Йир йөзендә куйдин бәрәкәтле мал йук» диелгән. «Адәм галәйһиссәламнең карыны ачты, Җәбраил галәйһиссәлам ике үгүз килтүрде Изи фәрманы берлә оҗмахдин. Бере – кызыл, тәкый бере – кара. Йирне өч бәхеш кыйлды: ике бәхешен зирагать кыйлды, бер бәхешене йортланды. Җәбраил галәйһиссәлам диһканчылыкның җәмигъ кирәк-йарагын үгрәтә бирде, өч хөшә богдай килтүрде... Өч әфүнне ушак кыйлды, тәлим булды. Адәм галәйһиссәлам игде һәм ул богдай булды, Хаува анамыз игде – арпа күкәрде. Адәм галәйһиссәлам әйде: «Тәнавел кыйлайынму?» – тиде. Җәбраил галәйһиссәлам әйде: «Оргыл!» Орды. «Йийайенму?» – тиде... «Он кыйлгыл!» – тиде... «Нан

[5] Кыйсасел-әнбийаи Рабгузи. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1881. – Б. 17. *Гыйваз* – өлеш.

[6] Шунда ук. – Б. 18. *Изи Гыйззе вә Җәлл* – Аллаһы Тәгалә; *йийем* – ризык; *булгусы торур* – булачак.

[7] Шунда ук. – Б. 25. *Галәйһиссәлам* – аңа сәламнәр булсын; *өйү кубарды* – өй төзеде; *йийезлеге* – түбәсе; *аты* – исеме; *тигрәсе* – тирәсе; *тәваф кыйлды ирсә* – әйләнсә; *Мәүля Тәгалә* – Аллаһы Тәгалә; *зилләт* – хурлык, гөнаһ; *йарлык* – фәрман.

пешергел!» – тиде. Нан пешүрде. «Йийайенму?» – тиде. «Йук!» Йарлыг килде: «Әй, Адәм! Көннең ике өлүше бар иде, бер өлүше калды. Сабыр кыйл, бер өлүшен рузә тотгыл. Мин сиңа өч эш гата кыйлайын: әүвәл – хушнуд булайын, йәнә гөнаһларың багышлайын, йәнә – сине оҗмахка кигүрәйен. Әймешләр – ул көн Гашура көне ирде»[8].

Әхмәд Биҗан язган «Әнварел-гашыйкыйн» китабының Адәм пәйгамбәр турындагы бүлегендә мондый юллар бар: «Адәм галәйһиссәлам качан очмакдан чыкды, карыны ачыкды. Җәбраил җәннәттән богдай китүрде вә зирагатен тәгълим итде. Адәм галәйһиссәлам аны үгүз илә икде вә ул богдай бөтде. Адәм бер тәнур йапды, анда бешүрде»[9]. Дини китапларда төрлечә: өч данә бодай дип яисә өч башак дип әйтелгән.

«Алты бармак» әсәрендә дә Аллаһы Тәгалә әмере буенча Адәм белән Хаувага җәннәттән терлек-туар китерелеп, аларның йоннарыннан киемнәр хәстәрләнүе һ.б. вакыйгалар хикәяләнгән. Мәүла Колый кыйссасына якын булган өлешләренең кайберләре мондый: «Адәм галәйһиссәлам эссе вә сугук тәшвишеннән хәляс булуб, ачлык изтыйрабына дөшде», «Җәбраил галәйһиссәлам ... агач вә дәмүр китүрде». Шулай ук Җәбраил өч данә бодай китергән һәм аларның икесен Адәмгә, берсен Хаувага бирергә кушкан. «Адәм галәйһиссәлам әйтде: «Йа, Җәбраил! Бонлары әкәл идәйемме?» Җәбраил галәйһиссәлам әйтде: «Сакла! Бу сәнең ачлыгың дәфегъ итсә кирәкдер. Буның сәбәбендән

---

[8] Шунда ук. – Б. 25–26. *Тәкый* – тагын; *бәхеш* – өлеш; *зирагать кыйлды* – сөрде; *диһканчылык* – игенчелек; *җәмигъ* – барлык; *үгрәтә* – өйрәтә; *хөшә, әфүн* – башак; *ушак кыйлды* – ваклады; *тәлим* – күп; *игде* – икте, чәчте; *күкәрде* – чыкты; *тәнавел кыйлайынму* – авыз итимме; *тиде* – диде; *йийайенму* – ашыйммы; *нан* – икмәк; *йарлыг* – Аллаһ фәрманы; *гата кыйлайын* – бүләк итим; *хушнуд* – риза, канәгать; *багышлайын* – кичерәм; *кигүрәйен* – кертим; *әймешләр* – риваять итәләр.
[9] Әхмәд Биҗан хәзрәтләренең «Әнварел-гашыйкыйн» нам китабе хакыйкать нисабләре. – Казан: Домбровский матбагасы, 1908. – Б. 29. *Качан* – кайчан; *очмак* – оҗмах; *зирагатен тәгълим итде* – чәчәргә өйрәтте; *бөтде* – мул уңыш бирде; *тәнур* – ипи пешерү миче, тандыр; *йапды* – ясады; *бешүрде* – пешерде.

җәннәтдән чыкдың. Сәнең вә әүлядының кыйамәтә дәк хәйатыңыза сәбәбдер...». Аннан соң җәннәттән ике үгез китергән. «Андан бәкар сәгый илә йире сөрмәгә башлады. Аннан ул данәләре икделәр... Башак улды. Җәбраил галәйһиссәламең дәлаләтилә дөгде вә сауырды вә он итде. Һәрвакыт йимәгә изен эстәрде, Җәбраил галәйһиссәлам мәныг идәрде. Андан тәнур бина итдерүб, хәмир итдерде вә итмәк әйләде. Җәбраил галәйһиссәлам әйтде: «Йа, Адәм! Нәһардән өч сәгать калды, сабыр әйлә, көн тулынсун. Ифтар заманы әкәл әйлә!» Адәм галәйһиссәлам аның савабын сөаль итде. Җәбраил галәйһиссәлам әйтде: «Хак Тәгалә аның мокабәләсендә өч кәрамәт вирер: әүвәл – сәне йарлыгар вә газаб итмәз; икенче – сәндин хушнуд улур, аслан газаб итмәз; өченче – сәне җәннәтә идхаль идәр вә әбәди ихраҗ итмәз»[10].

Бу риваятьләр һәм аларга охшаш башкалары бүтән дини әсәрләрдә дә язылган булса кирәк.

Үз заманының зур гыйлемгә ия булган татар әдибе Мәүла Колый поэмасын төрле чыганакларга – әйтеп үтелгән һәм башка әүвәлге дини китапларга нигезләнеп иҗат иткән. Монда китерелгән өзекләр эчтәлек ягыннан поэма текстына бик якын, хәтта М.Колый әүвәлге хезмәтләрдәге сүзләрне дә кулланган (мәсәлән, *дәмүр, әвүн, дөгде, тәнур, «Бәйтелмәгъмүр», зилләт* һ.б.).

---

[10] Чокрыкчызадә Мөхәммәд. Алты бармак китабы. – Казан: Вечеслав матбагасы, 1893. – Б. 77–78. *Сугук* – суык; *хәляс булуб* – котылып; *изтыйрабына дөшде* – газабына төште; *дәмүр* – тимер; *бонлары әкәл идәйемме* – боларны ашыйммы; *дәфегъ* – бетерү; *әүлядының* – балаларыңның; *кыйамәтә дәк* – кыяматкә хәтле; *хәйатыңыза* – яшәешегезгә; *бәкар* – үгез; *сәгый илә* – тырышып; *йире сөрмәгә* – җирне сөрергә; *данәләре икделәр* – бөртекләрне чәчтеләр; *дәлаләтилә* – өйрәтүенчә; *дөгде вә сауырды* – сукты һәм җилгәрде; *йимәгә изен эстәрде* – ашарга рөхсәт сорады; *мәныг идәрде* – тыйды; *тәнур бина итдерүб, хәмир итдерде* – мич ясатып, камыр хәзерләтте; *итмәк әйләде* – икмәк пешерде; *нәһар* – көн; *көн тулынсун* – кояш баесын; *ифтар заманы әкәл әйлә* – ифтар вакытында аша; *сөаль итде* – сорады; *мокабәләсендә* – бәрабәренә; *кәрамәт вирер* – юмартлык бирер; *йарлыгар вә газаб итмәз* – ярлыкар һәм газапламас; *сәндин хушнуд улур* – синнән канәгать булыр; *аслан* – бөтенләй; *җәннәтә идхаль идәр вә әбәди ихраҗ итмәз* – җәннәткә кертер һәм аннан мәңге чыгармас.

Әсәрнең теле чагыштырмача җиңел. Анда борынгы төрки сүзләрнең «дөгеб», «өгеб» (төеп, өеп) кебек язылышлары, Аллаһы Тәгаләнең Адәм пәйгамбәрне «зәгыйфем» дип атавы, «суыклык дәртенә ут булды дәва» рәвешендәге гыйбарәләр кызыклы.

Мәүла Колый әсәренең текстында Адәм пәйгамбәрнең Кәгъбәне төзүе тасвирланганына охшаш хәлләр дә элекке дини әсәрләрдә бар. Аларда Адәм галәйһиссәлам Мәккә шәһәре урынына килгәч Кәгъбәне төзи башлавы, шул вакытта изге кара ташның («хәҗәрел-әсвад») җәннәттән иңдерелүе турында да язылган. Дөрес, дини китапларда Кәгъбәне төзү турында өч төрле фикер бар: беренчесе – Адәм пәйгамбәр төзегән диелсә, икенчесе буенча аны фәрештәләр корган, ә өченче фикер – Адәм улы Шис пәйгамбәр төзегән. Ибраһим пәйгамбәр белән улы Исмәгыйль галәйһиссәлам Кәгъбәтулланы җимерелгәннән соң яңартып корганнар.

***

Адәм пәйгамбәр турындагы кыйсса тексты язылган кулъязма җыентыкның палеографик үзенчәлекләренә тукталыйк. Башка язма истәлекләргә хас булганча, анда да ялгыш-хаталар, аерым шигъри юлларның һәм сүзләрнең, шулай ук кушымчаларның һәм хәрефләрнең (еш кына нокталарының да) язылмыйча калуы кебек кимчелекләре бар. Кайбер сүзләр һәм икеюллыклар (8–9, 35 нче бәйтләр, 29 нчы бәйтнең икенче юлы) күчерүче тарафыннан кәгазь читләрендә өстәлгән. Ялгыш язылган сүзләрнең һәм хәрефләрнең кайберләре күчерүче кулы белән сызылган, тик шул ук вакытта сызылмыйча калганнары да бар. Аерым очракларда текстны күчерүче ялгышып кабатлап язган. Андыйлардан иң күләмлесе 27а кәгазьдәге җиде юллык текст 28а кәгазь башында кабатлап күчерелгән. Шул ике өлешнең берсендә хаталы язылган сүзләр икенчесендә дөресрәк теркәлгән булуы – текстны ачыклау өчен файда итте.

Хәрефләрнең язылыш үзенчәлекләреннән берсе – «уау» хәрефе өстендә өчәр нокта куелган. «Әлиф» һәм «ләм» хәрефләре кайбер сүзләрдә бик кыска язылганнар. Фарсы теленнән кергән сүзләрдә дә «п» хәрефе урынына «б» язылган очраклар бар, мәсәлән, «пөштипәнаһ» сүзе «бөштибәнаһ» дип теркәлгән. «Җим» шәкелендәге хәрефләрнең өске тарафы кайбер сүзләрдә уң якка таба шактый озын сызык кебек язылган. «Син» хәрефе аерым сүзләрдә бик кыска сызык белән (хәтта, юк дәрәҗәсендә) белдерелгән. Мәсәлән, «ихсан» һәм «мөяссәр» сүзләрендә «син» хәрефе язылмаган диярлек. «Гайн» хәрефенең сүз уртасындагы, ике яктан кушылып язылышы «фа» һәм «каф» кебек түгәрәксыман рәвештә. Шул сәбәпле, кайбер сүзләрне танып уку шактый читен, мәсәлән, 32 һәм 61 нче бәйтләрдәге «зәғифемғә» сүзен. «Йа» хәрефе еш кына «ра» хәрефенең бөгелгән («ра-и мокаувәс») шәкеленә охшаган, ә кайбер очракларда сүз ахырларында «ә» хәрефе рәвешен алган.

Аерым сүзләр бик бозылып язылган, мәсәлән, «илә» сүзе бер урында «зәйнә» дип, бөтенләй ялгыш теркәлгән.

Кыйсса текстында шактый гына сүзләрнең ахырларындагы «а», «ә» һәм «и» хәрефләре язылмаган булуына карап, бу әсәрнең элеккерәк күчермәләрендә, күрәсең, сузык авазларны белдергән хәрәкәләр кулланылгандыр дигән уй килә. «Суыкдан» сүзенең «суыкд» дип кенә язылган булуы, шулай ук әлеге кульязмадагы 2 нче хикмәт текстында «уфтанмакдин» сүзенең ахырындагы «ин» хәрефләре язылмаган булуы, ихтимал, кайбер сүзләр элекке күчермәләрдә тәнвиннәр («ан», «ән», «ин», «ун» дигәнне белдергән махсус тамгалар) белән дә язылгандыр дип фаразларга нигез булып тора. Борынгырак текстларда, бигрәк тә, «Кыйссаи Йосыф» күчермәләрендә хәрәкәләр һәм тәнвиннәр кулланылганлыгы мәгълүм[11].

[11] Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кульязмаларының палеографик үзенчәлекләре. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2024. – Б. 145–161.

Тексттагы берничә урында күчерүче тарафыннан төшереп калдырылган сүзләрне без фаразлап өстәдек. Әсәр кульязмасындагы текстның палеографик үзенчәлекләре астөшермәләрдә искәртелде.

Җыентыкта кыйсса тексты теркәлгән 24а кәгазе соңрак карандаш белән сызгаланган. Текстның ахырында (28б кәгазьдә) «тәммәт тәмам» дип язылган. Шул ук биттә «бисмиллаһ...» һәм Мәүла Колыйның беренче хикмәтенең беренче юлы һәм икенче юлының башындагы ике сүзе язылган.

Татар шагыйре Мәүла Колый иҗат иткән күләмле әсәрнең шушы хәлендәге өлеше (ягъни, шактый палеографик кимчелекле килеш тә һәм тексты бөтен-тулы булмаса да) әдәбият тарихы өчен бик әһәмиятле. Киләчәктә әсәрнең тагын да тулырак күчермәләре табылып, өйрәнелер дип өмет итәбез.

*24а кәгазь* 1 Булды суыӄ, исте йилләр һәм ӄати,
Бөгелде Адәм, ӄалмады һич таӄати.

Диде Адәм: «Йа, Раббым! Тигде үлүм.
Үзгә сәндин кем белүр мәнем хәлем?

Ут сән биргел йаӄыб йылынмаға[12],
Бу суыкдан[13] ӄотулмаӄ булынмаға».

Диде Аллаһ: «Бел, Адәм, бәндәлекең,
...[14]

5 Ташдин уты ӄудым имди[15] таӄытыб,
Ӄу-у-дәмур ағач илә беркетеб.

[12] Кульязмада бу сүз ялгыш «йылмаға» дип язылган.
[13] Кульязмада бу сүз «суыкд» дип теркәлгән.
[14] Бу бәйтнең икенче юлы җыентыкта язылмыйча калган.
[15] Кульязмада бу сүз юк, текстка безнең тарафтан өстәлде.

Анлардин ут эстәб алғыл имди сән,
Алмақлықны әмер қыйлдум имди[16] мән».

Алды Адәм ул заман ташны булуб,
Ташдин ут teләде ул[17] зари қыйлуб.

Дыңла имди фаш Адәмнең зарыни[18],
Ут чықаруб күргүзмәде нурыни.

Қуйды ташны һәм қуны алды йәнә,
Тәңре атын йад итеб қыйлды сәна.

Диде: «Әй, қу[19]! Ут бир мәңа, йықылдум,
*24б кәгазь* Суықлықдин үлүм хәлғә бөгелдүм»[20].

Нәчә дисә қудин аваз килмәди[21],
Ут бирмәгә қаульдин сәбәб булмади.

Қуы йәнә қуйыб дорды бер сари,
Чақмақ алыб һәм аңа қылды зари.

Диде Адәм: «Әй, чақмақ! Ут бир сәнә?
Тәңре атын[22] хақлаб, рәхим қыйл сана?»

Чақмақдин булмады анда һич чара,
Бу эш эчрә булды Адәм әүвәрә.

---

[16] Кулъязмада бу сүзнең ахырындагы «и» хәрефе язылмаган.
[17] Кулъязмада бу сүз юк, текстка безнең тарафтан өстәлде.
[18] Кулъязмада 8 нче һәм 9 нчы бәйтләр кәгазьнең сул читенә өстәп язылганнар.
[19] Кулъязмада бу сүз ялгыш «қод» дип язылган.
[20] Кулъязмада бу сүздәге «б» хәрефе астында бер нокта урынына ике нокта куелганга охшаган.
[21] Бу сүзнең «л» хәрефе кулъязмада теркәлмичә калган.
[22] Кулъязмада бу сүздән соң 14 нче бәйт башындагы «чақмақдин булмады» сүзләре язылып, күчерүче тарафыннан сызылган һәм шигъри юл дәвамы кәгазь читендә өстәлгән.

Фикер қыйлды бер күрүб лақын,
Таш дорды бер-беренә чалықын.

Дашы бер-бер йәнә тотды қуына[23],
Чақмақы[24] алды йәнә бер эленә[25].

Орды дашы – чықды ут, дөште қуа[26],
Суықлық дәрденә ут булды дәва.

Шөкер Хақға әйләде ут йандурыб,
...[27]

Ут қашында[28] ултуруб қылды фикер,
*25а кәгазь* Тәңренең рәхмәтенә қыйлды[29] шөкер.

«Аллаһ[30] дашда[31] қуәтемез беркетеб,
Йарлықайуб бирде мәңа ирек итеб.

Бу ут мәңа бақи кәрәк булғучы,
Та қыйәмәт ғаләм эчрә қалғучы», –

Диде. Берлек бу эшне бетерделәр:
Таш-тимерлә қу уты килтүрделәр.

---

[23] Әлеге сүз кулъязмада «қуы» дип теркәлгән. Бу сүзнең алдында «билә» (бөйлә) дип язылган сүз артык.
[24] Кулъязмада бу сүздәге «қаф» хәрефләренең өсләрендәге нокталары куелмаган.
[25] Кулъязмада бу сүздәге «н» хәрефенең ноктасы куелмаган.
[26] Кулъязмада «ут» сүзе урынында «уты» дип, «қуа» сүзе исә «қу» дип язылган.
[27] Бу бәйтнең икенче юлы кулъязмада теркәлмәгән.
[28] Бу сүзнең ахырындагы «а» хәрефе кулъязмада теркәлмичә калган.
[29] Кулъязмада бу сүзнең соңгы хәрефе төшеп калган.
[30] Кулъязмада бу сүз алдындагы «ут» сүзе артык. Күчерүче 19 нчы бәйт башындагы сүзне генә ялгыш кабатлап язган булган.
[31] Кулъязмада бу сүзнең «да» ижегеннән соң ялгыш «н» хәрефе теркәлгән һәм сызылган.

Кем дорырса, йари илә берегеб,
Һәр эше асан қыйла туғры торуб.

Берлек эше[32] Хақ қатында асан табар,
...[33]

Йа, Илаһи, күргүзгел берлек йулый,
Рәхмәтеңлә йарлуқа Мәүла Қолый.

Сүзләрүмнең разуына, әй, Ғәни[34]
Бу ғыдайы йийеб ...[35] қыйлғани.

***

*25б кәгазь* Дорды Адәм, йулына керде рәван,
Суықлықдин қотылыб, булды әман[36].

Йөрде андин таба ул Кәғбә йулын,
Тәваф[37] қыйлды ул «Бәйтел-мәғмүр» эвен.

Диде Адәм: «Йа, Иляһи, Раббәна!
Сәнсән мәңа бақида пөштипәнаһ[38].

Рахмәнсән сән, зилләтдин арығ қыйлан,
Нә дәйүрсәң[39] – әмрең илә эш қылам.

---

[32] Кулъязмада бу сүзнең алдында язылган «бер кийән» гыйбарәсе артык. Бу сүзләр, бәлки, «береккән» дип язылсы булып, күчерүче тарафыннан «берлек эше» дип теркәлгәндер.
[33] Бу бәйтнең икенче юлы җыентыкта язылмыйча калган.
[34] Кулъязмада «әй, Ғәни» сүзләре юк, текстка безнең тарафтан өстәлде.
[35] Кулъязмада икенче сүздәге хәрефләрнең барлык нокталары да куелмаган. Шуңа күрә, әлеге сүзтезмәне «боғдай сибеб» дип тә укырга мөмкин. Бу юлның уртасындагы бер сүз кулъязмада теркәлмәгән.
[36] Кулъязмада бу сүз урынында ялгыш «имам» дип язылган
[37] Кулъязмада: «тауваб».
[38] Кулъязмада: «бөштибәнаһ».
[39] Кулъязмада башта «дәйүрсән» дип теркәлеп, «сән» өлеше сызылган һәм «сәң» дип язылган.

Бу эү эчрә нә қылайын – дигел сән?!
Әмереңә жанны нишар қыйлам мән».

«Жәбраил вә йөрүб әйдең, варғыл дуд,
Зәғифемгә виргел сәлам-у-дөруд.

Әмерне дотсун – аңа бойырайын,
Андин соңра рузықын мән бирәйен.

Әмрем ике рәкәғәт сөннәт[40] аңа,
Ул эү эчрә[41] қылсун ул сәждә мәңа.

Ике рәкәғәт йәнә фарыз қылсун,
Ризқ-у-нәфәқәсене мәндин булсун.

*26а кәгазь* Түрт рәкәғәт йәнә бойурдум тағат[42],
Ул эү эчрә[43] қыйлмаға итсүн ғәдәт».

Қылды Адәм ул эү эчрә тағате[44],
Һәр сәхәр сәждә қылмақ ғадәте.

Қыйлды әмер Жәбраилгә Изем Ғәни:
«Адәмә[45] күргүз эшен, әйдүм сәни.

Жәннәтдин илт туқыз қуйны Адәмә[46],
Сәне қуштум Адәм өчүн ярдәмә[47].

---

[40] «Әмрем» сүз кулъязмада «әмер қылдум» рәвешендә язылып, төзәтелгән; «сөннәт» сүзе хаталы теркәлгән.
[41] «Эү» сүзе кулъязмада «йү» рәвешендә теркәлгән, «эчрә» сүзе «әрчерә» рәвешендәрәк, хаталы итеп язылган.
[42] Кулъязмада бу сүз алдында теркәлгән «аңа» сүзе артык.
[43] Кулъязмада бу сүзнең соңгы хәрефе төшеп калган.
[44] Кулъязмада бу сүзнең соңгы хәрефе теркәлмәгән.
[45] Кулъязмада бу сүзнең соңгы хәрефе язылмаган.
[46] Кулъязмада «қуйны» сүзе хаталы теркәлгән, «Адәмә» сүзенең соңгы хәрефе язылмаган.
[47] Кулъязмада бу сүзнең соңгы хәрефе төшеп калган.

Йәнә алғыл өч әвүн боғдай аңа,
Әмер қыйлдум – һәр эши күргүз аңа.

Қылсундур сәнеңдәй әмре. Қуйлари
Итен жыйсун, җонын[48] итсүн танлари.

Әйт сән[49]: «Урың боғдайы йәнә игеб,
Рәхмәтемдин теләсүн йиргә сибеб.

Боғдай мәндин торур бу туйдырмаға,
*26б кәгазь* Җан сөрсен данә илә тудырмаға.

Зәғифемгә боғдай[50] ниғмәт буласы,
Әмәлләйә[51] та қийамәт қыйласы».

Җәбраил Хақ әмрилә җәннәтә варуб,
Боғдай, қуйлар Адәмә[52] кәлде йөрүб.

Боғдай-у-қуййы Адәмға кәлтүреб,
Дөруд[53] илә Хақ сәламен тигүреб:

«Йимәк-ү-кимәкеңдин булмаз мәлял,
...[54]

Боғдайы йарағ илә[55] икмәк кәрәк,
Бу эше берегеб қылсаң – игүрәк».

---

[48] Бу сүз кульязмада «җанварлар» дип, ялгыш язылган.
[49] Кульязмада бу сүзләр «әтсүн» дип, хаталы язылган.
[50] «Зәғифемгә» сүзе кульязмада хаталырак теркәлгән. «Боғдай» сүзендәге «йа» хәрефе кульязмада «лы» («ле») кушымчасына охшаш итеп язылган.
[51] Бу сүздәге «м» хәрефе кульязмада «х» рәвешендәрәк теркәлгән. Аның дөресе «гамәл» (әмәл) сүзеннән булып, «эшләргә» мәгънәсен белдерә.
[52] Бу сүзнең соңгы хәрефе кульязмада теркәлмәгән.
[53] Кульязмада бу сүз ялгыш «дүр» дип язылган.
[54] Бу бәйтнең икенче юлы җыентыкта язылмаган.
[55] Кульязмада «йарағ» сүзе «йарығ» рәвешендә, «илә» теркәгече «зәйнә» дип, бозып язылган.

Диде Адәм: «Әй, әхи! Дигел мәңа,
Берегеб кем үзеңә[56], сорам сәңа».

Диде: «Берегеб, дәмүр-ағач[57] бер қыйлыб,
Көчай күтәрмәң, қуш бер хәйванә телеб[58].

Дорды Адәм, дәмүр-ағач бер қыйлды,
*27а кәгазь* Иб чарыды, хәйван йирене телде.

Боғдайны андин Адәм йиргә тигеб
Қуйды, «Урның булсын», – диб, туфрақ сибеб.

Диде Адәм: «Йа, Раббым, Кәрим, Сөбхан!
Сәндин торур бу булған җөмлә ихсан[59].

Бу боғдайға рәхмәт сәндин буласы,
Әмрең илә боғдай[60] эшкә киләсе.

Шул сағәт күккә Изем[61] қылды әмер:
«Боғдаййы өндүмәгә виргел йағмур!»

Инде[62] күкнең[63] мәхәббәте һәм йағыш,
Ул йағышдин туфрақ эче булды жуш.

Күк мәхәббәте бер йағмур индереб,
Йир боғдай вирде шул[64] сағәт өндүреб.

---

[56] «Үзеңә» сүзе кулъязмада «дүреңә» дип, бозып язылган.
[57] «Дәмүр» сүзе кулъязмада «дүр» дип ялгыш язылган, «ағач» сүзе «ағачы» дип теркәлгән.
[58] Кулъязмада соңгы ике сүзнең урыннары алыштырып, «телеб хәйванә» дип теркәлгән.
[59] Кулъязмада бу сүзнең «с» («син») хәрефе теркәлмәгән.
[60] Бу сүз кулъязмада хаталы рәвештә «боғады» («бу ғади») дип теркәлгән.
[61] Кулъязмада бу сүздәге хәрефләрнең нокталары куелмаган.
[62] Кулъязмада бу сүзнең соңгы хәрефе теркәлмәгән.
[63] Бу сүздәге «нең» кушымчасы кулъязмада шактый хаталы теркәлгән.
[64] Кулъязмада бу сүз юк, текстка безнең тарафтан өстәлде.

Боғдайы йыйыб Адәм һәм дөгеб,
Он әйләде һәм җәү эчендән өгеб.

*27б кәгазь* Асийабдин асиб, қыйлды аны хәмир,
Бешермәгә әйләде анда тәнвир.

Тағәм қыйлды аны ул дәм бешереб[65],
Йимәгә теләде Адәм әлен сузыб[66].

Җәбраиле[67] изды Хак Изем Ғәлләм:
«Зәғифемға тигүргел мәндин сәлам!

Рузә тотсун, кичә дикен йимәсен,
Хаҗәте нәдүр – мәндин ул[68] теләсүн!

Сөчене кичүрүбән, қыйлдум сафа,
Рәхмәтемә қылсун ул шөкр-ү-сәна!

Йәнә қуйам аны мөйәссәр җәннәтә[69],
Ғәрек қылам һич кимемәз[70] рәхмәтә».

Рузә тотуб, кичә ағыз ачты Адәм,
Хақға шөкер қылды һәм йиде тағәм.

*28а кәгазь*[71] Хақ әмрилә тағәм йийеб[72], шөкер итеб,
Хыйал қыйлды Хақ қөдрәтен ул көтеп[73].

---

[65] «Ул дәм» сүзтезмәсе кулъязмада «өндүм» («уйдум») рәвешендә теркәлгән. «Бешереб» сүзенең соңгы хәрефе кулъязмада төшеп калган.
[66] Бу сүз кулъязмада хаталы язылган.
[67] Кулъязмада бу сүзнең соңгы хәрефе язылмаган.
[68] Кулъязмада «мәндин» сүзе ике мәртәбә кабатланган. «Ул» сүзе кулъязмада юк, текстка безнең тарафтан өстәлде.
[69] Бу сүзнең соңгы хәрефе кулъязмада теркәлмәгән.
[70] Кулъязмада бу сүз ялгыш «кимәз» дип язылган.
[71] Кулъязманың бу кәгазе башында җиде юл – 51 нче бәйтнең икенче юлыннан алып, 54 нче бәйтнең икенче юлына кадәрге текст ялгыш кабатлап күчерелгән.
[72] Бу сүз кулъязмада «бәйт» («бит») рәвешендә теркәлгән.
[73] Бу юлдагы соңгы сүзләр кулъязмада теркәлмәгән, «ул көтеп» гыйбарәсе безнең тарафтан өстәлде.

Диде Адәм: «Дидем шөкерем[74] Сәңа,
...[75]

Берегеб бирдең һәрберене Сән қуша,
Берекмәкдин бу ниғмәт килде эшә.

Дәмур-ағач берегеб, иб хәйванә[76],
Күкдин йағмур инде – йир бирде данә».

*28б кәгазь* 70 Хақ диде: «Мәңа нәслең туарасы,
Һәм анлара бу эш белә қаласы».

Береккәннең һәр эше бөйлә була[77],
Береккәннәр эшен Хақ асан қыйла.

Береккәнлек[78] биргел сән Мәүля Қола,
Тағәтеңне қыйлмаға Изем ғайна.

73 Сәндин тәүфиқ теләйүр ғасый қолың,
Рәхмәтеңлә күргәзгел қоллық йулың[79]!

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Булды суык, исте җилләр һәм каты,
Бөгелде Адәм, калмады һич тәкате.

Диде Адәм: «Йә, Раббым! Тиде үлем.
Синнән башка кем белер минем хәлем?

---

[74] Кулъязмада «шөкер» дигәч ялгыш «қыйлды» дип язылган сүзне күчерүче үзе сызган һәм ахырына «м» хәрефен өстәгән («шөкерем»).
[75] Бу бәйтнең икенче юлы җыентыкта язылмаган.
[76] Кулъязмада бу сүзнең соңгы хәрефе теркәлмәгән.
[77] Кулъязмада: «буласы».
[78] Кулъязмада: «бер күңел».
[79] Соңгы сүз кулъязмада теркәлмәгән, текстка безнең тарафтан өстәлде.



*Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «8687т» шифры белән саклана торган кульязма. 24а кәгазь*


سو قیلقلارسن ایلوم حال ایدی کیلدوم نیچه دیب قسودین اوان کیلدی
اوطبر حلا قوتولیق سبب بولمدی قیلدیسنه قویوب دوردی بر سساری
چقماق الب ایم آنکلا قیلدی یاری
دیدی آدم ای چقماق اوطبر بیسنه
جاقلابر رحیم تنکری اطق جاقمقدین بولمادی قیلسنا
جاقمقدین بولمادی انده هیچ چاره منه
بواتش الحده بولدی آدم اوبر ا
فکر قیلدی بر کسوروب لاقالین منه
تاشنی دوزدی بر سببینه جاقلین
داشنی بر بیت تیدی بلیه قوی
جاقمقی الدی بیشه برالی نه
اوددین داشنی چقلدی اوطی دوشتی قو
شقلق دردینه اوطلا بولدی دوا
تنک حصه الیدی اوطیانلاوری
اوطلار ماننده اوستوروب قلدی فکر
تنکریکه

*24б кәгазь*


25
حكر بيك رحمتيله قيلانينك
اوطه الله دارغه اشتوا قوتمر بيرسين
يارلقايوب بردى منكا ايرك ايتب
بو اوطه منكا باقى كرك بولغوسى
تا قيامت علام اهرش تاللو عى
ديرى برلك بو اشنى بتردىلار
تا ايشى تمت له قو اوطه كيلتوردىلار
كم دود ودسه يادك ايله بر كيب
هر اشنى اسان قيلاتوعى تودرب
بر كيان برلك اشنى حق تا تسده ساء
تبار
يا الهى كور كورن كل برلكيدى
رحمتنكله يارلوتا هوعلى قعو ل
سولالادرم نشه رلاقو نيه
بو عرادسب قهقا نى
ى

*25а кәгазь*

دوردی اکرم یولینه کردی روان
سفر قیلغه دیدی قیل طلب بولادی امام
یر دمی اندیدی تا به دول کعبه یولی
طواف قیلدی اول بیت اطیفور اتوش
دیدی اکرم یا الهی ربنا
سن سن ذلتلیک الیدی قیلاش
نه دیور رسول سن امتیکل ایله اتشدی قیلام
بو ایشراهره نه قیلاسن دیکل سن
امتیکل ابجا سن نشان قیلام من
حبیب اکل وسیت وبلا الیدی واجعل دوزخ
عفیمه وبیکل اسلام دورد
امی نه دو تنبوت انکا بیور بیدی
انداین صونکره روزقیل من براید
دقیل ور ایکی رکعت کتیلا النماز
اول یوارج اقلیدی اول سحله
توتج

*25б кәгазь*

26

تورت رکعت بینه بیوردوم الکا طاعت

اوّل ایوراهم قیلیچما اتیسونی عادت

قیلدی آدم اولا ایوا احمد اطا عت

نوح سجده قیلماقی عادتی

قیلدی ام جیبیت الکل کا ایلدم عائشه

آدم کورکوران الشت ایلدوم سنی

جنتدین ایلت توقن قیدین آدم

سنی قوشتیدم آدم اوچون یاردم

بینه العلا وج اوچون بو عدی اسلا

اهم قیلیدوم طوا ایشنی کورکوران النا

قیلسونا دوا لنکدی ام کی قولیلاری

ایتیا جیسون جینورلار اتسون طالنلار

اتسونا اولنک بلجدای بینه ایکب

رحمتدین تیلاسون نکا سبب

بو عدای مندین تیرور بو حلورتدورمه

*26а кәгазь*

جان سرسن دانه ایلیه توور بیله
حقیقتده بو حدالی نعمت بولاسی
احلیه تا قیامت قیلاسی
جبت ایرکل حقا امر بیله جنته وار ور
بو حدالی قویلار ادم کلماری یورب
بو حدی قوش الله دمعه کلتورب
دورا ایلیه حق سلامین تکورب
بیحکو کیتکو تکدیب بولمن بلال
بو علالی بر یلانینه ایکمکی سن ال
بو الشی برکبب قلدا تکی ایکورالی
دیدی ادم ای احی دیکید امتانه
برکبب کیم دوور نکاسورا ادم سنی
دیدی سن برکب دورا اعاجین قیلب
کوچی کوتارمنکی قوش بیشتب نه حیوانه
دوردی ادم دا امورا اعاجین قیلدی
ایر

26б кәгазь

27

ایب چاردی حیران بیرینچه تلدی
بو عدا اینی اندین آدم کا تیکیب
قویدی اونك بولسون دیب توفراق سبب
دیدی ادم یارانسیم کیتسین سبحان
سندین تورور بو بو بعان جمله جان
بو عداین رحمت سندین بولاسی
امرینك ایله بو عمادی اشلاکیلاسی
شوندن ساعت کوکیلا ادم قلدی امر
بو عدای اوندو ملکا ویرلک ایلیور
ایند کوکلکه محبت بو یعشش
اون یعشدین توفراق ایچی بولدی خمیرش
کوکی محبت بر ییمور ایشد رب
یی بو عدای ویردی ساعت اوندو رب
بو عدای پیب ادم دوکمب
اوش ایله دن بو حوا چیندان اوکسب

27а кәгазь

ایسا بو یت اسیب قیلوری اشنی حجر
بشنی مللا ایلادی انلاه شنور
طاعم قیلوری انه اولدوم بشنی
بیملا تلادی ادم الله الدب
جبن ایکل الیذی قق ایلم علام
صفیمه تیکور کل انیسا سلام
روزه تو تشوه کچه دیکلا بیمس
ه جتنی نذور مندسی مندین تلاسا
سه جنی کیجوروبن قیلدیم صفا
رحمه قلسون اول شکر شنا
بیز قویام انه هیی بهشت
ی ق قلام سایح کیمن رحمته
روزه تو توب کچه ای احتی ادم
حقه ام ایلی
حقعه شکر قیلدی هم پیدی طعام.
تم

*27б кәгазь*


28

ایت چاردی چیغاردی بیت تلوری

بو عجدری بنی سندیتیا ادم ایکلب

قید بید سکم و وسنق بو لسون

دیدی ادم یارب سبحان

سندیتیا ترو ربو بولکان جمله احان

بو بو عجدا ایب رحمت سفی بوانسی

امرینگ ایله بو عجدانی انستکا کیلانسی

حق امریله طعام بیت شکر ایتیب

حیال قیلدی حق قدرتنی

بلکا دیدی ادم دیدم شکر قیلدیم

کیب بر دیکمانی بار انیه سنی قوارشا

بکلدی بو نعمت کیگدال ستا

دامور اماج کیب ایب خیون

کوکدین یلیمور انیزدی بیر دی داشه

*28а кәгазь*

خفا دیدن مناسب لیکن طور اسی
هم اتلاره بر اشنی بیلیه قالاسی
کیلکلایسنکز هر اشنی بیلیه بولاسی
بر کیلکلا تیلار اشنی حق اسان قیلیه
بر کونلیلار بیز کلکل سین صعولی قیولا
طاعتکنی قیلیه ابدام کیتنا
سندین توفیق تیلابیز دعا ی قیلیکن
رحمتکله کیوزا کیز بلکل تمل للق
تمت تمام
بسم الله الرحمن الرحیم
حمد قیلیل حق یادن ایتیما قلقفه
نوظم فقسیح
بسم الله الرحمن الرحیم

*28б кәгазь*

Ут Син бирче ягып җылынырга,
Бу суыктан ничек тә котылырга».

Диде Аллаһ: «Бел, Адәм, бәндәлегең,
...[80]

Таштан утны кудым шак-шак итеп,
Ку һәм тимер агач белән беркетеп.

Алардан утны теләп ал инде син,
Алуыңны әмер кылдым инде мин».

Алды Адәм ул заман ташны табып,
Таштан ут теләде ул зари кылып.

Тыңла инде ачык Адәмнең зарын,
Ут чыгарып һич күрсәтмәде нурын.

Куйды ташны һәм куны алды янә,
Тәңре исмен яд итеп, кылды сәна[81].

Диде: «Әй, ку! Ут бир миңа, егылдым,
Суыклыктан үлем хәлгә бөгелдем».

Күпме әйтсә кудан аваз килмәде,
Ут бирергә сүздән сәбәп булмады.

Куны янә бер якка куеп торды,
Чакма алып һәм аңа зарын кылды.

Диде Адәм: «Әй, чакма! Ут бир сәнә?
Тәңре атын хаклап, рәхим кыйл сана?»

---

[80] Бу строфаның икенче юлы җыентыкта язылмыйча калган.
[81] *сәна* – мактау, шөкер.

Чакмадан булмады анда һич чара,
Бу эш белән булды Адәм әүвәрә.

Фикер кылды урынын бер күреп,
Таш торды бер-беренә бәрелеп.

Ташны бер-бер янә тотты куына,
Чакманы алды янә бер кулына.

Орды ташны – чыкты ут, төште куга,
Суыклык дәртенә ут булды дәва.

Хакка шөкер итте ул ут яндырып,
...[82]

Ут каршында утырып кылды фикер,
Тәңренең рәхмәтенә кылды шөкер.

«Аллаһ ташта куәтебез беркетеп,
Ярлыкап бирде миңа ихтыяр итеп.

Бу ут миңа мәңге кирәк буласы,
Кыяматкәчә галәмдә каласы», –

Диде. Бергә бу эшне бетерделәр:
Таш-тимер һәм ку утны китерделәр.

Кем торса ярдәм белән берегеп,
Һәр эшне ансат кыла тугры торып.

Берлек эше Хак каршында җиңел табар,
...[83]

[82] Бу строфаның икенче юлы кульъязмада теркәлмәгән.
[83] Бу строфаның икенче юлы җыентыкта язылмаган.

Йә, Илаһи, күрсәтче берлек юлы,
Рәхмәт итеп ярлыка Мәүла Колый.

Сүзләремнең серләренә, Илаһи
Бу ризыкны ашап ...[84] кылганы.

***

Торды Адәм, юлына керде тәмам,
Суыклыктан котылып, булды әман.

Йөрде аннан, тапты ул Кәгъбә юлын,
Тәваф кылды ул «Бәйтел-мәгъмүр» өен.

Диде Адәм: «Йә, Раббыбыз, Илаһым!
Синсең миңа мәңгелеккә ярдәмчем.

Рәхимле Син, гөнаһлардан пакь кылган,
Нәрсә дисәң – әмрең белән эш кылам.

Бу өй эчендә ни кылыйм – әйтче Син?!
Әмереңә җаным фида кылам мин».

«Җәбраил, барып әйт син һәм бар тиз[85]
Зәгыйфемә дога тапшыр, сәлам бир.

Әмерне тотсын – аңа боерырмын,
Аннары соң насыйбын мин бирермен.

Әмрем – ике рәкәгать сөннәт аңа,
Ул өй эчендә кылсын ул сәҗдә миңа.

---

[84] Бу юлның уртасындагы бер сүз кулъязмада теркәлмәгән.
[85] Кулъязмадагы төп текстта «дуд» диелгән бу сүзнең мәгънәләреннән берсе «сулыш». Шул сәбәпле, сулыш алган вакыт кебек тиз арада бару күздә тотылган дип тәрҗемә иттек.

35 Ике рәкәгать янә фарыз кылсын,
Насыйп ризык-өлешен миннән тапсын.

Дүрт рәкәгать янә боердым тәгать[86],
Ул өй эчендә кылырга итсен гадәт».

Кылды Адәм ул өй эчендә тагатен,
Һәр таңда сәҗдә кылмак гадәтен.

Кылды әмер Гани[87] Аллам Җәбраилгә:
«Адәмгә күрсәт эшен, әйттем сиңа.

Җәннәттән илт тугыз куйны Адәмгә,
Сине куштым Адәм өчен ярдәмгә.

40 Йәнә ал син өч башак бодай аңа,
Әмер кылдым – һәр эшне күрсәт аңа.

Кылсын ул синдәй эшләрен. Куйларның
Итен ашап, кием итсен йоннарын.

Әйт син: «Ур-җый бодайны янә игеп,
Рәхмәтемнән теләсен җиргә сибеп.

Бодае миннән булыр туйдырырга,
Җан сөрсен бөртек белән тутырырга.

Зәгыйфемә бодай нигъмәт буласы,
Хезмәте кыяматкәчә каласы».

45 Җәбраил Хак әмере белән барып,
Бодай, куйлар Адәмгә китерде йөреп.

[86] *тәгать* – намаз.
[87] *Гани* – бик бай, байлыгы кимеми торган зат (Аллаһы Тәгалә).

Бодай һәм куйны Адәмгә китереп,
Дога белән Хак сәламен җиткереп:

«Ашау һәм киюеңнән булмас борчу,
...[88]

Бодайны корал белән игү кирәк,
Бу эшне бергәләп кылсаң – җиңелрәк».

Диде Адәм: «Әй, кардәш! Әйтче миңа,
Берегеп ки үзеңә, сорыйм сиңа».

Диде: «Бергә тимер-агач бер кылып,
Авыр күтәрмә, сөр бер хайванга кушып.

Торды Адәм, тимер-агач беркетте,
Бау бәйләде һәм хайван җирен сөрде.

Бодайны аннан Адәм җиргә чәчеп
Куйды, «Урның булсын», – дип, туфрак сибеп.

Диде Адәм: «Йә, Раббым, Кәрим, Сөбхан[89]!
Синнән тора бу булган барлык ярдәм.

Бу бодайга рәхмәт синнән буласы,
Әмрең белән бодай эшкә киләсе.

Шул сәгать күккә Раббым кылды әмер:
«Бодайны күтәрергә бир син яңгыр!»

Иңде күкнең мәхәббәте һәм яуды,
Ул явымнан туфрак эче кайнады.

[88] Бу строфаның икенче юлы җыентыкта язылмаган.
[89] *Рабб* – ике дөньяның хуҗасы, тәрбиячесе, *Кәрим* – юмарт зат, *Сөбхан* – һичбер кимчелексез, бөек (Аллаһы Тәгаләнең күркәм исемнәре).

Күк мәхәббәте бер яңгыр иңдереп,
Җир бодай бирде шул сәгать күтәреп.

Бодайны җыеп Адәм сугып-төеп,
Он итте бөртекләр эченнән өеп,

Тегермән тартып, кылды аны камыр,
Ясады пешерергә дип мич-тандыр.

Тәгам кылды аны шул чак пешереп,
Кабарга теләде Адәм кул сузып.

Җәбраилне юллады Аллаһ-Галләм[90]:
«Зәгыйфемә ирештер миннән сәлам!

Ураза тотсын, төнгәчә ашамасын,
Хаҗәте нидер – миннән ул сорасын!

Гөнаһларын кичереп, кылдым сафа,
Рәхмәтемә кылсын ул шөкер-сәна!

Янә куям аны кулай җәннәткә,
Насыйп итәм һич кимемәс рәхмәткә».

Ураза тотып, төнлә авыз ачты Адәм,
Хакка шөкер кылды һәм җыйды тәгам.

Хак әмре белән ашап, шөкер итеп,
Хыял кылды Хак кодрәтен ул көтеп.

Диде Адәм: «Әйттем шөкерем сиңа,
...[91]

[90] *Галләм* – иң күп белүче (Аллаһы Тәгалә).
[91] Бу строфаның икенче юлы җыентыкта язылмаган.

Һәрберсен Син кушып берегеп бирдең,
Береккәннән бу нигъмәт эшкә килде.

Тимер-агач берегеп, бау хайванга,
Күктән яңгыр иңде – җир бирде ярма».

70 Хак диде: «Миңа нәселең тотасы,
Һәм аларга бу эш беләң каласы».

Береккәннең һәр эше шулай була,
Береккәннәр эшен Хак җиңел кыла.

Береккәнлек бир син Мәүла Колыйга,
Боер Аллам гыйбадәтең кылырга.

73 Синнән тәүфыйк тели гөнаһлы колың,
Рәхмәтең белән күрсәт коллык юлың!

## «Дәрвишләр сохбәтендә»

Мәүла Колый иҗат иткән бу хикмәтнең хәзергә бер күчермәсе табылды.

Кулъязмада «Хикмәте хәким» дип аталган бу шигырь тексты ун строфадан тора, тугызынчы строфаның бер юлы теркәлмәгән. Текстның ике урынында – 4 нче һәм 10 нчы строфаларында авторның исеме – Мәүла Колый дип күрсәтелгән.

Бу шигырь мәшһүр суфи шагыйрьләр Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакырганиларның шундый ук калыптагы хикмәтләренә нәзыйрә рәвешендә иҗат ителгән. Күзаллау өчен әлеге ике авторның текстлары да түбәндә тәкъдим ителде.

Һәр строфасының ахыры «дәрвишләр сохбәтендә» дип кабатлана торган сүзләр (рефрен) әүвәл Ясәви хикмәтендә кулланылган. Аның тексты сигез строфадан тора. Ә шул хикмәткә ияреп, үз шигырен иҗат иткән Бакырганиныкы

алты строфалы һәм аның тестындагы рефрен бер иҗеккә озынрак – «дәрвишләрнең сохбәтендә» рәвешле. Сөләйман Бакыргани хикмәте Әхмәд Ясәвинекенә бик якын, анда Ясәви текстындагы гыйбарәләр генә кулланылган диярлек: сүзләре бераз гына үзгәртелгән һәм кайбер юлларның урыннары алмаштырылган. Ясәви хикмәтендәге 5 нче һәм 7 нче строфалар Бакыргани текстындагы 4 нче һәм 5 нчегә тәңгәл килә. Аларда бары тик берничә хәреф кенә башкача. Бәлки Ясәвинең бу хикмәте иске кулъязмаларда күчереп йөртелеп, бераз үзгәргән һәм кыскарган рәвештә, Бакырганига ялгыш нисбәт ителгән булгандыр дип тә уйларга мөмкин.

Монда М.Колый хикмәтләре теркәлгән башка бер җыентык турында Ш.Абилов язган мәкаләне искә алу зарур. Анда сүз 1969 елда галимнәр карамагына тапшырылган һәм «Кизләү җыентыгы» дип исемләнгән кулъязмадагы бер хикмәт турында бара: «...Анда 12 юл гына. Ул:

Ирәннәр мөхфилендә нур ягар сөхбәтендә,
Ни теләсә ул булыр дәрвишләр сөхбәтендә, –

дип башлана һәм:

Мәүла Колый, тәүбә кыл, хикмәт әйтмәй, хәлең бел,
Кол Гобәйди хикмәтен җандин гаҗиз тотарым, –

дигән юл белән тәмамлана.

Бу шигырь Мәүла Колыйның хикмәтләр диванында тулысынча юк, тик аның соңгы ике юлы гына бар. Әмма бу ике юлны эченә алган хикмәт биредә һәм формасы, һәм эчтәлеге белән бөтенләй башка. Кизләү җыентыгындагы хикмәт «Бакырган» китабына һәм Ясәвинең «Диваны хикмәт»енә дә кергән. Ләкин ул аларның берсендә Кол Сөләйман, икенчесендә Хуҗа Әхмәт [Ясәви] исеменнән сөйләнә. Күрәсез, бер үк әсәр өч җыентыкта өч төрле авторныкы итеп бирелгән. Бу – әсәрне күчерүчеләр хатасымы? Әллә бер шагыйрь икенче бер каләмдәшенең шигъри юлларыннан шулай файдаланамы? Чынлыкта аны кайсысы иҗат иткән? – Хәзергә билгеләве читен»[92].

---

[92] Абилов Ш. Мәүла Колый хикмәтләренең яңа кулъязмасы // Казан утлары. – 1971. – №6. – Б. 150–151.

Абилов мәкаләсенә иллюстрация итеп журналның 148 битендә «Мәүла Колый хикмәтләренең Кизләү кулъязмасыннан үрнәк, 15 бит кәгазь» дип бирелгән, нәкъ шушы хикмәт язылган битнең фотокүчермәсе мәсьәләне тулырак күзалларга ярдәм итә. Тексты дүртәр юллы 6 строфадан тора. Аның күбрәк строфалары С.Бакыргани хикмәтенә якын булса, бишенче строфасы Ясәвинеке, ә соңгы – алтынчысы («Мәүла Колый, тәүбә кыл...») М.Колыйныкы. Бу текстта Ясәви һәм Бакыргани китапларында басылган хикмәтләрдән аермалырак урыннары бар. Мәсәлән, Ясәви китабындагы рефренда «дәрвишләр» диелгән, ә «Бакырган китабы»нда «дәрвишләрнең» дип язылган. Кизләү җыентыгындагы төп текст С.Бакырганича булса да, рефрены «дәрвишләр» дип теркәлгән. Дүртенче һәм бишенче строфаларның ахырларында «дәрвишләр» сүзе урынында шундый ук мәгънәдәге «хәл әһле» сүзләре теркәлгән. Гомумән, Кизләү кулъязмасындагы хикмәтнең тексты төрле чыганаклардан алынып, кыскартылганлыгы аңлашыла. Ул башлангычта өч автор исемнәренә бәйле шундый шигырьләр булганлыгын белгән хәлдә, телдән-телгә сөйләнеп һәм көйләнеп килгән популяр мөнәҗәтләрдәге кебек үк, үзгәреп халыклашкан вариантка охшаш. Мәкаләдә телгә алынган «Мәүла Колый, тәүбә кыл...» дигән текст өлеше аның «Дәрвишләр сохбәтендә» хикмәтенең дүртенче строфасындагы «Мәүла Колый, тәүбә кәрәк» дигәненә бик якын.

Шунысы мөһим – безнең бу китапта бирелә торган, эчтәлеге, төзелеше һәм күләме ягыннан Ясәви белән Бакыргани текстларыннан аермалы хикмәтнең өч (беренче, дүртенче һәм соңгы) строфасында иҗат итүчесе Мәүла Колый дип күрсәтелгән. Димәк, монысының авторлыгы турында бәхәскә-шиккә урын юк.

Мәүла Колый хикмәте, әйтеп үткәнебезчә, күләмлерәк һәм аермалырак, аны элгәреләрнең текстлары белән, нигездә, төп теманы билгеләгән рефрен бәйли. М.Колый хикмәтенең ахыргы – унынчы строфасында Бакыргани күздә тотылып,

«Кол Сөләйман» дип аталып, ике суфи шагыйрьнең үзара рухи һәм иҗади бәйләнешләре белдерелгән.

Шигырьнең тексты Россиядә XIX гасыр уртасында эшләнгән, 17,5х21 см үлчәмле кәгазьдәге җыентыкта гарәп язуының нәстәгъликъ төрендә, караңгы көрән төстәге язу карасы белән теркәлгән. Әлеге җыентыкта шулай ук Раушаниның «Чубаннамә» әсәре, Ниязи һәм Шәриф Локман шигырьләре, «Тәркиб» китабы, дини риваятьләр, фикъһ мәсьәләләре, «Бакырган китабы»ннан хикмәтләр тупланган. Кульязмада авторы күрсәтелмәгән «Рухел-әмин» шигыренең авторы да М.Колый булуы ихтимал дип фаразладык. Аның тексты шушы китапның өченче бүлегендә урнаштырылды.

Җыентыкның күчерүчесе һәм иясе Уфа вилаятенең Имән авылы кешесе Мөхәммәтхан Төхфәтулла улы икәнлеге язылган. Ул кульязманың Шәмсемөхәммәд бине Исламколый мәдрәсәсендә күчерелгәнлеген теркәп куйган.

Сакланышы уртача хәлдәге бу кульязма җыентык хәзерге вакытта Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «8689т» шифры белән саклана. Аны Татарстанның Мөслим районындагы Яңа Сәфәр авылында Лотферахман Габдрахман улы Габдрахмановтан (1911 елда туган) археограф галим Альберт Фәтхи 1972 елда алган. Шуны белдергән мәгълүмат кульязманың 47а кәгазендә А.Фәтхи тарафыннан зәңгәр төстәге кара белән гарәп хәрефләрендә «АЭ-1972...» дип башлап язып куелган.

Кульязмадагы текстның палеографик үзенчәлекләренә килгәндә, иң әүвәл аның, шигъри әсәрләргә хас булганча парлы (ике яисә дүрт) багана рәвешендә теркәлмичә, өч багана итеп язылганлыгын әйтергә кирәк. Бу исә бары тик кәгазьнең язу мәйданын мөмкин хәтле файдалы куллану ысулы гына булган.

Текстта иң күп кабатланган «сохбәтендә» сүзендәге «сад» хәрефе өстенә һәр очракта да нокта куелган һәм ул «зъад» («дад») хәрефенә әйләнеп, «зохбәтендә» буларак укы-

ла. Бу, әлбәттә, күчерүченең хатасы гына. Бәлки ул кулланган протографта «сохбәтендә» сүзенең «х» хәрефе өстендә нокта куеп язылган булып, әлеге хата шуннан килгәндер. Гәрчә бу сүздә ноктасыз «х» хәрефе язылырга тиешле булса да, иске кульязмаларда андый ялгышлар күп очрый.

Аерым очракларда «уау» хәрефе өстендә өчәр нокта куелган, «ч» хәрефе урынына «җ» язылган. Бу хикмәт теркәлгән кульязма текстында хаталар чагыштырмача аз. Булганнары астөшермәләрдә искәртелде.

Тексттагы «һу-һу кошы» һәм «Һу, Һу» дәйүр һу-һу кошы» дигән гыйбарәләрдә ябалак (байгыш) күздә тотылган. Әлеге кошның «һу» дигәнгә охшаш тавыш белән кычкыруы аның шулай аталуына сәбәп булган. Суфичылык әдәбиятында «Һу» (ул) сүзе Аллаһы Тәгаләне белдергән. М.Колыйның шушы «Дәрвишләр сохбәтендә» хикмәте теркәлгән кульязмадагы «Рухел-әмин» шигыре текстындагы «Һу» сүзе нәкъ менә соңгы мәгънәсендә телгә алынган.

Суфи шагыйрьләрнең әсәрләрендә «һу кошы» күчерелмә мәгънәдә «дәрвишләр» дигәнне аңлаткан. Мәсәлән, Әхмәд Ясәвинең бер хикмәтендә «Дәрвишлекне бел хозур – Һу кошыдыр дәрвишләр»[93] дип ачык әйтелгән.

Мәүла Колый хикмәтендәге «Һу, Һу» дәйүр һу-һу кошы» гыйбарәсе һәм башка тасвирлары Кол Шәрифнең «Бакырган» китабындагы шигыренә[94] берникадәр аваздаш.

*5б кәгазь* Хикмәте хәким

1 Мәүля Қолый, ғақулға кил
Дәрвишләр сохбәтендә.
Табулур эшүң камил
Дәрвишләр сохбәтендә.

[93] Диване хикмәт гаусел-васыйлин хәзрәти солтанел-гарифин Хуҗа Әхмәд бине Ибраһим бине Мәхмүд бине Ифтихар Ясәви. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1896. – Б. 104.
[94] Бакырган. – Казан: Кукубин табыгханәсе, 1858. – Б. 28.

2 Ғашиқ улсаң тариқатдә,
Сыйддиқ улсаң шәриғәттә,
Ирешүрсән камиләтдә
Дәрвишләр сохбәтендә.

3 Рәхим Чәләб[95] рәхмәт ачар –
Фәрештәләр нида сачар.
Дәвасызлар дәва табар
Дәрвишләр сохбәтендә.

4 Нида әйләр өч мең мәләк,
Рәхим әйләр Қадир Чәләб.
Мәүля Қолый тәүбә кәрәк
Дәрвишләр сохбәтендә.

5 Һу-һу қошы қанат қағар,
Инс-ү-җангә төшәр нәзар,
Йоқлағанлар[96] булур пайдар
Дәрвишләр[97] сохбәтендә.

6 «Һу, Һу» дәйүр һу-һу қоши,
Зикр-ү-тағәт аның эши,
Ихлас улур мөэмин кеши,
Дәрвишләр сохбәтендә.

7 Ихлассызлар гөл дик ула[98],
Җисманилар җәүһәр ула[99],
Дәвасызлар[100] әсрар ула[101]
Дәрвишләр сохбәтендә.

---

[95] Кулъязмада бу сүз «Җәлимәб» рәвешендә, хаталы язылган.
[96] Кулъязмада бу сүз «йоқланлар» рәвешендә, хаталы язылган.
[97] Бу сүзнең соңгы хәрефе кулъязмада теркәлмәгән.
[98] Бу сүз кулъязмада «әлә» («ала») рәвешендә ялгыш теркәлгән
[99] Бу сүз кулъязмада «улла» дип ялгыш теркәлгән.
[100] Кулъязмада бу сүзнең «дәва» өлешендәге «а» хәрефе язылмаган.
[101] Бу сүз кулъязмада «улур» дип теркәлгән. Ләкин авторның төп текстында шигъри тезмә таләбенчә «ула» дип язылганлыгы аңлашыла.

8 Лөэлөэ-мәрҗан тәмам ула,
Сафсыз қәлбе ушал ула,
Җисем берлә дөнйа тула,
Дәрвишләр сохбәтендә.

9 Таләб қыйлма таләби әғля,
«Аллаһ» дәйү, зар-зар йығла,
...[102]
Дәрвишләр сохбәтендә.

10 Мәүля Қолый әхваль-хәбәр
«Аллаһ» дәйү, қыйлғул нәзар.
Қол Сөләйман булур пайдар
Дәрвишләр сохбәтендә.

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Мәүла Колый, акылга кил
Дәрвишләр сохбәтендә.
Табылыр эшең камил
Дәрвишләр сохбәтендә.

Гашыйк булсаң тарикатьтә,
Тугры булсаң шәригатьтә,
Ирешерсең камиллеккә
Дәрвишләр сохбәтендә.

Рәхимле Хак рәхмәт ачар –
Фәрештәләр өндәү чәчәр.
Дәвасызлар дәва табар
Дәрвишләр сохбәтендә.

[102] Кулъязмада бу урында булырга тиешле юл язылмыйча калган.



*«8689т» шифрлы кулъязма.*
*5б кәгазь*

Өндәр өч мең фәрештәләр,
Кадыйр Алла Рәхим кылыр.
Мәүла Колый тәүбә кирәк
 Дәрвишләр сохбәтендә.

Һу-һу кошы канат кагар,
Кеше-җанга караш төшәр,
Йоклаганнар чыдам булыр
 Дәрвишләр сохбәтендә.

«Һу, Һу» дияр һу-һу кошы,
Зикер-тагат аның эше,
Ихлас булыр мөэмин кеше,
 Дәрвишләр сохбәтендә.

Ихлассызлар гөлдәй була,
Җисемлеләр җәүһәр була,
Дәвасызлар серле була
 Дәрвишләр сохбәтендә.

Энҗе-мәрҗан тулы була,
Сафсыз күңеле шулай була,
Җисем белән дөнья тула,
 Дәрвишләр сохбәтендә.

Иң бөек таләпне кылма,
«Аллаһ» диеп, зар-зар ела,
...[103]
 Дәрвишләр сохбәтендә.

Мәүла Колый, хәбәр һәм хәл
«Аллаһ» диеп, күзеңне сал.
Кол Сөләйман һәрчак булыр
 Дәрвишләр сохбәтендә.

[103] Кулъязмада бу урында булырга тиешле юл теркәлмичә калган.

Әхмәд Ясәвинең 134 нче хикмәте[104]:

1 Ирәнләр җәмаль күрәр,
Сохбәтендә дәрвишләр.
Ирәнләр мәҗлесендә
Нур йагар сохбәтендә.

2 Нә кыйлса – ул булур,
Дәрвишләр сохбәтендә,
Һәр серләр заһир булур
Дәрвишләр сохбәтендә.

3 Һәркем сохбәткә килде –
Ирәндин өлүш алды.
Йат килде, белеш булды
Дәрвишләр сохбәтендә.

4 Һәркем сохбәткә килде –
Күңлегә мәгънә йотты.
Әсхабләр морад тапты
Дәрвишләр сохбәтендә.

5 Гамь килсә, хас булур,
Йолдуз килсә, ай булур,
Мис килсә алтун булур
Дәрвишләр сохбәтендә.

6 Кибер-хөседләр үләр,
Эчегә мәгънә тулар.
Күз ачыб Хакны күрәр
Дәрвишләр сохбәтендә.

[104] Диване хикмәт гаусел-васыйлин хәзрәти солтанел-гарифин Хуҗа Әхмәд ..., 1896. – Б. 242. Строфа башларындагы саннар китапта юк, мондагы текстта безнең тарафтан өстәлде.

7 Рәсулга вәхи килде,
Башыдин таҗыны алды,
Кубты, хадимлык кыйлды
Дәрвишләр сохбәтендә.

8 Кол Хуҗа Әхмәд сохбәттә,
Дәм орар мөнаҗатдә.
Зәһи хушдур сәгадәт[105]
Дәрвишләр сохбәтендә.

Сөләйман Бакыргани хикмәте[106]:

1 Ирәнләрнең мәхфилендә
Нур йагар сохбәтендә.
Ни[107] теләрсә – ул булыр
Дәрвишләрнең сохбәтендә.

2 Һәркем сохбәткә килде –
Ирәндин өлүш алды.
Әсхабләр морад табды
Дәрвишләрнең сохбәтендә.

3 Һәркем сохбәтне булды,
Күңлендә мәгънә алды.
Йад килде, белеш улды
Дәрвишләрнең сохбәтендә.

---

[105] *ирәнләр* – суфилар; *җәмаль күрәр* – йөз күрер (Аллаһы Тәгаләнең дидарын күрү); *йагар* – явар; *заһир* – ачык; *әсхабләр* – дуслар, юлдашлар; *морад* – максат; *гамь* – түбән катлау; *хас* – югары катлау; *мис* – бакыр; *кибер-хөсед* – тәкәббер-көнче; *эчегә* – эченә; *кубты* – торды; *хадимлык* – хезмәт; *дәм орар* – сулыш алыр; *мөнаҗат* – догалар; *зәһи* – бик яхшы; *сәгадәт* – бәхет, рәхәтлек.
[106] Бакырган. – Казан: Кукубин табыгханәсе, 1858. – Б. 18–19.
[107] «Бакырган» китабының 1858 елгы басмасында бу сүз юк, текстка безнең тарафтан өстәлде.

4 Гами килсә, хас булур,
Йолдуз килсә, ай булур,
Мис килсә алтун булур
Дәрвишләрнең сохбәтендә.

5 Рәсүлгә вәхи килде,
Башындин таҗын алды,
Кубды, хадимлык кыйлды
Дәрвишләрнең сохбәтендә.

6 Кол Сөләйман сохбәтендә,
Дәмбәдәм мөнаҗатдә.
Зәһи хуш дәрәҗатдә[108]
Дәрвишләрнең сохбәтендә.

---

[108] *мәхфил* – җыен, мәҗлес; *теләрсә* – теләр исә, теләсә; *сохбәтне булды* – аралашуны тапты; *гами* – түбән катлау; *дәмбәдәм* – туктаусыз; *дәрәҗат* – дәрәҗәләр.

# ИКЕНЧЕ БҮЛЕК: МОҢАРЧЫ БАСЫЛГАН ТЕКСТЛАРНЫҢ БИЛГЕСЕЗ КҮЧЕРМӘЛӘРЕ

Бу бүлектә Мәүла Колыйның төрле кулъязма җыентыклардагы шигырь-хикмәтләре тупланды. Аларны 2010 елда Уфада басылган китаптагыча саннар белән билгеләдек.

Яңа ачыкланган кулъязмалардагы шигъри текстларның күпчелеге, кызганыч ки, тулы түгел. Басма китаптагы белән чагыштырганда, дүрт хикмәтнең (4, 25, 74 һәм 78 нче) текстлары тулы. Барлык текстларда да моңарчы Уфада чыккан китаптагыдан аермалы һәм кайбер гыйбарәләргә төгәллек кертә торган урыннары бар. Ачыкланган аермалар һәм үзенчәлекләр һәр хикмәт тексты ахырындагы искәрмәләрдә күрсәтелде. Китап белән чагыштырганда зур булмаган аермалар (мәсәлән, *дуслар/дустлар, нә/ни, имеш/ирмеш, сән/син, кәрәк/кирәк)* искәртелмәде.

Мәүла Колыйның 2010 елда дөнья күргән әсәрләр җыентыгындагы текстларны соңгы ачыкланган кулъязмалар белән чагыштыру нәтиҗәләренә карасак, басмадагы ялгыш-хаталарның берничә төрле икәнен күрәбез. Аларның бер өлеше шул китапта бирелгән факсимилесында дөрес язылган булып, хәзерге татар хәрефләрендә ялгыш басылган. Мәсәлән, факсимиледа дөрес язылганнардан 1 нче хикмәттәге «килүр микән» һәм «булур микән» сүзтезмәләре «килүрме икән», «булурмы икән»[1] рәвешләрендә, 2 нче хикмәттәге «курланмышдур» сүзе басмада «корылмышдыр», 16 нчы хикмәтнең беренче текстындагы «кушлукда»

[1] Мисалларның 2010 елгы басмада кайсы битләрдә икәнлеге безнең шушы китаптагы хикмәт текстлары ахырындагы искәрмәләрдә төгәл күрсәтелде.

сүзе «төшлекидә» дип, 25 нче хикмәттәге «бирүр» урынына «булур» дип басылган, 74 нче хикмәттәге «әндамендин» сүзе «анда-монда» һәм «хокыб» сүзе урынына «гокъбә», 78 нче хикмәттәге «йанай» сүзе басмада «йангай». Менә болар, әйткәнебезчә, факсимиледа барысы да дөрес, ялгышлар бары тик хәзерге хәрефләр белән басылган текстларга хас.

Китапта тәкъдим ителгән факсимиледа булган кайбер сүзләрнең басмада төшеп калган очраклары да бар.

23 нче хикмәттәге шигъри юллар башындагы сүзләрнең гарәп әлифбасы хәрефләре тәртибе буенча язылган булуына һәм аларның төп мәгънәсе – Коръәнгә бәйлелеген аңлатуына 2010 елгы басмада әһәмият бирелмәгәнен дә искәртү зарур. Факсимиледа юл башларында гарәп хәрефләре язылган булса да, басмада аларның бирелмәве зур хата.

Шагыйрьнең икенче санлы хикмәте ахырында:

Бу мескен Мәүла Колый зарын ачар,
Гөнаһындин тәүбә кыйлыб Хакга качар,

– дигәндәге «качар» сүзенең К.Дәүләтшин хәзерләп бастырган китапта «тапар» рәвешендә бирелеше ялгыш икәнлеге аңлашылып тора. Галим кулланган кульязманы күчерүчеләр ялгышыннан киткән мондый төр хаталар тагын да бар. Мәсәлән, 23 нче хикмәттәге «һидайәт өмидемез» сүзләре басмада «һәдийәт өмидемсез» диелүе, 68 нче хикмәттәге «түшәнүб» сүзенең «каушаныб» рәвешендә бирелүен әйтергә була.

Тексттагы сүзләргә карата басмада ялгыш аңлатмалар бирелгән урыннар да күренә. Мәсәлән, Газраилнең Коръәндә «үлем фәрештәсе» дип аталган «мәләкүл-мәүти» исеме 2010 елгы китапта (48 биттә) «алла синонимы» буларак аңлатылуы асылда дөрес түгел.

2010 елгы басмада 25 нче хикмәтнең беренче һәм икенче строфалары мондый:

Гыйнайәт нуры рәхмәт –
Кадер төндә,
Колларына булур рәхмәт –
Кадер төндә.

Күк хиҗабы ачылур,
Кадер төндә
Гөнаһларың кәчелүр
Уйаг тор кадер төн(ен)дә.

Ә шул ук строфалар хәзер ачыкланган кулъязмада мондый:

Гыйнайәттүр инүлүр
Рәхмәт Кадер төнендә,
Колларына бирүлүр
Дәүләт Кадер төнендә.

Күк хиҗабы ачулур,
Йиргә рәхмәт сачүлүр,
Гөнаһларың кәчүлүр
Уйаг Кадер төнендә.

Менә болардан күренүенчә, басма китаптагы текст кайтышрак, икенчесе исә камилрәк. Шул ук хикмәтнең җиденче строфасындагы «Күрклүк Кадер төнендә» дигән юлдагы беренче сүзе басмада «күкдә» дип бирелгән булуы да күчерүчеләрдән килгән ялгыш булса кирәк. Монда басма китаптагы ялгыш-кимчелекләрнең бер өлешенә генә тукталу белән чикләндек.

Мәүла Колыйның аерым шигырь-хикмәтләрендә, гомумән, яңа дүртьюллыклар да барлыгының ачыклануы автор иҗатын баета. Соңгы чорда ачыкланган кулъязмалардагы шигъри текстларның аерым бер өлеше өзекләр рәвешендә генә булсалар да, киләчәктә М.Колый әсәрләренең тулы җыентыгын эшләүчеләр өчен файдасы тияр дип уйлыйбыз.

Авторның үлем хәлләре һәм мәхшәр көне тасвирлары, тәмуг газаплары турында язган кайбер шигырьләрен укучылар авыр кабул итәргә мөмкин. Боларның әдәби кыйммәте һәм әһәмиятләре нидә икән соң дигән сорау тууы да ихтимал. Андый тематика урта гасырлардагы әдәбият мәйданында шактый урын биләгән булуын истә тоту, шулай ук М.Колый иҗади мирасын тулы күзаллау өчен аның бөтен әсәрләренең дә өйрәнелүе зарур. Әдип иҗатын тәфсилләп өйрәнгән Ка-

мил Дәүләтшин фикерен хәтергә төшерик. Ул болай дигән: «Еш кына галимнәр Мәүла Колый иҗатын бәяләгәндә аның аерым хикмәтләренә генә таянып эш итәләр. Язучы иҗаты исә системалы берлек, бөтенлек тәшкил итә. Димәк, иҗат иясенең иҗтимагый, сәясәт һәм эстетик карашларын дөрес күзаллау өчен, аның әсәрләренең барысы белән дә таныш булу мотлак»[2].

## 1 нче хикмәт

Монда урын алган 1 нче һәм шулай ук 2, 3, 4 һәм 5 нче хикмәтләрнең төрле тулылыктагы текстлары Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «8687т» шифры белән саклана торган кульъязмадан алынды. Аның тасвирламасы беренче бүлектәге «Адәм пәйгамбәр кыйссасы» текстының алдында бирелде. Шунда ук кульъязма истәлекнең палеографик үзенчәлекләре белән бергә, кыйсса текстындагы хаталар һәм ялгышлар турында да мәгълүмат язылды. Анда «әлиф» һәм «ләм» хәрефләренең тиешеннән кыскарак итеп, «гайн» хәрефенең сүз уртасында түгәрәксыман, «йа» хәрефенең «ра» кебегрәк язылышлары турында әйтелде. Шундый ук үзенчәлекләр, кульъязма җыентык бер үк кеше кулы белән язылганлыктан, 1–5 нче хикмәтләргә дә хас. Әлеге хикмәтләрнең текстларында хәрефләр һәм аларның аерым элементлары, сүзләрнең һәм шигъри юлларның теркәлмичә калуы, ялгыш һәм хаталы язылышлар, башка кимчелекләр астөшермәләрдә искәртелде.

*29а кәгазь* Хәмед қыйлыб Хақ йадын әйтмақлықға
Бу[3] телем фәсыйхлықға килүр микән?
…[4]
Бу күңелем мәхәббәтдин тулур микән?

[2] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый: уку кулланмасы. – Уфа: РИЦ БашГУ, 2010. – Б. 16.
[3] Әлеге сүздәге «б» хәрефенең ноктасы кульъязмада ялгыш хәрефнең өстенә куелган.
[4] Бу урында булырга тиешле бер юл кульъязмада теркәлмичә калган.


بسم الله الرحمن الرحيم

*1 нче хикмәт. «8687т» шифрлы кулъязма. 29а кәгазь*

...[5]

Бу сүзләрне йад кәлүр диден теркендә
    Хақ қашында сүзең қабул булур микән?

Бу мескен Мәүля[6] Қолый төн-көн йатмай,
    Хақ қоллығын қыйлсаңчы сән хикмәт[7] әйтмәй.

[5] Шигырь текстының төп өлеше (6 дүртьюллыгы һәм шушы строфаның ике юлы) бу кулъязмада төшеп калган.
[6] Бу исем кулъязмада «Дәүля» дип хаталы теркәлгән.
[7] Бу сүздәге «к» хәрефенең ярымавыш сызыгы кулъязмада язылмаган.

Қол Сөләйман хикмәтене әдәб тотмай,
　　Хикмәт әйтүр нәчә халең булур микән?

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Аллаһыга мактау-шөкер укыр өчен
Бу телем матур сөйли алыр микән?
...[8]
　　Бу күңелем мәхәббәттән тулыр микән?

...[9]
Бу сүзләрне хәтердә диден тере чакта
　　Хак каршында сүзең кабул булыр микән?

Бу мескен Мәүла Колый төн-көн ятмый,
Хак коллыгын кылсаңчы син, хикмәт әйтми.
Кол Сөләйманның хикмәтен әдәп тотмый,
　　Хикмәт әйтер күпме хәлең булыр микән?

*Искәрмәләр*

2010 елгы басма китапта әлеге хикмәт 9 дүртьюллыктан тора[10].

Хикмәт текстын басма белән чагыштыргач түбәндәге үзенчәлекләр ачыкланды:

Беренче юлдагы «йадын» сүзе басмада (46 биттә) «йадини» дип бирелгән, гәрчә шул ук китаптагы факсимилесында «йадын» дип язылган.

Икенче юлындагы «килүр микән» сүзтезмәсе басмада (46 биттә) «килүрме икән» дип бирелгән, гәрчә факсимиледә (295 биттә) «килүр микән» дип язылган.

Өченче юлдагы «тулур микән» сүзләре шулай ук басмада «тулурмы икән» дип басылган, ләкин факсимилесында «тулур микән».

Дүртенче һәм бишенче юллар 2010 елгы басмада шушы хикмәтнең башка дүртьюллыгында теркәлгән. Дүртенче юлдагы «йад кәлүр диден теркендә» гыйбарәсе китапта (47 биттә) «йәдкәр әйдең терекендә» дип басылган. Бишенче юлдагы «қашында» сүзе урынында басмада (47 биттә) «катында» дип бирелгән.

---

[8] Бу урында булырга тиешле бер юл кулъязмада теркәлмичә калган.
[9] Шигырь текстының төп өлеше (6 дүртьюллыгы) кулъязмада төшеп калган.
[10] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 46–47.

Ахыргы юлдагы «хикмәтене» сүзе басмада (47 биттә) «хикмәтенә» дип басылган.

## 2 нче хикмәт[11]

Хикмәт[12]

*29а кәгазь* 1 Қарилық кәлде мәңа, тағәтем йуқ,
Нә қыйлғаймән қыйамәт көн[13] мән қол анда?
Рахман Изем қазый булуб мәндин сорса,
Ни айғаймән мән ғасый қол җаваб анда?

2 Бу җәһанда туғмады мәндин йаман,
*29б кәгазь* Нәфес илә шәйтан бирде мәңа гөман.
Ахыр дәмдә рузи қыйлсун Хақ мәңа иман,
Йуқ ирсә[14] эшем хатәр йарин анда.

3 Бу дөнйа зиндан ирмеш, белең монда[15],
Бу тәнемез бостан ирмеш ул[16] зинданда.
Җанларымыз миһман ирмеш ул бостанда,
Ул бостан бозылур булса – хәсрәт анда.

4 ...[17]
Күрүр күзгә[18], ағызларға туфрақ тулғай,
Гүр эчрә Мөнкир-ү-Нәкир соруғ сорғай,
Хақ ғинайәт қыйлмады ирсә дөшвар булғай.

---

[11] Текст Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «8687т» шифры белән саклана торган кулъязмадан алынды.
[12] Әлеге сүз кулъязмада беренче хикмәтнең соңгы юлы алдында, гүя, ике мәртәбә кабатланган рәвештә теркәлгән.
[13] Бу сүз кулъязмада ялгыш шушы юлның ахырында язылган.
[14] Бу сүз кулъязмада теркәлмәгән.
[15] Кулъязмада: «мәндин».
[16] Бу сүз кулъязмада «ур» дип ялгыш теркәлгән.
[17] Әлеге строфаның беренче юлы кулъязмада төшеп калган.
[18] Кулъязмада бу сүз «күзгәй» дип теркәлгән.



*2 нче хикмәт. «8687т»*
*шифрлы кулъязма. 29б кәгазь*

5 Күңлем эчрә ќурланмышдур гөнаһ туйы[19],
Ут ќабар диб хәүефлемән[20] – белең моны.
Ул утларны сүндерер ирмеш тәүбә суы,
Андин үзгә дәва йуќдыр һәргиз[21] анда.

[19] Бу сүзнең беренче хәрефе урынында кулъязмада ялгыш «ќ» язылган.
[20] Әлеге сүздәге «л» хәрефе кулъязмада теркәлмичә калган.
[21] Бу сүз кулъязмада теркәлмәгән.

6 Әй, дуст! Көн-төн тәүбә қыйлғыл монда,
*30а кәгазь* Берничә сүз шиғер-хикмәт әйдең монда.
Қыйамәт көн нәтәк булғай халең анда?
Хақдин үзгә йуқдур дәрман ул көн анда[22].

7 Бу мескен Мәүля Қолый зарын ачар,
Гөнаһындин тәүбә қыйлыб Хақға қачар[23].
Ғөмрем зайа кичде тәйү, йәшләр сачар.
Уфтанмақдин ғөмер қайра килмәз[24] анда.

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Картлык килде миңа, гыйбадәтем юк,
Ни кыйлырмын кыямәт көн мин кол анда?
Рәхимле Аллам казый булып миннән сораса,
Ни әйтермен гөнаһлы кол җавап анда?

Бу җиһанда тумады миннән яман,
Нәфес белән шайтан бирде миңа гөман,
Соң сулышта бирсен Аллаһ миңа иман,
Юкса эшем хәтәр булыр иртәгә анда.

Бу дөнья зиндан икән, бел син монда,
Бу тәнебез бакча икән ул зинданда.
Җаннарыбыз кунак икән ул бакчада,
Ул бакча бозылыр булса – хәсрәт анда.

...[25]
Күрер күзгә, авызларга туфрак тулыр,

[22] Кулъязмада «көн анда» сүзләре «көндә» дип ялгыш теркәлгән.
[23] Бу сүз ахырындагы «р» хәрефе кулъязмада ялгыш ике тапкыр кабатланган.
[24] Кулъязмада «уфтанмақдин» сүзенең ахырындагы «ин» хәрефләре теркәлмәгән. Ә «қайра» сүзе ялгыш «қайур» дип язылган, «килмәз» сүзендәге «з» хәрефенең ноктасы куелмаган.
[25] Әлеге строфаның беренче юлы кулъязмада төшеп калган.

Гүр эчендә Мөнкир-Нәкир сорау сорар,
    Аллаһ ярдәм кылмаса бик авыр булыр.

Күңлем эчен биләгәндер гөнаһ туйы
Ут кабар дип хәвефле мин – белче моны.
Ул утларны сүндерер икән тәүбә суы,
    Аннан башка дәва юктыр һич тә анда.

Әй, дуст! Көн-төн тәүбә кыл син монда,
Берничә сүз шигырь-хикмәт әйт син монда.
Кыямәт көн ничек булыр хәлең анда?
    Хактан башка юктыр дәрман ул көн анда.

Бу мескен Мәүла Колый зарын ачар,
Гөнаһыннан тәүбә кылып, Хакка качар.
Гомрем зая кичте диеп, яшьләр чәчәр.
    Уфтанмактан гомер кире килмәс анда.

*Искәрмәләр*

2010 елгы басма китапта әлеге хикмәт 8 дүртьюллыктан тора[26].

Беренче юлдагы «тағәтем» сүзе урынында 2010 елгы басма китапта (47 биттә): «такъәтем».

Икенче строфаның икенче юлындагы «гөман» сүзе урынында басмада (47 биттә): «йаман». Шул ук дүртьюллыктагы «Хақ» сүзе басмада юк.

Дүртенче строфаның бу кульязмада төшеп калган юлы басмада (48 биттә) «Ул бостанны мәлик әл-мәүет хәраб кылгай» дип бирелгән. «Мәлик әл-мәүет» сүзенә карата бирелгән «алла синонимы» дигән аңлатмасы ялгыш. Чөнки, дөреслектә, «мәләкүл-мәүти» (үлем фәрештәсе) дигәндә Газраил күздә тотылган. Ул Коръәннең «Әс-Сәҗдә» сүрәсендәге 11 нче аятьтә нәкъ шулай аталган.

Дүртенче строфаның ахыргы юлындагы «булғай» сүзе урынында басмада (48 биттә): «анда».

Бишенче дүртьюллыктагы «қурланмышдур» сүзе басмада (48 биттә) «корылмышдур» дип бирелгән, гәрчә факсимилесында (296 биттә) «курланмышдур» диелгән.

Алтынчы строфа башындагы «Әй, дуст» гыйбарәсе басмада (48 биттә) «Әйә, дустлар» дип бирелгән, гәрчә факсимилесында (296 биттә) «әй...»

[26] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 47–49.

дип язылган. Шул ук алтынчы строфаның икенче һәм өченче юллары басма китапта бөтенләй юк. Анда бу юллар башкача бирелгән.

Җиденче строфаның беренче юлындагы «Мәүла» исеменнән соң кулъязмада теркәлгән «р» хәрефе ялгыш. Икенче юл ахырындагы «қачар» сүзе урынында басмада (48 биттә): «тапар».



*3 нче хикмәт. «8687т» шифрлы кулъязма. 30а кәгазь*

## 3 нче хикмәт[27]

*30а кәгазь*

Хикмәт

1 Адәм уғлы бизәнүр
Дөнйаны бақи саныб.
Гөнаһ тохымын игәрләр
Билен бағлаб, йасаныб.

2 ...[28]
Ахирәткә күчәрләр
Гөнаһ атын атлануб.

3 Тәүбә қыйлыб йығланур
Ғөмер заиғ кичмешен.
...[29]

4 Хақға тағәт қыйлуңыз,
Бу тереклек кичкүсе.
Үлүм килүб башына
Тамурларың печкүсе.

5 Мәүля Қолый, тәүбә қыйл,
Қыйәмәт көн булғусы.
*30б кәгазь* Мондин қыйлған эшләрең
Барча алға килгүсе.

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Адәм улы бизәнер
Дөньяны мәңге санап.

---

[27] Текст Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «8687т» шифры белән саклана торган кульязмадан алынды.
[28] Бу строфаның башындагы ике юлы кульязмада теркәлмәгән.
[29] Бу строфаның ахырындагы ике юлы кульязмада теркәлмәгән.

Гөнаһ орлыгын игәрләр
    Билен баглаб, ясаныб.

...[30]
Ахирәткә күчәрләр
Гөнаһ атын атланыб.

Тәүбә кылып еланыр
Гомер зая кичкәнен.
...[31]

Хакка тагать кылыгыз,
Бу тереклек кичәсе.
Үлем килеп башына
    Тамырларың кисәсе.

Мәүла Колый, тәүбә кыл,
Кыямәт көн булачак.
Моннан кылган эшләрең
    Барча алга киләчәк.

*Искәрмәләр*

2010 елгы басма китапта әлеге хикмәт 5 дүртьюллыктан тора[32].

Икенче строфадагы «атлануб» сүзе кульязмада «атунуб» дип ялгыш теркәлгән.

Өченче строфаның беренче юлындагы «йығланур» сүзе урынында 2010 елгы басма китапта (49 биттә): «йыглаңыз». Шул ук строфаның икенче юлындагы «кичмешен» сүзе урынында басмада: «кичмешдин».

Бишенче строфаның өченче юлындагы «мондин» сүзе урынында басмада (49 биттә): «монда».

---

[30] Бу строфаның башындагы ике юлы кульязмада теркәлмәгән.
[31] Бу строфаның ахырындагы ике юлы кульязмада теркәлмәгән.
[32] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 49.



*4 нче хикмәт. «8687т» шифрлы кулъязма. 30б кәгазь*

## 4 нче хикмәт[33]

*30б кәгазь* Хикмәт

1 Мәүҗ орур бу күңел
Хакны эстәй китәле.
Ихлас илә эстәсәм,
Морадыма[34] йитәле.

[33] Текст Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «8687т» шифры белән саклана торган кулъязмадан алынды.
[34] Бу сүзнең соңгы хәрефе кулъязмада теркәлмәгән.

2 Хақны табар чын күңел,
Ихлассыздин сән түңел.
Хақның әмрене исә
Ихлас илә тотарам[35].

3 Нәфес мәңа пар дәгүл,
Эче[36] қара, тышы гөл.
Нәфсе хәйлә-хәшмендин
Ихлас илә үтәрүм.

4 Нәфсе Хақны танымаз,
Гөнаһ қыйлур, арымаз.
Нәфсе-шомның хиҗлендин
Хәсрәт утын йотарам.

5 Рузә тотуб, қыйл намаз,
Ихлас илә қыйл нийаз.
Үлүм килүр башымға,
Гүр өйүнә күчәрәм.

6 Үлүм килүр ғақибәт,
Булғусыдур ахирәт.
Әйттүм, дустлар, нәсыйхәт,
Пәнд сүзем сачәрәм.

7 Мәүля Қолый, тәүбә[37] қыйл,
Хикмәт әйтмә, халең бел.
*31а кәгазь* Қол Ғөбәйди хикмәтен
Җандин ғәзиз тотарам.

[35] Кулъязмада «илә» сүзе төшеп калган, «тотарам» сүзе хаталы итеп «тоғарам» рәвешендә теркәлгән.
[36] «Эче» сүзе кулъязмада «ач» дип ялгыш теркәлгән.
[37] Бу сүзнең соңгы хәрефе кулъязмада теркәлмәгән.

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Дулкынлана бу күңел
Хакны теләп китәрмен.
Ихлас белән теләсәм,
　　Морадыма җитәрмен.

Хакны табар чын күңел,
Ихлассыздин син чиген.
Хакның әмерен исә
　　Ихлас белән тотармын.

Нәфес миңа пар түгел,
Эче кара, тышы гөл.
Нәфес хәйлә-ярсуын
　　Ихлас белән үтәрмен.

Нәфес Хакны танымас,
Гөнаһ кылыр, арымас.
Нәфес-шом оятыннан
　　Хәсрәт утын йотармын.

Ураза тот, кыл намаз,
Ихлас белән кыл нияз[38].
Үлем килер башыма,
　　Гүр өенә күчәрмен.

Үлем килер, ниһаять,
Булачактыр ахирәт.
Әйттем, дуслар, нәсыйхәт,
　　Үгет сүзем чәчәрмен.

Мәүла Колый, тәүбә кыл,
Хикмәт әйтмә, хәлең бел.

---

[38] *нияз* – үтенү, ялвару, дога.

Кол Гобәйди хикмәтен
Җаннан газиз тотармын.

*Искәрмәләр*

Әлеге хикмәт 2010 елгы басма китапта да 7 дүртьюллыктан тора[39].

Беренче строфадагы «китәле» һәм «йитәле» сүзләре басмада (50 биттә): «китәрүм», «йетәрүм».

Өченче строфаның беренче юлындагы «пар» сүзе урынында басмада (50 биттә): «йар». Шул ук строфаның өченче юлындагы «хәйлә» сүзе урынында басмада (50 биттә): «хийәл». Әлеге строфаның соңгы юлындагы «үтәрүм» сүзе урынында басмада: «качарум».

Алтынчы строфаның дүртенче юлындагы «пәнд» сүзе кулъязмада «бәнд» дип теркәлгән. «Пәнд сүзем» гыйбарәсе урынында басмада (50 биттә): «бәндә сердәм».

## 5 нче хикмәт[40]

*31а кәгазь* 1 Рахман Изем остад қапуғын ачмыш икән,
Берничә көн анда җәүлян қыйлдым, дустлар.
Ғафиллекда күзем сукыр[41]қарамақда,
Остадымдин җөда булыб қалдум, дуслар.

2 Остадым Хақ йулына қайтқан ирмеш,
Ғақилләрнең хатрене байутған ирмеш.
Мән ғафилне дөнйа таба атқан ирмеш,
Бу халәтне һәргиз белмәй қалдум, дустлар.

3 Остадым бу җиһандин байық бизде,
Ғилм-ү-хикмәт китабларыны күңленә йазды.
Көне-төне батыйн эчрә Қөръән төзде,
Күргән игәч серен белмәй қалдум, дуслар.

[39] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 49–50.
[40] Текст Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «8687т» шифры белән саклана торган кулъязмадан алынды.
[41] Бу сүз кулъязмада «сирфә» рәвешендә, хаталы язылган.

*31б кәгазь* 4 Остадым Хақ ғыйшқында тормыш ирде,
Мәдрәсә-мәктүбханә қормыш ирде[42].
Җөмлә мәрде хезмәтенә йөз ормыш ирде,
    Берничә көн ул мәҗлесдә тордым, дуслар.

5 Остадым хезмәтендә бер[43] көн тордым,
Остадымлә қәдәм оруб, бергә йөрдүм,
Туфраҕ қыйлу йөзем йиргә ордум,
    Ул хәлвәтдин бер доғасын алдум, дуслар.

6 Остадым бу җиһанны фани белде,
Әүлийалар ғыйшқы[44] берлә күңле[45] тулды.
Астанәләр йабдурмақға нийәт қыйлды,
    Ул нийәтен мондин тәмам итде дуслар.

7 Остадым ғәзизләрдән мәдәд табты,
Балым Хуҗа астанәсен әүвәл йабды.
Шәһри Болғар...[46]

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Рәхимле Аллам остаз капкасын ачкан икән,
Берничә көн анда йөреп алдым, дуслар.
Гамьсезлектә күзем сукыр карамакта,
    Остазымнан аерылып калдым, дуслар.

Остазым Хак юлына кайткан икән,
Аңлыларның хәтерен баеткан икән.
Мин гамьсезне дөнья таба аткан икән,
    Бу халәтне һич тә белми калдым, дуслар.

[42] Кулъязмада бу юлдан соң, гүяки, яңа шигырь башланганны белдергән «Хикмәт» дигән сүз ялгыш язылган.
[43] Бу сүз кулъязмада теркәлмәгән.
[44] Кулъязмада: ғашиқы.
[45] Бу сүзнең соңгы хәрефе кулъязмада теркәлмәгән.
[46] Кулъязма дәфтәрнең моннан соңгы кәгазьләре төшкән, «Шәһри Болгар» сүзләре 31б кәгазьнең кустодында гына теркәлгән.

Остазым бу җиһаннан тәмам бизде,
Гыйлем-хикмәт китапларын күңленә язды.
Көне-төне күңелендә Коръән төзде,
Үзен күргәч серен белми калдым, дуслар.



*5 нче хикмәт. «8687т» шифрлы кулъязма.*
*31а кәгазь*

Остазым Хак гыйшкында торган иде,
Мәдрәсә-мәктүбханә[47] корган иде.
Бөтен кеше хезмәтенә йөз тоткан иде,
    Берничә көн ул мәҗлестә тордым, дуслар.

Остазым хезмәтендә бер көн тордым,
Остазым белән бергә атлап, бергә йөрдем,
Туфрак кылып йөземне җиргә ордым,
    Ул аулактан бер догасын алдым, дуслар.

Остазым бу җиһанны фани белде,
Әүлиялар гыйшкы белән күңле тулды.
Астанәләр төзетергә ният кылды,
    Ул ниятен моннан тәмам итте дуслар.

Остазым изгеләрдән ярдәм тапты,
Балым Хуҗа астанәсен әүвәл япты,
    Шәһри Болгар...

*Искәрмәләр*

Әлеге хикмәт 2010 елгы басма китапта 16 дүртьюллыктан тора[48].

Беренче строфадагы «икән» сүзе урынында басмада (51 биттә): «иркән».

Өченче строфаның өченче юлындагы «көне-төне» гыйбарәсе урынында басмада (51 биттә): «төне-көне».

Дүртенче строфаның өченче юлындагы «мәрде» сүзе урынында басмада (51 биттә): «мөрид».

Бишенче строфаның өченче юлындагы «туфраґ» сүзе урынында басмада (51 биттә): «тәззәригъ». Шул ук строфаның дүртенче юлындагы «хәлвәтдин» сүзе урынында басмада (51 биттә): «хәлвәтдә».

Алтынчы строфаның соңгы юлындагы «мондин» сүзе урынында басмада (52 биттә): «монда».

Җиденче строфаның икенче юлындагы «Балым» исеме басмада (52 биттә): «Балгым».

---

[47] *мәктүбханә* – китаплар күчереп язу өчен махсус бина. Бу очракта мәдрәсә белән икесе бергә дип аңлашыла. Татар кульязмаларын күчерү – мәдрәсә шәкертләренең төп шөгыльләреннән берсе булганлыгы тарихтан билгеле.

[48] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 51–53.

## 16 нчы хикмәт (беренче текст)

Хәзерге вакытта Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «8688т» шифры белән саклана торган кульязма җыентыкта Мәүла Колыйның 16 нчы һәм 74 нче хикмәтләре (1а–2а кәгазьләрдә) бар. Кульязмада шулай ук гарәп телендәге шигъри «Кафия» (татарча юлга-юл тәрҗемәле), Габделҗәббар хикәяте, шигъри «Кырык фарыз», Габдерәхим Утыз Имәнинең «Мөһимматез-заман» әсәре көрән төстәге язу карасы белән, нәстәгъликъ-шикәстә төрендә теркәлгән. «Хикмәт» сүзләре кызыл кара белән язылган, текстлар икешәр кызыл рамкага алынган. Кульязма истәлек зурлыгы 17х22 см үлчәмендәге, Россиядә XIX гасырның беренче яртысында эшләнгән кәгазьдән гыйбарәт. Кульязманың барлык битләре дә сакланмаган.

Бу җыентыкны күчерүче Йосыф һәм Йосыф өчен дусты Фәсхетдин, Габделгаффар исемнәре күрсәтелгән. Кульязманың кайчан һәм кемнән алынган булуы теркәлмәгән.

Җыентыкның 1а–1б кәгазьләрендәге хикмәтнең башы юк, төп өлеше һәм ахыры бар. Ул барлыгы 14 дүртьюллыктан тора һәм эчтәлеге белән С.Бакырганиның «Ахыр заман» әсәре текстына якын. Хикмәтнең соңгы дүртьюллыгында автор үзе дә: «Мәүла Колый ... ахыр заман сыйфатларын әйдүрсән сән» дигән.

Бу кульязмадагы М.Колый хикмәтләренең текстлары шактый дөрес имля белән теркәлгән, аларда хата-ялгышлар аз.

*1а кәгазь* 1 Андин соңра көн тотылуб, томан[49] булғай,
Дөнйа эчрә ғауға булуб һәйеһа тулғай.
Дөнйа халқы қаранғулуқ эчрә қалғай,
Өч кичә-көн қаранғуда кичәр ирмеш.

[49] Кульязмада бу сүзнең соңгы хәрефе теркәлмәгән.

2 Мәшрикдин көн зәвальға чықыб килгәй,
Йәнә қайтуб мәшриқға барыб ингәй.
Өч көнгәчә төшкә килеб, кире түнгәй,
Өч көндин соң мәғрибғача китәр ирмеш.

3 Мондин соңра Исрафилға дәстүр[50] бирүр,
Җомға көн хасс қушлукда сурын өрүр,
Йирдә, күкдә мәхлүкне җөмлә қырур,
Түрт мөкәррәб фәрештә һәм қалур ирмеш.

4 Бу дөнйада қырық йылча анлар қалур,
Шул вақытда Иблиснең җанын алур,
Җан алурда ул мәлғүн фөрйад қыйлур –
Җанлы мәхлүк булса иссез үлүр ирмеш.

5 Хақ Тәғалә Ғазраилгә әмер қыйлур,
Ғазраил өч фәрештә җанын алур.
Андин соңра үз җанына чәнгял орур,
Уң қулилә сул күзендин тартар ирмеш.

6 Йир-ү-күк мәхлүкатдин хали қалғай,
Йир йөзенә пәшә-сиңәк, чебен тулғай.
Өч йылғача бу дөнйада алар булғай,
Андин соңра дөнйа иссез қалур ирмеш.

7 Мивә-нигъмәт бу йир йөзе тәмам булғай,
Җанлық-мәхлүк, йаба-эчләр һич йук булғай.
Бу йир йөзе бу сыйфатлығ булуб қалғай,
Өч йыл йәнә бу сыйфатлығ кәчәр ирмеш.

8 Андин соңра бу дөнйаға туфрақ тулғай,
Йәш нә ирсә қалмағай, көйүб гәүһәр булғай.
Йир йөзендә Хақ Тәғалә туфан қыйлғай –
Йир-күк ара су тулубән торар ирмеш.

---

[50] Бу сүзнең соңгы хәрефе «р» урынына кульязмада ялгыш «д» хәрефе теркәлгән.




*16 нчы хикмәт (беренче текст).*
*«8688т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь*

9 Дөнйа эчрә андағ тағлар булса йүчә –
Йитмеш аршун су йуқару[51] андин кичә.
Бу йир йөзен су тотар очдин-оча,
Бу йир йәнә қайра қоруғ булур ирмеш.

[51] Кулъязмада: йуқарру.

*1б кәгазь* 10 Бу эшләр булғунча һәм[52] өч йыл кәчәр,
Хақ Тәғалә йир қапуғын тәмам ачар,
ағлар-ташлар тузан кебек күккә очар,
Йирне[53]-күкне зир-ү-зәбәр қыйлур ирмеш.

11 Бу эшләр булғунча қырық йыл кәчәр,
Рахман Изем Исрафилға рәхмәт сачар.
Терелүбән[54] Хақ әмерен күзен ачар,
Сурун өргәч йир-күк халқы терелүр ирмеш.

12 Ғәләм халқы ул көн анда[55] терелүбән,
Ғарасатға килүр барча сөрелүбән,
Қырық мең йыл ул мәқамдә булуб һаман,
Йегерме биш мең йыл сыйратда қалур ирмеш.

13 Йегерме биш мең йылдин соңра әмер булғай,
Кяфер, мөэмин бер-берендин айырулғай,
Мөэмин қоллар дидар күрүб, җәннәт[56] булғай,
Кяферләргә бақи тәмуғ булур ирмеш.

14 Мәүля Қолый Хақға йығлаб тағәт қыйлсун,
Үз дидарын күрмәкне Хақ[57] рузи қыйлсун.
Ахыр заман сыйфатларын әйдүрсән сән,
Меңдә бер сүз растлықға килүрмү ирмеш?

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Аннары соң көн тотылып, томан булыр,
Дөнья эче гауга булып, шау-шу тулыр.

[52] Бу сүз кулъязмада юк, текстка безнең тарафтан өстәлде
[53] Кулъязмада бу сүз юл ахырына гына өстәп куелган.
[54] Бу сүз кулъязмада «терелибин» дип ялгыш язылган.
[55] Кулъязмада «анда» сүзе юк, текстка безнең тарафтан өстәлде.
[56] Кулъязмада: җәннәтдә. Дөресе – бу китаптагы шушы ук хикмәтнең икенче текстындагыча (3 нче строфада) «җәннәт булғай», ягъни «җәннәт табар» булырга тиеш.
[57] Бу сүз кулъязмада теркәлмәгән, текстка безнең тарафтан өстәлде.

Дөнья халкы караңгы эчендә калыр,
    Өч төн һәм көн караңгыда кичәр икән.

Көнчыгыштан кояш баюга чыгып килер,
Тагын кайтып көнчыгышка барып иңәр.
Өч көнгәчә төшкә килеб, кире түнәр,
    Өч көннән соң көнбатышка китәр икән.

Аннан Аллаһ Исрафилга рөхсәт бирер,
Җомга көн нәкъ төшкә хәтле сурын өрер,
Җирдә, күктә булганнарның барын кырыр,
    Иң якын дүрт фәрештә калырлар икән.

Бу дөньяда кырык елга алар калыр,
Шул вакытта Иблиснең җанын алыр,
Җан алганда ул мәлгунь зар кычкырыр –
    Җанлы мәхлук булса аңсыз үләр икән.

Хак Тәгалә Газраилгә әмер кылыр,
Газраил өч фәрештәнең җанын алыр.
Аннары соң үз җанына тырнак орыр,
    Уң кулы белән сул күзен тартыр икән.

Җир һәм күк җан ияләреннән буш калыр,
Җир йөзенә черкиләр һәм чебен тулыр.
Өч йылгача бу дөньяда алар булыр,
    Аннары соң дөнья җансыз калыр икән.

Җимеш-нигъмәт бу җир йөзе тәмам тулыр,
Җанлы-мәхлук, яба-эчләр һич юк булыр.
Бу җир йөзе бу сыйфатлы булып калыр,
    Өч ел янә бу сыйфатлы кичәр икән.

Аннары соң бу дөньяга туфрак тулыр,
Яшел нәрсә калмас, көеп гәүһәр булыр.

Җир йөзендә Хак Тәгалә туфан кылыр –
    Җир-күк арасы су тулып торыр икән.

Дөнья эчендә иң югары таулар булса –
Җитмеш аршин су югары аннан кичә.
Бу җир йөзен су тотар очтан-очка,
    Бу җир янә кире коры булыр икән.

Бу эшләр булганчы өч ел кичәр,
Хак Тәгалә җир капкасын тәмам ачар,
Таулар-ташлар тузан кебек күккә очар,
    Җир-күкне астын-өскә китерер икән.

Бу эшләр булганчы кырык ел кичәр,
Рәхимле Аллам Исрафилга рәхмәт чәчәр.
Терелеп Хак әмереннән күзен ачар,
    Сурын өргәч җир-күк халкы терелер икән.

Галәм халкы ул көнне анда терелеп
Кыяматкә килерләр барча сөрелеп,
Кырык мең ел ул урында һаман булып,
    Егерме биш мең ел сиратта калыр икән.

Егерме биш мең елдан соң әмер булыр,
Кяфер, мөэмин бер-береннән аерылыр,
Мөэмин коллар дидар күреп, җәннәт табар,
    Кяферләргә мәңге тәмуг булыр икән.

Мәүла Колый Хакка елап тагать кылсын,
Үз дидарын күрмәкне Хак насыйп итсен.
Ахыр заман сыйфатларын әйтерсең син,
    Меңнән бер сүз дөреслеккә килер микән?

*Искәрмәләр*

Әлеге хикмәт 2010 елгы басма китапта 23 дүртьюллыктан тора[58].

Беренче строфаның соңгы юлындагы «кичә-көн» гыйбарәсе урынында басмада (68 биттә): «көн дәхи».

Өченче строфаның беренче юлындагы «Исрафилға» сүзе урынында басмада (68 биттә): «Исрафил». Икенче юлдагы «қушлукда» сүзе басмада (68 биттә) «төшлекидә» дип ялгыш бирелгән, чөнки шул ук китаптагы факсимилесында (308 биттә) бу сүз нәкъ шулай – «қушлукда» дип теркәлгән. («Қушлуқ» дигән борынгы төрки сүз иртәдән алып төшкә кадәрге вакытның уртасын (сәгатьне) белдергән). Өченче юлдагы «мәхлүқне» сүзе урынында басмада (68 биттә): «мәхлукатны».

Дүртенче строфадагы беренче юлның «Бу дөнйада қырық йылча» өлеше урынында басмада (68 биттә): «Бу дөнъйа кырык йылгача». Икенче юлдагы «җанын» сүзе басмада (68 биттә) «җаныни» дип бирелгән, гәрчә факсимилесында (308 биттә) «җанын» дип теркәлгән. Дүртенче юлдагы «иссез» сүзе урынында басмада (68 биттә): «исә».

Алтынчы строфаның беренче юлындагы «йир-күк» гыйбарәсе урынында басмада (69 биттә): «йир бөлә күк». Дүртенче юлдагы «иссез» сүзе урынында басмада (69 биттә): «әсисез».

Җиденче строфаның беренче юлындагы соңгы сүз урынында басмада (69 биттә): «тулгай». Икенче юлдагы «җанлық» сүзе урынында басмада (69 биттә): «җанлы». Шул ук юлдагы «йаба-эчләр» гыйбарәсе урынында басмада (69 биттә): «йййәр-эчләр». Факсимилесында (309 биттә) «эчләр» дип түгел, ә «эчрә» дип язылган. Дүртенче юлдагы «сыйфатлығ» сүзе урынында басмада (69 биттә): «сыйфатлы».

Сигезенче строфаның беренче юлындагы «туфрақ» сүзе урынында басмада (69 биттә): «төтен». Икенче юлдагы «Йәш нә ирсә қалмағай, көйүб гәүһәр булғай» җөмләсе урынында басмада (69 биттә): «Йәш нәрсә калмыйча, кибеб күмер булгай».

Тугызынчы строфаның өченче юлындагы «йөзен» сүзе басмада (69 биттә) «йөзени» дип бирелгән, гәрчә факсимилесында (309 биттә) «йөзен» дип язылган. Дүртенче юлдагы «қайра» сүзе басмада (69 биттә) юк, факсимилесында (309 биттә) бар.

Унынчы строфаның беренче юлындагы «булғунча» сүзе басмада (69 биттә) «булганича» дип бирелгән, гәрчә факсимилесында (309 биттә) «булганча» дип язылган. Икенче юлдагы «йил» сүзе урынында басмада (69 биттә): «йир». Өченче юлдагы «күккә» сүзе урынында басмада (69 биттә): «кукдә».

Унберенче строфаның беренче юлындагы «булғунча» сүзе басмада нәкъ унынчы строфа искәрмәсендә әйтелгәнчә үк. Соңгы юлдагы «терелүр» сүзе басмада (69 биттә): «терлур».

[58] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 66–70.

Уникенче строфаның икенче юлындагы «барча» сүзе урынында басмада (69 биттә): «анда».

Унөченче строфаның беренче юлындагы «соңра» сүзе урынында басмада (70 биттә): «соң». Өченче юлдагы «җәннәтдә» сүзе урынында басмада (70 биттә): «җәннәт». Дүртенче юлдагы «кяфирләргә» сүзе урынында басмада (70 биттә): «кяфиргә».

Ундүртенче строфаның беренче юлындагы «қыйлсун» сүзе урынында басмада (70 биттә): «кыйл сән». Өченче юлдагы «әйдүрсән сән» гыйбарәсе урынында басмада (70 биттә): «әйтә вирсүн». Дүртенче юлдагы «Меңдә бер сүз растлықға килүрмү ирмеш» җөмләсе урынында басмада (70 биттә): «Мең дә берсен бәйан идеб булмас ирмеш».

## 16 нчы хикмәт (икенче текст)

Мәүла Колыйның түбәндә тәкъдим ителә торган шигыре XIX гасыр башында Россиядә эшләнгән, 7,5х17 см зурлыгындагы кәгазьле җыентыкта теркәлгән. Бу кулъязмада Мәүла Колыйның моңарчы билгеле булган шигырьләре (16, 17, 25 һәм 68 нче хикмәтләре) теркәлгән. Аларның башларында кызыл төстәге кара белән «Хикмәт» дип язылган, берничәсе күпнокталар белән чолгап, үзенчәлекле итеп бизәлгән. Текстлары караңгы көрән төстәге кара белән, нәстәгъликъ-шикәстә төрендә язылган.

Әйтелгәннәрдән тыш, җыентыкта гыйшык җыры («Гөлгыйзар»), «Бакырган китабы»ннан шигырьләр, «Бу кичә аяз кичә...» шигыре, «Хикәяте Аю» (Яубазы) һәм төрле догалар бар. Кулъязманы күчергән кешесе – мулла Газиз бине Җомагыл бине Кинҗәкәй бине Ишем дип күрсәтелгән. Бу истәлекнең сакланышы уртача. Язуы торыксыз булса да, кайбер хаталарыннан башка, кимчелекләре күп түгел.

Җыентык хәзерге вакытта Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «8686т» шифры белән саклана. Аны Татарстанның Чаллы районындагы Иске Гәрдәле авылында Дөрлекамал Хаҗетдиновадан археограф Альберт Фәтхи алган. Шул хактагы мәгълүмат кулъязманың 4а кәгазендә кызыл төстәге кара белән гарәп хәрефләрендә А.Фәтхи тарафыннан теркәп

куелган, әмма кайсы елда алынганлыгы күрсәтелмәгән. Фәтхинең эш хисаплары турындагы язмаларыннан ачыклавыбызча, аның әлеге авылдагы археографик эзләнүләре 1975 елның июнь-июль айларында узган.

Бу кулъязмада М.Колыйның 16 нчы хикмәте ахырындагы дүрт строфасы гына теркәлгән (берсенең ике юлы гына язылган).

*21б кәгазь* Хикмәт

1 ...[59]
Терелеб Хақ әмеренә күзен ачар,
Сурын өргәч йир-күк халқы терелүр ирмеш.

2 Ғәләм халқы ул көн анда терелүбән[60]
Ғарасатқа килүр барча сөрелүб һәм,
Қырық мең йыл ул мәқамдә булуб һаман,
Йегерме биш мең йыл сыйратда қалур ирмеш.

3 Йегерме биш мең йылдин соңра әмер булғай,
Кяферләр, мөэмин бер-берендин айырылғай,
Мөэмин қоллар дидар күрүб җәннәт булғай,
Кяферләргә бақи тәмуғ булур ирмеш.

4 Мәүля Қолый, Хақға йығлаб тағәт қыйл син,
Үз дидарын күрмәкне Хақ рузи қыйлсун,
*22а кәгазь* Ахыр заман сыйфатларын әйдүрсүн син,
Меңдә берсүн растлықға килүрмү ирмеш?

[59] Бу строфаның башындагы ике юлы кулъязмада теркәлмәгән.
[60] Бу сүз кулъязмада «терелүбүн» дип теркәлгән.



*16 нчы хикмәт (икенче текст). «8688т» шифрлы кулъязма. 21б кәгазь*

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

...[61]
Терелеп Хак әмереннән күзен ачар,
   Сурын өргәч җир-күк халкы терелер икән.

Галәм халкы ул көнне анда терелеп
Кыяматкә килер барча һәм сөрелеп,
Кырык мең ел ул урында һаман булып,
   Егерме биш мең ел сиратта калыр икән.

Егерме биш мең елдан соң әмер булыр,
Кяфер, мөэмин бер-береннән аерылыр,
Мөэмин коллар дидар күреп, җәннәт табар,
   Кяферләргә мәңге тәмуг булыр икән.

Мәүла Колый, Хакка елап тагать кыл син,
Үз дидарын күрмәкне Хак насыйп кылсын,
Ахыр заман сыйфатларын әйтерсең син,
   Мең нән берсе дөреслеккә килер микән?

*Искәрмәләр*

Бу хикмәт 2010 елгы басма китапта 23 дүртьюллыктан тора[62].

Беренче строфаның иң беренче сүзе урынында басмада (69 биттә): «терелүбән». Икенче юлдагы «терелүр» сүзе басмада (69 биттә) «терлур» дип бирелгән.

Икенче строфаның икенче юлындагы «барча сөрелүб һәм» сүзләре урынында басмада (69 биттә): «анда сөрелүбән».

Өченче строфадагы «соңра» сүзе урынында басмада (70 биттә): «соң». Икенче юлдагы «кяферләр» сүзе урынында басмада (70 биттә): «кяфир». Дүртенче юлдагы «кяферләргә» сүзе урынында басмада (70 биттә): «кяфиргә».

Дүртенче строфаның өченче юлындагы «әйдүрсүн син» гыйбарәсе урынында басмада (70 биттә): «әйтә вирсүн». Дүртенче юлдагы «рас-

[61] Бу строфаның башындагы ике юлы кулъязмада теркәлмәгән.
[62] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 69–70.

тлыкъга килүрмү» сүзләре урынында басмада (70 биттә): «бәйан идеб булмас».

## 17 нче хикмәт

Бу хикмәт моннан алдагы 16 нчы хикмәт (икенче текст) теркәлгән «8686т» шифрлы кулъязмадан алынды. Анда әлеге хикмәтнең башындагы дүрт строфасы язылган.

*22а кәгазь* Хикмәт

1 Кәғбәтулла рәхмәт тулуғ дивар имеш,
Күрмәклекне Хақдин теләб йөрсәмче мән.
Ихлас илә төн-көн йөрүб рәхмәтендә
Хаҗилар[63] кеби, ул йул сари булсамчы мән.

2 Кәғбә йулы рәхмәт имеш иқдам орсаң,
Ихлас илә Кәғбә сари рихләт қыйлсаң,
Хозыр Илйас рәһбәр имеш барыр булсаң,
Ихлас илә Кәғбә сари йөрсәмче мән.

3 Кәғбәтулла сәфид раушан мәрвәр имеш,
Анда бөткән җөмлә сәнкләр гәүһәр имеш,
Рәхмәт йимеше тулуб торған бостан имеш,
*22б кәгазь* Ул бостанның йимешендин татсамчы[64] мән.

4 Кәғбә сари йөрегәнләр – ирнең ири,
Тәваф қыйлуб гөнаһындин булур ари,
Қийамәт көн күрүр анлар Хақ дидари.
Хаҗи булуб, Хақ дидарын күрсәмче мән.

[63] Кулъязмада бу сүз ахырындагы «р» хәрефе теркәлмәгән.
[64] Бу сүздәге «с» хәрефе кулъязмада төшеп калган.



*17 нче хикмәт. «8686т» шифрлы кульязма. 22а кәгазь*

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Кәгъбәтулла рәхмәт тулы дивар икән,
Күрәсемне Хактан теләп йөрсәмче мин.
Ихлас белән төн-көн йөреп рәхмәтендә
　Хаҗилар кебек ул юлда булсамчы мин.

Кәгъбә юлы рәхмәт икән көчең куйсаң,
Ихлас белән Кәгъбә якка күчеп китсәң,
Хозыр Ильяс юл күрсәтер барыр булсаң,
　Ихлас белән Кәгъбә якка йөрсәмче мин.

Кәгъбәтулла якты, раушан энҗе икән,
Андагы күп барча ташлар гәүһәр икән,
Рәхмәт җимеше тулып торган бакча икән,
　Ул бакчаның җимешен татысамчы мин.

Кәгъбә ягына йөргәннәр – ирнең ире,
Тәваф кылып, гөнаһыннан булыр ару,
Кыямәт көн күрер алар Хак дидарын.
　Хаҗи булып, Хак дидарын күрсәмче мин.

*Искәрмәләр*

Бу хикмәт 2010 елгы басма китапта 11 дүртьюллыктан тора[65].

Беренче строфаның беренче юлындагы «дивар» сүзе урынында басмада (70 биттә): «дидар». Икенче юлдагы «күрмәклекне» сүзе урынында басмада (70 биттә): «күрмәклеккә», «рәхмәтендә» сүзе урынында: «ризалыкда». Дүртенче юлдагы «хаҗилар» сүзе урынында басмада (70 биттә) «хаҗаҗ», «булсамчы» сүзе урынында «йөрсәмче» диелгән.

Икенче строфадагы «икдам орсаң» гыйбарәсе урынында басмада (70 биттә) «кадәм кыйлсаң» дип бирелгән, факсимилесында «кыйлсаң» сүзе урынында «орсаң» дип язылган. Икенче юл басмада (70 биттә) «Ихласилә кәгьбәсари рихдәт кыйлсаң» рәвешендә бирелгән.

Өченче строфадагы «сәфид» сүзе урынында басмада (70 биттә) «сәгыйд», «мәрвәр» сүзе урынында «мөрүр». Икенче юлдагы «бөткән» сүзе урынында басмада (70 биттә): «бәңа». Икенче һәм өченче юлларның ахырларындагы «имеш» сүзләре урыннарында басмада (70 биттә): «ирмеш».

---

[65] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 70–72.

## 22 нче хикмәт

Бу хикмәтнең тулы тексты 2010 елгы басмада ун дүртьюллыктан тора. Түбәндәге дүрт строфалы текст хикмәтнең башындагы өч дүртьюллыгын һәм ахыргы строфасын тәшкил итә.

Өченче строфаның ахыргы ике юлы 2010 елгы басмада бүтәнчә. Шунлыктан, М.Колыйның бу хикмәте, күрәсең, ун строфадан гына тормагандыр дип аңларга мөмкин. Чөнки дүрт кенә строфадан торган өзегендә дә аермалы юллар булуы шуңа ишарә итә.

Тәкъдим ителгән текст 1886 елгы шигъри җыентыкның 4а һәм 4б кәгазьләрендә урын алган. Россиядә эшләнгән, 11x18 см зурлыгындагы кәгазьдән торган әлеге җыентыкта Мәүла Колый хикмәтеннән тыш, С.Бакырганиның «Исмәгыйль кыйссасы» һәм мөнәҗәт язылган. Текстлар көрән төстәге язу карасы белән нәстәгъликъ төрендә теркәлгән. Кулъязманың гомуми сакланышы уртача. Имлясы төзек диярлек, текстта кайбер хәрефләрнең нокталары төшеп калудан тыш, хаталары аз.

Җыентык хәзерге вакытта Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «8685т» шифры белән саклана. Аны Татарстанның Сарман районындагы Яңа Минзәләбаш авылында Салиха Җәләева археограф Альберт Фәтхигә тапшырган. Шул хактагы мәгълүмат кулъязманың 3а кәгазендә кызыл төстәге кара белән, гарәп хәрефләрендә А.Фәтхи тарафыннан теркәлгән. Кайсы елда алынганлыгы күрсәтелмәгән. Фәтхинең экспедицияләр турындагы язмаларыннан ачыклавыбызча, аның бу авылдагы археографик эзләнү эшләре 1973 елның июль һәм август айларында узган.

*4а кәгазь* 1 Хак сүзедер, аңмак кәрәк[66] ошбу Қөръән,
Җан қолағың сагыр булмай, ишетер булса.

[66] Бу сүз кулъязмада төшеп калган, текстка 2010 елгы басма буенча өстәдек.

Күңелең күзе[67] күр булмайын, ачық булса,
    Хақ йулчасы күрмәк кәрәк ошбу Қөръән.

2 Хақ сүз йәнә инде күкдин йир йөзенә,
Вирүб иде Хәбибенең Хақ үзенә[68].
Кем инанса бу Қөръәннең хақ сүзенә,
    Оҗмах таба юл күстәрүр ошбу Қөръән.

3 Айәт-айәт күкдин инде Әхмәденә,
Вир салават Мостафайа вә әүляденә.
Рәсүл һәдийә Қөръән қуйды өммәтенә,
    Аллаһ сари юл рәһбәре ошбу Қөръән[69].

*4б кәгазь* 4 Мәүля[70] Қолый төн-көн эшең ғилем булсун,
Ғилем нуры эчең-тышың тәмам булсун.
Гүр эчрә Қөръән сәңа һәмраһ булсун,
    Оҗмах қапуғын ачқай сәңа ошбу Қөръән.

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Аллаһ сүзе, аңлау кирәк ошбу Коръән,
Җан колагың саңгырау булмый, ишетсә.
Күңелең күзе сукыр булмый, ачык булса,
    Хак юлчысы күрү кирәк ошбу Коръән.

Хак сүз янә инде күктән җир йөзенә,
Биргән иде Хәбибенең Хак үзенә.
Кем инанса бу Коръәннең хак сүзенә,
    Оҗмах таба юл күрсәтер ошбу Коръән.

---

[67] Бу сүзнең соңгы хәрефе кулъязмада теркәлмәгән.
[68] Кулъязмада: «сүзенә».
[69] Бу строфаның соңгы ике юлы 2010 елгы басмада юк.
[70] Мәүла исеме кулъязмада Мулла рәвешендә язылган.

Аять-аять күктән иңде Әхмәденә,
Бир салават Мостафа һәм нәселенә.
Рәсүл бүләк Коръән куйды өммәтенә,
    Аллаһка таба юл күрсәтер ошбу Коръән.

Мәүла Колый, төн-көн эшең гыйлем булсын,
Гыйлем нуры эчең-тышың тәмам тапсын.


حق سوزی دور انکلا اوشبو قرآن
جان قلاغنک صفیر بولمای ایشتور بولسه
کونکلانک کوزی کور بولمای آچق بولسه
حق بولیچه سی کورسنک کراک اوشبو قرآن
حق سوزی دور ایندی کوکدین یر سیرینه
ویروب ایدی حبیب ننک حق سوزینه
کم ایناسه بو قرآن ننک حق سوزینه
او جهاندا تبا یول کوستارور اوشبو قرآن
آیت آیت کوکدین ایندی احمدینه
ویر صلوات مصطفی غه واولادینه
رسول هدیه قرآن قویدی امتینه
الله غه ساری یول رهبری اوشبو قرآن

*22 нче хикмәт. «8685т» шифрлы кульязма.*
*4а кәгазь*

Гүр эчендә Коръән сиңа юлдаш булсын,
Оҗмах капкасын ачар сиңа ошбу Коръән.

*Искәрмәләр*

Бу хикмәт 2010 елгы басма китапта 10 дүртьюллыктан тора[71].

Беренче строфаның беренче һәм икенче юллары басмада (78 биттә) мондагыча тәртиптә түгел, ягъни мондагы беренче юл анда икенче, ә икенче юл анда беренче итеп бирелгән. Икенче юлдагы «ишетүр булса» гыйбарәсе урынында басмада (78 биттә): «ишетүр». Өченче юлдагы «ачыҗ» сүзе урынында басмада (78 биттә) һәм факсимилесында да (315 биттә): «иштүр». Дүртенче юлдагы «күрмәк» сүзе урынында басмада (78 биттә): «кермәк».

Икенче строфадагы «сүз йәнә» өлеше урынында басмада (78 биттә): «санигъ илә». Икенче юлдагы «вирүб инде» гыйбарәсе урынында басмада (78 биттә): «вирүр ирде». Шул ук юл ахырындагы «сүзенә» сүзе урынында басмада «үзенә». Хәбиб – Мөхәммәт пәйгамбәр.

Өченче строфаның беренче юлындагы Әхмәд – Мөхәммәт пәйгамбәр. «Мостафайа вә әүляденә» сүзләре урынында басмада (78 биттә): «Мостафаның әүладинә». Мостафа – Мөхәммәт пәйгамбәр. Өченче һәм дүртенче юллар басмада (78–79 битләрдә) башкача, ягъни:

Һәм салауат әйдең аның әсхабинә,
Җөмләмезгә хаҗәт ирүр ушбу Коръән.

Дүртенче строфаның «Ғилем нуры эчең-тышың тәмам булсун» дигән икенче юлы басмада (78 биттә): «Гыйлем нуры илә эчең-тышың тулсын».

## 23 нче хикмәт[72]

Бу хикмәт тексты Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «2932т» шифры белән сакланучы, 1877–1885 елларга карый торган җыентыкта язылган. Кулъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсе һәм Казан федераль университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Пенза өлкәсенең Лопатин районындагы Сөләү (Сулеевка) авылында Рушан Морадымовтан 1996 елда алынган иде. Сакланышы уртача.

[71] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 78–80.
[72] Бу материал моңарчы өлешчә басылды: Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2021. – Б. 55–59.

Җыентыкта шигъри строфалары гарәп әлифбасы тәртибендәге сүзләр белән башланып киткән 10 төрле тезмә текстның берсе – Мәүла Колыйның 23 нче хикмәте. Калган 9 текстның да эчтәлекләре охшаш, алар барысы да Аллаһы Тәгаләгә сыгынуга багышланган. Шулардан дүртенче текстның гына авторы – Шәмсе Гасый исеме күрсәтелгән, башка авторларның исемнәре (М.Колыйның да) белдерелмәгән. Суфи әдип Шәмсе Гасый исемле авторның шигырьләре «Бакырган» китабында да басылган, ләкин анда бу кульязмадагы шигырь юк.

Мәүла Колыйның 23 нче хикмәте буларак мәгълүм текстка килгәндә, ул моңарчы басылган җыентыгында 9 строфаны (36 шигъри юлны) тәшкил итә[73]. Шул ук хикмәт XIX гасырда Казанда басылган бер китапта да чыккан булган. Аның фотокүчермәсе Камил Дәүләтшин 2010 елда Уфада чыгарган китапта бирелгән (396 бит). Фотокүчермәдәге текстта строфа башларында гарәп алфавиты хәрефләре куелган. Әмма анда иске басманың исеме һәм бүтән мәгълүматы күрсәтелмәгән. М.Колыйның бер хикмәте революциягә (1917 ел, октябрь) кадәр үк басылганын К.Дәүләтшин ачыклаган булуы турында мәгълүмат әдәбият тарихы күптомлыгында 1984 елда ук хәбәр ителгән[74]. К.Дәүләтшин үзе дә Мәүла Колыйның аерым хикмәтләре октябрь инкыйлабына кадәрге басма җыентыкларда дөнья күрүен ачыклавын белдергән[75]. 1984 елгы хезмәттә «бер хикмәте» диелгән булса, соңгырак китапларда «аерым хикмәтләре» дип, күплек санда язылган. Әмма бары тик бер – 23 нче хикмәте генә басмаларда чыкканлыгы мәгълүм. Басмалар турында язганда нинди

[73] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 80–81.
[74] Татар әдәбияты тарихы: алты томда. Т. 1: Урта гасырлар дәвере. – Казан: Татар. китап нәшр., 1984. – Б. 368.
[75] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 5; Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Т. 2: XV–XVIII гасырлар / төз. Р.Рахмани. – Казан: Татар. китап нәшр., 2014. – Б. 242; Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 2 т.: XV–XVIII гасырлар / төз. һәм фәнни мөх. Г.Дәүләтшин. – Яңарт. 2 нче басма. – Казан: Татар. китап нәшр., 2022. – Б. 245.



*23 нче хикмәт.*
*Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә*
*«2932т» шифры белән саклана торган кулъязма.*
*44б кәгазь*

китапта яисә җыентыкларда чыкканлыгы төгәл әйтелмәгән. Мондый хәлне бары тик К.Дәүләтшин карамагында басма китапның исеме, басылган урыны һәм елы күрсәтелгән титул битеннән гайре өлеше генә булгандыр дип фаразларга мөмкин. Югыйсә, күпмедер тираж белән матбагада чыккан китапның төп мәгълүматы белдерелгән булыр иде.

Милли китапханәдәге, алда әйтелгән кулъязмада Мәүла Колыйның шигъри тексты «Алтынчы нәүгы» (ягъни, төр) дип аталган һәм охшашлары арасында алтынчы урынны били (кулъязмада 44а, 44б кәгазьләрдә). Шигырьнең күләме 30 юлдан тора. 2010 елда басылган җыентыктагысы белән чагыштырганда текстында аермалар бар. 2010 ел басмасындагы «Мәүла Колый, Коръән бел...» рәвешендәге, шигырьнең авторы күрсәтелгән юллар кулъязмада юк.

Бу кулъязмадагы Мәүла Колый шигыре һәм шулай ук аңа охшаш бүтән текстлар да XIX гасырда басылган китаптан алынган дип аңлашыла. Моның шулай икәнлегенә ике дәлил бар. Беренчесе – К.Дәүләтшин бастырган җыентыкта бирелгән басма китапның фотокүчермәсендәге текстның Милли китапханәдәге кулъязма текстыннан зур аермалары юк. (Фотокүчермәдәге «Илаһым» сүзенең кулъязмада «Аллаһым» дип бирелүе кебек берничә гыйбарәдән тыш). Икенче дәлил – гарәп алфавиты тәртибендәге шигырьләрнең иң ахырында (46а кәгазьдә) кулъязма иясе «бу китаб басма улынмышдыр... Кукубин мәдрәсәханәсендә Ибраһим угылы Кәлимулланың» дигән юллар. «Басма улынмышдыр Кукубин» сүзләре әлеге текстларның Казандагы Кукубин (Николай Петрович Коковин) матбагасында нәшер ителгән басма китаптан күчерелгәнен белдерә. Ә Кәлимулла – шушы кулъязма җыентыктагы текстларны күчергән кешенең исеме.

Мәүла Колыйның 23 нче хикмәтенең 30 юл күләмендәге тексты басылган, әмма моңарчы фәнни хезмәтләрдә исеме күрсәтелмәгән китапның тулы мәгълүматын Казандагы Кукубин матбагасында нәшер ителгән китаплар даирәсеннән максатчан эзләп, ачыклауга ирештек. Ул китап – «Хоруфе әт-



( ٩ )

بسم الله الرحمن الرحيم

| نوعى | ا ب ت ث ج ح خ د ذ ر<br>ز س ش ص ض ط ظ ع غ<br>ف ق ك ل م ن و ه لا ى * | آلتنچى |
|---|---|---|

( ا ) الله منك برآت آتنك صورصاق الهم *
( ب ) بوستاننك آچامش كرا بلسك الهم *
( ت ) تلاكم سن الله يارلقاغيل الهم *
( — ) ذاكر بولديم لا اله الا الله قبول قيلغيل الهم *
( ث ) ثوابنك كرك در حشر ونشر كوننده *
( ج ) جنتنك روزى قيل جمله قلغه الهم *
( ح ) حياتده طاعتنك قيله باساك پاك الله *
( خ ) خدايم رحمتنكدين اميد درر الهم *
( د ) دولتلو يوللرنك آچوق ترور جباريم *
( ذ ) ذلتلو اشلاردين يراق قيلغيل الهم *
( ر ) رحمتلى ديدارين تلاى باساك تركده *
( ز ) زقومنك شرندين صاقلاغايدنك الهم *
( س ) سعادت اشلاكان ياشون ساچار تركده *
( ش ) شهيدلار ثوابن نصيب ايتكل الهم *
( ص ) صفانى تلايمز حشر ونشر كوننده *
( ض ) ضايع كيچروب عمرمزنى الهم *
( ط ) طاعتكا اوشبوكون اخلاصمنى باغلاسم *
( ظ ) ظلمتلو طاموغنك كورمزايديم الهم *
( ع ) عقل بيردى بزلاركا حق يولنى بلمكا *
( غ ) غفلت يوقوسون بيرمه بزكا الهم *
( ف ) فراقلق كونلارين قورقب توتساق كونكلده *
( ق ) قدرت اشلارنك عياندرر الهم *
( ك ) كلام الله اوقرغه تيل ياراتدى بزلاره *
( ل ) لا اله الا الله قبول قيلغيل الهم *
( م ) ملايم طاعتنك اخلاص تام بغلاسه *

*23 нче хикмәт.*
*«Хоруфе әт-тәһәҗҗи...» исемле китапта*
*(Казан, 1873) басылган*

тәһәҗҗи, ягъни унике төрле әлиф-бидә улгучы мөнәҗәтләр, ягъни фарзы гайн» дип исемләнгән, Казанда «Кукубин табыгханәсендә Гайнулла Фәйзулла угылының хиражәте илән» һиҗри 1290 (милади 1873) елда нәшер ителгән. Китапны бастыруга рөхсәт 1873 елның 2 июнендә бирелгән. Күләме 24 бит булып, анда әлифба тәртибендәге 12 шигъри текст, 17–24 битләрендә чәчмә «Фарзы гайн бәйаны» урын алган. Әлеге китапның 9–10 битләрендә Мәүла Колыйның хикмәте «Алтынчы нәүгы» исеме астында басылган һәм анда да ахыргы юллары (авторы күрсәтелгән өлеше) юк. Алда әйтелгән «2932т» шифрлы кульязма, ачыклавыбызча, нәкъ шушы басмадан күчерелгән.

1873 елда басылган китапның башында «...хәзрәти Сөбханәһә вә Тәгалә ошбу хоруфе тәһәҗҗине хәзрәти Адәм галәйһиссәламә инзаль кыйлмышдыр. Хәзрәти Җәбраил галәйһиссәлам васитасилә ошбу хоруфе һиҗа, ягъни әлифби – мәҗмугысы Кәлямулладандыр. Гафләт улынмайа. «Мәгариҗен-нөбүвәт» китабында мәзкүр»[76] дип язылган. Ягъни, гарәп әлифбасы Адәм пәйгамбәргә үк иңдерелгән һәм бөтен хәрефләре дә Коръәннән диелгән. Шигъри юллар яисә строфа башларын гарәп әлифбасы хәрефләре тәртибендә иҗат итүнең «сихәрфи» дип аталган ысулы мөселман мәдәниятендә әүвәлдән үк билгеле булган. Суфичылык әдәбияты вәкилләре бу ысулга еш мөрәҗәгать иткәннәр. Гомумән, суфичылыкта гарәп хәрефләре күп серләргә бәйләп аңлатылган. Мәүла Колый да 23 нче хикмәтендә шундый шигъри алымны кулланган.

Түбәндә тексты бирелгән кульязмада һәм 1873 елгы китапта М.Колый хикмәтенең ахыргы строфалары юк. Ә анда

[76] Хоруфе әт-тәһәҗҗи, ягъни унике төрле әлиф-бидә улгучы мөнәҗәтләр, ягъни фарзы гайн. – Казан: Кукубин табыгханәсе, 1873. – Б. 2. *Хоруфе тәһәҗҗи* – әлифба, алфавит; *инзаль кыйлмыш* – иңдергән; *васитасилә* – арадашлыгы белән; *мәҗмугы* – барысы; *Кәлямулла* – Коръән; *гафләт* – игътибарсызлык, ваемсызлык; *улынмайа* – булмасын, ителмәсен; *мәзкүр* – әйтелгән; *«Мәгариҗен-нөбүвәт»* – XV гасырда фарсы телендә иҗат ителгән «Мәгариҗен-нөбүвә фи мәдәриҗел-фөтувва» исемле әсәр.

«Һәдийә Коръәнең изыды өммәт хакына», «Йегерме тукыз кәлимәң, Коръән, әйтдүң сән безгә», «Мәүла Колый, Коръән бел, Коръән берлә гамәл кыйл»[77] дигән юллар бар. Хикмәтнең авторы, шул рәвешчә, соңгы строфаларда бу шигырьнең Коръән хәрефләренә бәйлелеген ачык белдергән. Шагыйрьнең иҗатына багышланган хезмәтләрдә Мәүла Колыйның әлеге хикмәтендәге үзенчәлекле шигъри алым турында әйтелмәгән. 2010 елгы басмада хикмәтнең кульязма факсимилесында (316 биттә) һәр строфа башында алфавит тәртибе буенча хәрефләр («әлиф, би, ти» һ.б.) язылган булса да, хәзерге татарча текстында (55–59 битләр) андый хәрефләр күрсәтелмәгән.

Кульязмада хаталар күп түгел, «б» хәрефе урынына «п» язылган очраклар бар.

*44б кәгазь* 1 *әлиф* Аллаһы мең бер ат,
Атың сорсаҡ[78], Аллаһым.
*би* Бостаның ачылмыш,
Керә белсәк, Аллаһым.

2 *ти* Теләгем сән – Аллаһы,
Йарлыҡағыл, Аллаһым.
«Лә иләһә Иллә Аллаһ»[79],
Ҡабул[80] ҡыйлғыл, Аллаһым.

---

[77] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 81. Китапта кайбер сүзләр ялгыш бирелгән һәм мәгънәләре дә дөрес түгел. Мәсәлән, «иңдерде» мәгънәсендәге «изыды» сүзе китапта «Аллаһның «изди» дигән эпитеты» дип, бу очракта гарәп алфавитындагы хәрефләр күздә тотылган «кәлимәң» сүзе «кәлямең – сүзләр» дип, шулай ук, дөресе «Коръән, әйтдүң» урынына «Коръән, итдүң» дип ялгыш басылган.

[78] Кульязмада бу сүздәге икенче «с» хәрефе өстендә ялгыш нокта куелган.

[79] Бу гыйбарә алдында кульязмада «закир булдым» дигән сүзләр теркәлгән. Алар бу хикмәтнең шигъри үлчәменә туры килми һәм, шунлыктан, күчерүчеләр тарафыннан өстәлгән дип аңлашыла. 2010 елгы басмада әлеге сүзләр урынында (80 биттә): «зикрем» диелгән. Шушы ук тексттагы 12 нче строфаның 3–4 нче юлларында да әлеге гыйбарәнең бирелеше безнең фаразны куәтли.

[80] Кульязмада «б» хәрефенең бер ноктасы урынында өч ноктаны белдергән ишарә куелган.

3 *си* Савабың кәрәкдер
Хәшр-ү-нәшер көнендә.
җим Җәннәтең рузи қыйл
Җөмлә қолға, Аллаһым.

4 *хә* Хәйатдә тағатең
Қыйла белсәк пакь, Аллаһ.
*ха* Ходайым рәхмәтеңдин
Өмид дорур, Аллаһым.

5 *дәл* Дәүләтлү йулларың
Ачуқ торур, Җәббарым.
*зәл* Зилләтлү эшләрдин
Йырақ қыйлғыл, Аллаһым.

6 *ра* Рәхмәтле дидарын
Теләй белсәк терекдә,
*за* Зәққумың шәррендин
Сақлағайдең, Аллаһым.

7 *син* Сәғадәт эшләгән
Йәшен сачар терекдә.
*шин* Шәһидләр савабын
Насыйб иткел, Аллаһым.

8 *сад* Сафаны теләймез
Хәшр-ү-нәшер көнендә.
*дад* Зайиғ кичерүб
Гомремезне, Аллаһым.

9 *тый* Тағәткә ошбу[81] көн
Ихласымны бағласам,

[81] Кулъязмада «б» хәрефе урынында «п» язылган.

*зый* Зольмәтлү тәмуғың
Күрмәз идем, Аллаһым.

10 *гәйн* Ғақыл бирде безләргә
Хақ йулыны белмәгә.
*гайн* Ғәфләт йоқусун
Бирмә безгә, Аллаһым.

11 *фа* Фирақлық көннәрен
*қаф* Қурқыб тотсақ күңелдә,
Қөдрәт эшләрең
Ғайан дорыр, Аллаһым.

12 *кәф* Кәлямулла уқырға
Тел йаратды безләрә.
*ләм* Лә иләһә иллә Аллаһ –
Қабул қыйлғыл, Аллаһым.

13 *мим* Мөляем тағәтең
Ихлас тамь бағласа,
*нун* Носрәт һәр эшдә
Сәндин торур, Аллаһым.

14 *уау* Ва вәйля, аһ улур
Қийамәтнең көнендә.
*һә* Һидайәт өмидемез
Сәндин торур, Аллаһым.

15 *ләм-әлиф* Ләйлне қөдрәтдин
Йаратдың сән безләрә.
*йа* Йаманлық төнләрне
Насыйб итмә, Аллаһым.

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Аллаһы мең бер исем,
Исемең сорасак, Аллаһым.
Гөлбакчаң ачылган,
    Керә белсәк, Аллаһым.

Теләгем син – Аллаһы,
Йарлыкачы, Аллаһым.
«Лә иләһә Иллә Аллаһ»,
    Кабул итче, Аллаһым.

Савабың кирәктер
Мәхшәрнең көнендә.
Җәннәтең насыйп кыл
    Барча колга, Аллаһым.

Тормышта тагатең
Кыла белсәк пакь, Аллаһ.
Ходаем рәхмәтеңнән
    Өметтер, Аллаһым.

Дәүләтле юлларың
Ачык торыр, Җәббарым[82].
Хаталы эшләрдән
    Ерак кыл син, Аллаһым.

Рәхмәтле йөзеңне
Тели белсәк дөньяда,
Зәһәрле тәмугдан
    Сакласаңчы, Аллаһым.

---

[82] *Җәббар* – бик көчле-куәтле (Аллаһы Тәгалә).

Рәхәтлек эшләгән
Яшен чәчәр дөньяда.
Шәһидләр савабын
    Насыйп итче, Аллаһым.

Сафаны телибез
Без мәхшәр көнендә.
Заяга кичереп
    Гомребезне, Аллаһым.

Гыйбадәткә бу көн
Ихласымны багласам,
Золымлы тәмугың
    Күрмәс идем, Аллаһым.

Акыл бирде безләргә
Хак юлын белергә.
Ваемсызлык йокысын
    Бирмә безгә, Аллаһым.

Аерылу көннәрен
Куркып тотсак күңелдә,
Кодрәтле эшләрең
    Ачык торыр, Аллаһым.

Коръәнне укырга
Тел яратты безләргә.
Лә иләһә иллә Аллаһ –
    Кабул кыл син, Аллаһым.

Мөлаем тагатең
Ихласым багласа,
Ярдәм һәр эштә
    Синнән торыр, Аллаһым.

Үкенечләр булыр
Кыямәтнең көнендә.
Һидайәт[83] өметебез
    Синнән торыр, Аллаһым.

Кодрәтеңнән төнне
Яраттың син безләргә.
Яманлык төннәрне
    Насыйп итмә, Аллаһым.

*Искәрмәләр*

Бу хикмәт 2010 елгы басмада 9 строфадан тора[84]. Текстның андагыча озын юллар итеп бирелүе шигъри ритмикасына туры килми. Шунлыктан, монда кыска юллы строфалар итеп тәкъдим ителде. Ягъни, шушы китаптагы ике строфа 2010 елгы басмадагы бер дүртьюллыкка туры килә.

Кулъязмадан алынган һәм шулай ук 1873 елда басылган китаптагы текстларда ахыргы строфалары (2010 елгы басма китаптагы соңгы дүртьюллык) юк.

Кулъязмадан күчерелеп монда бирелгән текстта һәм шулай ук 1873 елгы басмада (9–10 битләрдә), 2010 елда чыккан китаптагы кулъязма факсимилесында (316 биттә) шигъри юллар алдында гарәп алфавитының хәрефләре куелган. Димәк, шундый үзенчәлекле поэтик алым кулланылган – шигъри юллардагы сүзләр нәкъ шундый хәрефләрдән башланган. Бу шигырь-хикмәтнең төп мәгънәсе дә шуннан гыйбарәт.

1873 елда чыккан китапта һәм хәзерге басма өчен кулланылган кулъязмада М.Колый хикмәтенең гарәп әлифбасы хәрефләреннән артык булган, ягъни текст ахырындагы – авторы да белдерелгән строфалары төшереп калдырылган.

Беренче һәм икенче строфаларның икенче һәм дүртенче юллары, ә 3–15 нче строфаларның дүртенче юлларындагы «Аллаһым» сүзләре 1873 һәм 2010 еллардагы басмаларда «илаһым» дип бирелгән.

Беренче строфаның икенче юлындагы «сорсаҗ» сүзе урынында 2010 елгы басмада (80 биттә): «сорсам».

Өченче строфаның икенче юлындагы «хәшр-ү-нәшер» сүзләре басмада (80 биттә): «хәшер-нәшер». Дүртенче юл – «җөмлә ҫолға, Аллаһым» урынында басмада (80 биттә): «кыйамәт көн булганда».

Дүртенче строфаның беренче юлындагы «тағатең» сүзе урынын-

---

[83] *һидайәт* – туры юлга керү.

[84] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 80–81.

да басмада (80 биттә): «қоллыгың». Икенче юлдагы «белсәк» сүзе урынында басмада (80 биттә): «белсәм». Өченче һәм дүртенче юллар басмада (80 биттә): «халайык аралаб рәхмәтең бар, шаһым».

Бишенче строфаның беренче юлындагы «дәүләтлү йулларың» сүзләре урынында басмада (80 биттә): «дәүләтең йуллары». Дүртенче юлдагы «йырақ қыйлғыл» сүзләре урынында басмада (80 биттә): «аригъ булсак».

Алтынчы строфаның беренче юлындагы «рәхмәтле дидарын» сүзтезмәсе урынында басмада (80 биттә): «рәгъна дидарың». Икенче юлдагы «белсәк» сүзе урынында басмада (80 биттә): «белсәм».

Җиденче строфаның беренче юлындагы «сәғадәт эшләгән» гыйбарәсе урынында басмада (80 биттә): «солтанлигъ эстәгән». Икенче юлындагы «йәшен» сүзе урынында басмада (80 биттә): «йәшләр». Өченче һәм дүртенче юллардагы «шәһидләр савабын насыйб иткел» җөмләсе урынында басмада (80 биттә): «Шуридә зәкъкумең күрмәйен тиб илаһым».

Сигезенче строфаның беренче юлындагы «сафаны» сүзе урынында (80 биттә): «сафалигъ». Икенче юлдагы «хәшр-ү-нәшер» сүзләре урынында басмада (80 биттә): «хәшер һәйһат».

Тугызынчы строфаның икенче юлындагы «ихласымны бағласам» сүзтезмәсе урынында басмада (81 биттә): «ихласымыз багласак». Дүртенче юлдагы «идем» сүзе урынында басмада (81 биттә): «ирдек».

Унынчы строфаның беренче һәм икенче юллары басмада (81 биттә): «гакыл бирде Хакъ коллык йулыни белмәгә».

Уникенче строфаның беренче юлындагы «Кәлямулла» сүзе урынында басмада (81 биттә): «кәлямең». Икенче юлдагы «тел йаратды безләрә» сүзләре урынында басмада (81 биттә): «кол йаратуң сән бези».

Унөченче строфадагы «мөляем» сүзе урынында басмада (81 биттә): «мөлязим». Икенче юл басмада (81 биттә): «булды безгә терекдә». Өченче юлдагы «эшдә» сүзе урынында басмада (81 биттә): «эшкә».

Ундүртенче строфаның беренче һәм икенче юллары басмада (81 биттә): «вәйлә аһ-ваһ булур безгә кыйамәт ул көннәрдә». Өченче юлдагы «һидайәт өмидемез» сүзтезмәсе урынында басмада (81 биттә): «һәдийәт өмидемсез».

Унбишенче строфа басмада башкача (81 биттә): «Лям, әлиф, ләйләт әл-кадер төне бирдүң, илаһым».

## 25 нче хикмәт

Бу хикмәтнең тексты Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «8686т» шифры белән саклана торган кулъязмадан алынды. Әлеге җыентыкның тасвирламасы шушы бүлектәге 16 нчы

хикмәт (икенче текст) алдында бирелде. Имлясы тотрыксыз, аерым сүзләр хаталы язылган.

*19а кәгазь* Хикмәт

1 Ғинайәттүр инүлүр
Рәхмәт Қәдер төнендә,
Қолларына бирүлүр
Дәүләт Қәдер төнендә.

2 Күк хиҗабы ачулур,
Йиргә рәхмәт сачүлүр,
Гөнаһларың кәчүлүр
Уйағ Қәдер төнендә.

3 Рузә[85] тотыб, қыйл намаз,
Гөнаһыңдин бул хәляс,
Хақға йығлаб қыйл нийаз –
Қабул Қәдер төнендә.

4 Қәдер төндә[86] тор уйағ,
Қул күтәрүб қыйл доға,
Ни теләсәң – бирүр Хақ
Теләң Қәдер төнендә.

5 Рамазан айы[87] ничәсе,
Йегерме йите шәбб қайсы,
Шулдур Қәдер кичәсе,
Йатма Қәдер төнендә.

6 Қәдер төнең белгәнләр,
Йатмай[88], уйағ торғанлар[89],

---

[85] Бу сүз кулъязмада «рузи» дип ялгыш теркәлгән.
[86] Кулъязмада: төнендә.
[87] Кулъязмада бу сүз «әйтте» дип ялгыш язылган.
[88] Бу сүз кулъязмада «йатлы» дип ялгыш теркәлгән.
[89] Кулъязмада бу сүзнең «р» хәрефе төшеп калган.



*25 нче хикмәт. «8686т» шифрлы кулъязма.*
*19а кәгазь*

Морадын булғанлар
    Булды Қәдер төнендә.

7 Қәдер төне сәғадәт[90],
Йатма төнне, қыйл тағәт,
Хақдин булур ғинайәт
    Күрклүк Қәдер төнендә.

*19б кәгазь* 8 Күк хиҗабы йазылур,
Хақдин бер нур белүнүр,
Дәүләтлегә күренүр
    Ул нур Қәдер[91] төнендә.

9 Нур булур күккә бәйан,
Һәркемгә булса ғәйан,
Дөнйа[92]-ахирәт әман
    Булур Қәдер төнендә.

10 Ул нурны күргән адәм
Җәннәттә[93] булур әман,
Хақ теләген бирде тәмам –
    Табты Қәдер төнендә.

11 Мәүля Қолый, намаз қыйл,
Қәдер төнен уйағ тор!
Хақға йығлаб тәүбә[94] қыйл –
    Кичүрүр Қәдер төнендә.

[90] Бу сүз кулъязмада «сәққад» дип ялгыш язылган.
[91] Кулъязмада ике сүзнең урыннары ялгыштырып «Қәдер нур» дип теркәлгән.
[92] Бу сүз кулъязмада «дөнйада» дип ялгыш теркәлгән.
[93] Бу сүзнең «тә» кушымчасы кулъязмада теркәлмәгән.
[94] Бу сүзнең соңгы хәрефе кулъязмада теркәлмәгән.

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Ярдәм нуры юнәлер
Рәхмәт Кадер төнендә,
Колларына бирелер
    Дәүләт Кадер төнендә.

Күк пәрдәсе ачылыр,
Җиргә рәхмәт чәчелер,
Гөнаһларың кичелер
    Уяу Кадер төнендә.

Ураза тотып, намаз кыл,
Гөнаһыңнан азат бул,
Хакка елап нияз кыл –
    Кабул Кадер төнендә.

Кадер төндә уяу тор,
Кул күтәреп дога кыл,
Ни теләсәң – Хак бирер,
    Телә Кадер төнендә.

Рамазан ае ничәсе,
Егерме җиде, яна кайсы,
Шулдыр Кадер кичәсе,
    Ятма Кадер төнендә.

Кадер төнең белгәннәр,
Ятмый, уяу торганнар,
Теләгәнен тапканнар
    Булды Кадер төнендә.

Кадер төне ул рәхәт,
Ятма төнне, кыл тагать,
Алладан булыр ярдәм
    Күркәм Кадер төнендә.

Күк пәрдәсе ачылыр,
Хактан бер нур беленер,
Дәүләтлегә күренер
    Ул нур Кадер төнендә.

Нур булыр күккә ачкыч,
Һәркемгә ачык булса,
Дөнья-ахирәт имин
    Булыр Кадер төнендә.

Ул нурны күргән адәм
Җәннәттә табар әман,
Хак теләген бирде тәмам –
    Тапты Кадер төнендә.

Мәүла Колый, намаз кыл,
Кадер төнен уяу тор!
Хакка елап тәүбә кыл –
    Кичерер Кадер төнендә.

*Искәрмәләр*

Бу хикмәт 2010 елгы басмада да 11 строфадан тора[95]. Андагы беренче строфа түбәндәгечә (83 биттә):

Гыйнайәт нуры рәхмәт –
Кадер төндә,
Колларына булур рәхмәт –
Кадер төндә.

Икенче строфадагы «Йиргә рәхмәт сачүлүр» дигән икенче юлы урынында басмада (83 биттә): «Кадер төндә».

Дүртенче строфаның икенче юлындагы «доға» сүзе басмада (83 биттә): «теләк». Өченче юлдагы «бирүр» сүзе урынында басмада «булур» дип бирелгән, гәрчә факсимилесында (317 биттә) «бирүр» дип язылган.

Алтынчы строфаның беренче юлындагы «төннең» сүзе урынында басмада (83 биттә): «төнен».

Җиденче строфаның дүртенче юлындагы «күрклүк» сүзе урынында басмада (84 биттә): «күргел».

[95] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 83–84.

Сигезенче строфаның икенче юлындагы «белүнүр» сүзе урынында басмада (84 биттә): «бирелүр». Өченче юлдагы «дәүләтлегә» сүзе урынында басмада (84 биттә) «дәүләтигә».

Тугызынчы строфаның беренче юлындагы «күккә» сүзе урынында басмада (84 биттә): «күкдә».

Унынчы строфаның өченче юлындагы «теләген» сүзе урынында басмада (84 биттә): «теләгән».

## 52 нче хикмәт

Бу хикмәт тексты язылган кәгазьнең зурлыгы 8х14 см күләмендә, XIX гасыр башында Россиядә эшләнгән. Текст көрән төстәге язу карасы белән нәстәгъликъ төрендә, башындагы исеме һәм юл араларын белдергән кечкенә түгәрәксыман тамгалар кызыл кара белән теркәлгән.

Мәүла Колый шигыре җыентыкта «Мөнаҗат-вәгазь» дип исемләнгән һәм 5 строфадан тора. Авторының исеме күрсәтелгән соңгы строфасы теркәлмәгән. Язуы төзек, хатасыз. Сүз уртасындагы «гайн» хәрефләре, «фа» һәм «каф» кебек, түгәрәксыман рәвештә язылган.

Кульязма хәзерге вакытта Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «6748т» шифры белән саклана, ул Актаныш районындагы Калмаш авылында Мөзәянә Әгъзамовадан 1977 елда археограф Альберт Фәтхи тарафыннан алынган. Шул турыдагы мәгълүматны кульязманың 3а кәгазендә «АЭ–77...» дип башлап, кызыл төстәге язу карасы белән А.Фәтхи теркәгән. Бу кульязманың сакланышы уртачадан түбән: кәгазьләре шактый таушалган һәм пычранган, кайбер битләрендә язулары начар таныла.

*34а кәгазь* Мөнаҗат-вәгазь

1 Әй, сән ғафил, сән ғафил,
Хақны белмәс кәм ғақыл!
Хақны белмәс башларға
Нигә кирәк бу ғақыл?

2 Рузә, намаз, фарыз бел,
Һәрбер хәлдә шөкер қыйл!
Шөкер қыйлмас наданға
Нигә кирәк ошбу тел?

*34б кәгазь* 3 Була күргел Хақға қол,
Булыб сәхи, ихсан қыйл!
Ихсан қыйлмаз ахмақға
Нигә кирәк ошбу қул[96]?

4 Иртән сәхәр тор уйағ,
Мәсҗид сари бас айақ,
Мәсҗид сәүмәс наданға
Нигә кирәк бу айақ?

5 Ғәни, биһтәр ғөмер бир!
Хәл барында тағәт қыйл!
Тағәт-намаз қыйлмағач,
Нигә кирәк бу ғөмер?

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Әй, син гафил, син гафил[97],
Хакны белмәс ким акыл!
Хакны белмәс башларға
Нигә кирәк бу акыл?

Ураза, намаз, фарыз бел,
Һәрбер хәлдә шөкер кыл!
Шөкер кылмас наданга
Нигә кирәк ошбу тел?

[96] Бу сүз урынында кульязмада «тел» дип ялгыш теркәлгән.
[97] *гафил* – надан, ваемсыз.



*52 нче хикмәт. «6748т» шифрлы кулъязма.*
*34б кәгазь*

Була күр син Хакка кол,
Булып юмарт, ярдәм кыл!
Ярдәм кылмас ахмакка
    Нигә кирәк ошбу кул?

Иртән таңда тор уяу,
Мәчет таба бас аяк,
Мәчет сөймәс наданга
    Нигә кирәк бу аяк?

Гани[98], күркәм гомер бир!
Хәл барында тагать кыл!
Тагать-намаз кылмагач,
    Нигә кирәк бу гомер?

*Искәрмәләр*

Бу хикмәт 2010 елгы басмада 8 строфадан тора[99].

Беренче строфаның беренче юлындагы «әй, сән» сүзләре урынында басмада (129 биттә): «сән-сән».

Икенче строфаның икенче юлындагы «хәлдә» сүзе урынында басмада (129 биттә): «сүздә».

Өченче строфадагы «ахмакға» сүзе урынында басмада (129 биттә): «бәхилгә».

Дүртенче строфаның башындагы «иртән сәхәр» сүзләре урынында басмада (129 биттә): «тагъәт кыйла». Өченче юлдагы «наданга» сүзе урынында басмада (129 биттә): «җаһилгә».

Бишенче строфа басмада (130 биттә) башкачарак:

Ганимәтдүр гомер бел!
Йатма көни тагъәт кыйл,
Хакъны белмәз адәмгә,
    Нигә кирәк бу гомер?

[98] *Гани* – бай (Аллаһы Тәгаләнең мактаулы исеме).
[99] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 129–130.

## Ике хикмәтнең кушылмасы[100]

Кулъязма истәлекләрдә Мәүла Колый әсәрләренең аерым өлешләре үзара кушылып һәм башка шигырьләргә өстәлеп киткән мисаллар күренгәли. Мәсәлән, Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «433т» шифры белән саклана торган, XIX гасырның икенче яртысына нисбәтле кулъязмадагы[101] (162б–163а кәгазьләр) шигъри юлларга игътибар итик. Анда язылган сигез строфалы һәм һәр дүртьюллыгы ахырында кабатланган ике юллы рефренлы шигырьнең (кулъязмада ул «Робагый шәриф» дип исемләнгән) бер өлеше түбәндәгечә:

*162б кәгазь* Иртә сәхәр торайық,
Мәсҗид сари барайық.
Мәсҗид сәүмәз қолларға
Нигә кирәк бу айақ?!
*163а кәгазь* Һу Аллаһ, Һу Аллаһ, җан Аллаһ,
Җаным, иманым Илләллаһ.

Әй, сән ғафил, сән ғафил,
Хақлый белмәз кем ғақил!
Хақны белмәз қолларға
Нигә кирәк бу ғақыл?
Һу Аллаһ, Һу Аллаһ, җан Аллаһ,
Җаным, иманым Илләллаһ.

Менә бу шигъри юлларның бераз гына аермалы вариантлы моннан алда тексты бирелгән 52 нче хикмәттәге дүртенче һәм беренче строфалары икәнлеге күренеп тора.

Ә «433т» кулъязмасындагы «Робагый шәриф»нең «Һу Аллаһ...» рефренындагы шигъри юллар шулай ук Мәүла

---

[100] Бу материал моңарчы басылды: Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар ..., 2021. – Б. 53–54.

[101] Кулъязманы күренекле дин эшлеклесе, Татарстанның баш мөхтәсибе һәм баш казые Габделхак хәзрәт Саматов (1930–2009) бу юлларның авторына 1994 елның 2 июнендә тапшырган иде.

Колыйның 35 нче хикмәтендә бар. Анда әлеге юллар (бераз башкачарак булса да) өч мәртәбә кабатланган. Мәсәлән (рефрен өлеше курсив белән күрсәтелде):

Бостан кыйлдың галәмне,
Кодрәтең бар, *һу Аллаһу.*
Солтан кыйлдың адәмне,
Рәхмәтең бар, *һу Аллаһу.*
*Җан Алла, җаным иманым: илля Алла*[102].

Болардан күренгәнчә, М.Колыйның хикмәтләре төрлечә (өлешчә һәм үзгәргән хәлендә), үзенчәлекле кушылып та йөртелгән.

***

Бу кулъязмадагы «Робагый шәриф»нең башындагы 6 строфалы тексты Мәүла Колый әсәрләре арасында басылмаган һәм аның авторы кем булганлыгы анык билгеле түгел. Ахырындагы ике дүртьюллыгы М.Колыйныкы икәнлеге төгәл мәгълүм. Башындагы өлешенең авторы М.Колый булуы да мөмкин, һәрхәлдә, бу мәсьәлә хәзергә ачыкланмаган килеш кала. Киләчәктә эзләнүләр һәм ачыклык кертү өчен мәгълүмат булсын дип «433т» шифрлы кулъязмадагы шигъри әсәрнең тулы текстын тәкъдим итәбез.

*162б кәгазь* Робағый шәриф

1 Қомған алдым қулыма,
Қоллығым Тәңре йулына.
Қомған алмай йөрегән
Төшәр тәмуғ төбенә.
Һу Аллаһ, Һу Аллаһ, җан Аллаһ,
Җаным, иманым Илләллаһ.

[102] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый..., 2010. – Б. 99.



*Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «433т» шифры белән саклана торган кулъязма. 162б кәгазь*

2 Тәмуғ – Тәңре қәһһари,
Йанар ләйл-ү-нәһари.
Әсиргәмез бел һаман
Йөзләре гөлбәһари.
Һу Аллаһ, Һу Аллаһ, җан Аллаһ,
Җаным, иманым Илләллаһ.

3 Тәмуғ тора ағыз ачыб,
Йалан-йалан ут сачыб.
Хәбибуллаһ булмаса,
Кемсә қотулмас қачыб.
Һу Аллаһ, Һу Аллаһ, җан Аллаһ,
Җаным, иманым Илләллаһ.

4 Оҗмах Тәңре күшәге,
Қызыл алтун ишеге.
Эче тулу бел һаман
Йопар, ғәнбәр, мишеге.
Һу Аллаһ, Һу Аллаһ, җан Аллаһ,
Җаным, иманым Илләллаһ.

5 Оҗмах тулы хурлари,
Айдин ары[103] йөзләри,
Күрсә күңле ачарур
Һаман сафа йөзләри.
Һу Аллаһ, Һу Аллаһ, җан Аллаһ,
Җаным, иманым Илләллаһ.

6 Гүзәл йегет авазлари,
Айәт, хәдис сүзләри.
Қийамәт көн булғанда
Аппақ булсун йөзләри.

[103] *ләйл-ү-нәһари* – төнлә һәм көндез; *әсиргәмез* – кызганабыз; *гөлбәһари* – яз гөле; *ағыз* – авыз; *сачыб* – чәчеп; *Хәбибуллаһ* – пәйгамбәр; *күшәк* – сарай; *йопар, ғәнбәр, мишек* – җофар, гамбәр, мишек (хуш исләр); *ары* – якты, саф.

Һу Аллаһ, Һу Аллаһ, җан Аллаһ,
Җаным, иманым Илләллаһ.

7 Иртә сәхәр торайык,
Мәсҗид сари барайык.
Мәсҗид сәүмәз қолларга
Нигә кирәк бу айақ?!
*163а кәгазь* Һу Аллаһ, Һу Аллаһ, җан Аллаһ,
Җаным, иманым Илләллаһ.

8 Әй, сән ғафил, сән ғафил,
Хақлый белмәз кем ғақил!
Хақны белмәз қолларға
Нигә кирәк бу ғақыл?
Һу Аллаһ, Һу Аллаһ, җан Аллаһ,
Җаным, иманым Илләллаһ.

Әлеге шигырь-хикмәтнең нәкъ шундый ук диярлек тагын бер күчермәсен Казан университеты китапханәсендә «8683т» шифры белән саклана торган, XIX гасырга нисбәтле кулъязмада да (2б кәгазендә) барлыгын ачыкладык. Бу кулъязма Казан федераль университеты һәм Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Пермь өлкәсенең Барда районындагы Аклыш авылында Тәгъсимә Куштановадан 2001 елда алынган.

Анысы «Мөнаҗәт» дип исемләнгән. Ике тексттагы кайбер сүзләрдә зур булмаган аермалар бар. Мәсәлән, өченче строфадагы «йалан-йалан» сүзе урынында университет күчермәсендә «йылан-чайан», бишенче строфадагы «йөзләри» сүзе урынында «нурлары» һәм «күңле ачарур» сүзтезмәсе урынында «күңелне ачар». Ә Милли китапханә кулъязмасындагы һәр строфа саен кабатланган рефрен гыйбарәсе университет күчермәсендә бары тик бер тапкыр – иң ахыргы строфадан соң гына язылган.

Университет китапханәсендә саклана торган күчермә текстының соңгы өч строфасы түбәндәгечә тәртиптә.




*Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «8683т» шифры белән саклана торган кульъязма. 2б кәгазь*

6 Иртән сәхәр тор уйағ,
Мәсҗид сари бас айағ.
Мәсҗид сәүмәз қолларға
Нигә кирәк бу айақ?!

7 Әй, сән ғафил, сән ғафил,
Хаклый белмәз кәм ғақыл!
Хакны белмәз қолларға
Нигә кирәк бу ғақыл?

8 Гүзәл йегет үзеңез,
Айат, хәдис сүзеңез.
Қийамәт көн булғанда
Аппақ булсун йөзеңез.
Һу Аллаһ, Һу Аллаһ, җан Аллаһ[104],
Җаным, иманым Илләллаһ.

## 68 нче хикмәт

Бу хикмәтнең тексты Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «8686т» шифры белән саклана торган кулъязмадан алынды. Аның тасвирламасы шушы бүлектәге 16 нчы хикмәт (икенче текст) алдында бирелде.

*21а кәгазь* Хикмәт

1 Булғусыдур қийамәт,
Нитәк чара иткәймез?
Малдин хисаб Хақ теләр[105] –
Нитәк хисаб биргәймез?

[104] Кулъязмада «җан Аллаһ» гыйбарәсе ике мәртәбә кабатланган.
[105] Бу сүздәге «т» хәрефенең ике ноктасы урынына кулъязмада ялгыш бер генә нокта куелган.



*68 нче хикмәт. «8686т» шифрлы кулъязма.*
*21а кәгазь*

2 Қыйлды дөнйа әүвәрә,
Ғәмәл йуқ вә[106] йөз қара.
Қийамәт көн бичара
Нитәк җаваб биргәймез?

3 Күрүб ғибрәт алмадуқ,
Хақ қоллығун қыйлмадуқ,
Йөзне йиргә қуймадуқ –
Нә йөз берлә барғаймыз?

4 Бу тән бер көн түшәнүб,
Кәфен тунун йасануб,
Башсыз атқа атлануб,
Гүр ивенә киткәймез.

5 Мәүля Қолый, киләсе –
Җөмлә қалмай үләсе.
Гүрдин йәнә терелүб
Җәмиғ мәхшәр булғаймыз.

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Булачактыр кыямәт,
Ничек чара итәрбез?
Малдан хисап Хак сорар –
Ничек хисап бирербез?

Кылды дөнья әүвәрә,
Гамәл юк һәм йөз кара.
Кыямәт көн бичара,
Ничек җавап бирербез?

[106] Кулъязмада «вә» теркәгече юк, текстка безнең тарафтан өстәлде.

Күреп гыйбрәт алмадык,
Хак коллыгын кылмадык,
Йөзне җиргә куймадык –
    Ни йөз белән барырбыз?

Бу тән бер көн түшәнеп,
Кәфен киемен ясанып,
Башсыз атка атланып,
    Гүр өенә китәрбез.

Мәүла Колый, киләсе –
Барча калмай үләсе.
Гүрдән янә терелеп
    Барча мәхшәр булырбыз.

*Искәрмәләр*

Бу хикмәт 2010 елгы басмада 6 строфадан тора[107].

Икенче строфаның икенче юлындагы «ғәмәл» сүзе урынында басмада (151 биттә): «гыйлем».

Өченче строфаның өченче юлындагы «қуймадуқ» сүзе урынында басмада (151 биттә): «ормадык».

Дүртенче строфа басмада (152 биттә) хикмәтнең иң соңгы дүртьюллыгы итеп бирелгән. Дүртенче строфаның беренче юлындагы «түшәнүб» сүзе басмада (152 биттә): «каушаныб».

## 74 нче хикмәт

Бу хикмәтнең тулы тексты Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «8688т» шифры белән саклана торган кулъязмадан алынды. Аның тасвирламасы шушы бүлектәге 16 нчы хикмәт (беренче текст) алдында бирелде.

[107] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 151–152.



*74 нче хикмәт. «8688т» шифрлы кулъязма.*
*1б кәгазь*

*1б кәгазь* Хикмәт

1 Зина сүзүн һәркем телендә сүзләр булса,
Хәшер көне рисвайлык чигәр дирләр.
Зина қыйлғум тәйү һәркем күңлегә алса,
Қийамәт көн қурку-хәтәр күрәр дирләр.

2 Һәркем қыйлса зина, ләззәт табуб монда,
Қийамәт көн төрлүк ғазаб күрүр анда.
Рисвай қыйлыб қийамәт халқы арасында
Берәм-берәм мондағ җәза қыйлур дирләр.

3 Зиначылар тәүбә қыйлмай барса үлүб,
Қийамәт халқы ара килсә терелеб,
Тәнләрендин төрлүк сасық исләр[108] килеб,
Ләғнәт қыйлу, хәляиқлар қачар дирләр.

4 Зиначының тешисене ичле асыб,
Иркәгене салыр түбән билгә қысыб.
*2а кәгазь* Тешисенең әндамендин нәҗес чықыб,
Иркәгенең ағызы үзрә ақар дирләр.

5 Андин соңра тәмуғ илә ғазаб қыйлур,
Йылан-чайан тәнләрене бәрбәр қыйлыр.
Зиначылық җәзаларын ул көн булур,
Хәсрәт берлә фөрйад-фиған қыйлур дирләр.

6 Ғақил ирсәң, зина эшен асан белмәң,
Зина қыйлма, Хакдин тәүбә-тәүфиқ теләң.
Тағәт қыйлу, Хақ эшенә бағлаң билең,
Зиначыға төрлүк ғазаб булур дирләр.

7 Мәүла Қолый, тәүфиқ телә, зина қылма,
Зина қыйлыб, ғарасат көн рисвай булма!

---

[108] Бу сүзнең башында булырга тиешле «әлиф» хәрефе кульязмада теркәлмәгән.

Тәмуғның ғазабларындин[109] асан белмә,
Бер зина өчен йитмеш хөқеб йанар дирләр.

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Зина сүзен һәркем телендә сөйләр булса,
Мәхшәр көнне рисвайлык чигәр диләр.
Зина кылыйм дип һәркем күңленә алса,
Кыямәт көн курку-хәтәр күрер диләр.

Һәркем кылса зина, ләззәт табып монда,
Кыямәт көн төрле газап күрер анда.
Рисвай кылып кыямәт халкы арасында
Берәм-берәм шундый җәза кылыр диләр.

Зиначылар тәүбә кылмый барса үлеп,
Кыямәт халкы арасында терелеп,
Тәннәреннән төрле сасы исләр килеп,
Ләгънәт кылып, халыклар качар диләр.

Зиначы хатын-кызны эченнән асып,
Ир-атларын салыр түбән билен кысып.
Хатынының әгъзасыннан нәҗес чыгып,
Ир-атының авызыннан агар диләр.

Аннары соң тәмуг белән газап кылыр,
Елан-чаяннар тәннәрен талар-кыркыр.
Зиначылык җәзаларын ул көн табар,
Хәсрәт белән елап, зар-моң кылыр диләр.

Акыллы булсаң, зина эшен җиңел белмә,
Зина кылма, Хактан тәүбә-тәүфыйк телә.
Тагать кылып, Хак эшенә билең багъла.
Зиначыга төрле газап булыр диләр.

[109] Бу сүз кулъязмада «ғазабламдин» дип, хаталы теркәлгән.

Мәүла Колый, тәүфыйк телә, зина кылма,
Зина кылып, кыямәт көн рисвай булма!
Тәмугъның газаплары җиңел дип белмә,
Бер зина өчен җитмеш гасыр янар диләр.

*Искәрмәләр*

Бу хикмәт 2010 елгы басмада да 7 строфадан тора[110].

Беренче строфаның «телендә сүзләр булса» өлеше урынында басмада (159 биттә): «ирсә теле сүзләр». Икенче юлдагы «көне» сүзе урынында басмада (159 биттә): «көндә». Өченче юлдагы «күңлегә» сүзе урынында басмада (159 биттә): «күңелгә». Дүртенче юлдагы «қурқу» сүзе урынында басмада (159 биттә): «куркыб».

Икенче строфаның өченче юлындагы «қийамәт» сүзе басмадагы текстта, шул исәптән факсимилесында да (159 һәм 367 битләрдә) юк. Шул ук юлдагы «халкы» сүзе урынында басмада: «халык». Дүртенче юлдагы «берәм-берәм мондағ» сүзләре урынында басмада (159 биттә): «бер-беринә мендереб». Шул ук юлдагы «қыйлур» сүзе басмада «кыйлгай» дип бирелгән, гәрчә факсимилесында «кыйлур» дип язылган.

Өченче строфаның икенче юлындагы «қийамәт» сүзеннән соң басмада (159 биттә) «көн» дигән сүз бар. Шул ук юлдагы «халқы» сүзе басмада: «халык». Дүртенче юлдагы «қыйлу» сүзе урынында басмада (159 биттә): «кыйлур».

Дүртенче строфаның беренче юлындагы «ичле» сүзе урынында басмада (159 биттә): «ганә». Өченче юлдагы «әндамендин» сүзе урынында басмада (159 биттә) «анда-монда» дип ялгыш бирелгән, чөнки факсимилесында (367 биттә) ачык итеп «әндамендин» дип язылган. Шул ук юлдагы «чықыб» сүзе урынында басмада (159 биттә): «акыб».

Бишенче строфаның икенче юлындагы «бәрбәр қыйлыр» сүзләре урынында басмада (159 биттә): «бер-бер теләр». Өченче юл ахырындагы «булур» сүзе урынында басмада (160 биттә): «күрүр».

Алтынчы строфаның өченче юлындагы «тағәт» сүзе урынында басмада (160 биттә): «тәүбә». Шул ук юлдагы «бағлаң билең» сүзләре «билең багълаң» рәвешендә.

Җиденче строфадагы «ғарасат» сүзе урынында басмада (160 биттә): «кыйамәт». Өченче юл басмада: «Тәмугының газабларын асан күрмә». Дүртенче юлдагы «хөқеб» сүзе урында басмада (160 биттә) ялгыш «гокъбә» дип бирелгән, гәрчә факсимилесында (368 биттә) дөрес рәвештә «хөқеб» дип язылган.

---

[110] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 159–160.

## 78 нче хикмәт

Бу хикмәтнең күчермәсе Россиядә XIX гасыр башында эшләнгән, 17,5х22 см зурлыгындагы, ачык яшькелт төстәге кәгазьдә ачык көрән кара белән, нәстәгъликъ төрендә язылган.

Элекке җыентыктан калган бер кәгазьнең 1а битендә җеназа турындагы татарча әсәр тексты тәгәлләнгән урындагы буш мәйданында Мәүла Колыйның әлеге хикмәте теркәлгән. Ул кәгазьнең иңе буенча, ягъни төп әсәр текстына аркылы рәвештә, ике багана итеп язылган. Баганаларның ян-якларында һәм икесенең уртасында вертикаль рәвештә, кызыл төстәге язу карасы белән гади түгәрәксыман бизәкләр ясалган. Хикмәтнең башында исеме юк, ахырында «кадь тәммә булды» (тәмам булды) дип язылган. Кулъязманың 1б кәгазендә пәйгамбәр хәдисләренә багышланган, гарәп телендәге «Китабел-лөбаб» текстының башы теркәлгән. Саклanышы уртача.

Мәүла Колыйның 78 нче хикмәте язылган кулъязма ядкяр хәзерге вакытта Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «8771т» шифры белән саклана. Аны Татарстанның Актаныш районындагы Яңа Кормаш авылында Сания Дәүләтгәрәй кызы Әхмәтова (1910 елда туган) археограф Альберт Фәтхигә тапшырган. Шул хактагы мәгълүмат 1б кәгазендә кызыл төстәге кара белән гарәп хәрефләрендә А.Фәтхи тарафыннан теркәлгән, ләкин елы күрсәтелмәгән. А.Фәтхинең эш хисаплары турындагы язмаларыннан ачыклавыбызча, аның бу авылдагы археографик эзләнүләре 1977 елның июль аенда узган.

Әлеге хикмәт, төзелеше ягыннан, Мәүла Колыйның иң күркәм шигырьләреннән берсе. Һәр строфа ахырындагы шагыйранә нәфис юлларның укучыларга тәэсире бәхәссез. Бу хикмәтне: «Мәүла Колыйның күңелне җәлеп итәрлек авазлар яңгырашына, кабатлауларга нигезләнеп [иҗат ител-

гән], искиткеч музыкаль аһәңле [әсәре]»[111]дип, Камил Дәүләтшин бик хаклы бәяләгән.

*1а кәгазь* 1 Ирүр дөнйа бер сағәт,
Нә йатурсән? Қыл тағәт!
Бу җан тәндә әманәт –
Белгел, беләй, бел сәнә.

2 Дөнйа ирүр, бел, фани,
Тәүфиқ эстә, қуй ани.
Тәүбә утына бағлаб
Йан, йан, йанай, йан сана.

3 Бу тереклек бозылур,
Тән[112] туфрақға тигелүр,
Қорт-қарынча нәзелүр,
Тан, тан, танай, тан сана.

4 Зәбун дөнйа төзәнүб,
Килен кебек бизәнүб,
Алданмаға йасануб...
Қач, қач, қачай, қач сана.

5 Бу дөнйада хасыйлең –
Ун қари бүз кәфенең.
Тар ләхетдә урының –
Йат, йат, йатай, йат сана.

6 Бу дөнйаға алдануб,
Үзеңне бер ир[113] сануб,

[111] Татар әдәбияты тарихы: алты томда. Т. 1: Урта гасырлар дәвере ..., 1984. – Б. 384; Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 234.
[112] Кулъязмада: тын (тин).
[113] Кулъязмада: йир.

Тағәт қыйлмай, буш[114] қалуб
    Ғафилләрдин аң сана[115].

7 Ачқыл күзең[116] – ғибрәт күр,
Ғақлың тирүб йулға кер[117].
Хақның әмре[118] – тағәт қыл,
    Қыйл, қыйл, қыйлай, қыйл сана.

8 Булғусыдур[119] қийамәт,
Олуғ атлығ ғәламәт,
Ғәмәллеккә[120] сәламәт,
    Аң, аңлағул, бул сана[121].

9 Мәүла Қолый, нәсыйхәт[122]:
Сәңа тигәр ғәқибәт.
Гүргә таба киткәнне
    Күргел, күрәй, күр сәнә.

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Булыр дөнья бер сәгать,
Ник ятасың? Кыл тагать!
Бу җан тәндә әманәт –
    Бел син, бел, әй, бел сәнә.

Дөнья булыр, бел, фани,
Тәүфыйк телә, куй аны.

[114] Кулъязмада бу сүзнең ахыргы хәрефе язылмыйча калган.
[115] «Аң сана» сүзләре кулъязмада хаталы теркәлгән.
[116] Кулъязмада бу сүзне язганда «күз» дигәч ике хәреф ялгыш язылып, сызылган. Шуннан соң дөрес кушымчасы теркәлгән.
[117] Бу сүз кулъязмада «сә» рәвешендә, ялгыш язылган.
[118] Кулъязмада: «әмрене».
[119] Бу сүз кулъязмада «бағлусыдур» дип, ялгыш язылган.
[120] Бу сүз кулъязмада бераз хаталырак теркәлгән.
[121] Кулъязмада: булсын.
[122] Кулъязмада бу сүз алдында теркәлгән «бу» сүзе артык.

Тәүбә утына баглап
    Ян, ян, ян, әй, ян сана.

Бу тереклек бозылыр,
Тән туфракка керер,
Корт-кырмыска урнашыр,
    Тан, тан, тан, әй, тан сана.

Шакшы дөнья төзәнеп,
Килен кебек бизәнеп,
Алданырга ясанып...
    Кач, кач, кач, әй, кач сана.

Бу дөньяда табышың –
Ун карыш бүз кәфенең.
Тар ләхеттә урының –
    Ят, ят, ят, әй, ят сана.

Бу дөньяга алданып,
Үзеңне бер ир санап,
Тагать кыйлмый, буш калып
    Аңсыздан аңла сана.

Ач син күзең – гыйбрәт күр,
Акылың җыеп юлга кер.
Хакның әмре – тагать кыл,
    Кыл, кыл, кыл, әй, кыл сана.

Булачактыр кыямәт,
Зур исемле галәмәт,
Гамәллеккә сәламәт,
    Аң, аңла син, тап сана.

Мәүла Колый, нәсыйхәт:
Сиңа тияр ниһаять.




*78 нче хикмәт.*
*«8771т» шифрлы кульязма. 1а кәгазь*

Гүргә таба киткәнне
Күр син, күр, әй, күр сәнә.

*Искәрмәләр*

Бу хикмәт 2010 елгы басмада да 9 строфадан тора[123].

Икенче строфаның өченче юлындагы «бағлаб» сүзе урынында басмада (164 биттә): «йакулуб». Дүртенче юлындагы «йанай» сүзе урынында басмада «йангай» дип ялгыш бирелгән, чөнки факсимилесында (369 биттә): «йанай».

Өченче строфаның икенче юлындагы «тигелүр» сүзе урынында басмада (164 биттә): «түкүлүр». Өченче юлдагы «нәзелүр» сүзе урынында басмада (164 биттә): «тезүлүр». Дүртенче юлдагы «Тан, тан, танай, тан сана» сүзләре урынында басмада (164 биттә): «Тән-тән, тәнәй, тәнсәнә». Кульязмаларда бу сүз гарәп әлифбасының йомшак «тә» һәм «нун» хәрефләре белән язылган булса да, аның автор вариантындагы дөресе – «тан» (тану – кире кагу, белмәгәнгә салыну) сүзе булганлыгында шигебез юк. Чөнки башка строфаларның дүртенче юлларындагы сүзләр дә боерык фигыль төрләнешләре булганлыгы шуны белдерә һәм монда аваз ияртеме рәвешендәге «тән-тән...» кулланылган дияргә нигез юк.

Дүртенче строфаның беренче юлындагы «зәбун» сүзе урынында басмада (165 биттә): «кари». Өченче юлындагы «алданмаға» сүзе урынында басмада (165 биттә): «алдамага». Дүртенче юлы басмада: «Кач, качкынай, качсана».

Бишенче строфаның беренче юлындагы «дөнйада хасыйлең» сүзтезмәсе урынында басмада (165 биттә): «дөнъйадин китәсең». Өченче юлдагы «урының» сүзе урынында басмада (165 биттә): «үренеб». Дүртенче юлы басмада: «Йат, йаткынай, йатсана».

Алтынчы строфаның дүртенче юлы басмада (165 биттә): «Гаф, гафилин, аңсана».

Сигезенче строфаның дүртенче юлындагы «бул сана» сүзе урынында басмада (165 биттә): «сорсанә».

Тугызынчы строфаның икенче юлындагы «тигәр» сүзе урынында басмада (165 биттә): «тийәр».

## 79 нчы хикмәт

Бу хикмәтнең тексты барлыгы ун дүртьюллыктан тора. Ләкин аларның җидесе 2010 елгы китаптагы строфаларга туры килми, бары тик башындагы өч строфа гына (1, 2,

[123] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 164–165.

3 нче дүртьюллыклар 2010 елгы басмадагы 6, 7 һәм 8 нче строфаларга) өлешчә тәңгәл килә. Ә 4–10 нчы строфалар басмада юк. Иң соңгы – автор исеме язылган дүртьюллык та басма китапта бүтәнчә. Димәк, шагыйрьнең бу хикмәте күләм ягыннан зур булса да, электән билгеле җыентыкларда тулысынча теркәлмәгәнлеге аңлашыла. Соңгы ачыкланган кулъязма ярдәмендә хикмәт текстына тагын җиде дүртьюллык өстәлә. Шулай итеп, 2010 елда басылган 9 строфалы хикмәтнең тексты хәзер тулыланган рәвештә барлыгы уналты дүртьюллыкны тәшкил итә. М.Колый иҗат иткән бу хикмәтнең тагын да бүтән күчермәләре ачыкланса, строфалар саны артуы да ихтимал.

Тәкъдим ителгән текст XIX гасырның беренче яртысында Россиядә эшләнгән, 11x18 см зурлыктагы кәгазьгә теркәлгән. Хикмәт-шигырь җыентыкның 13а–14а кәгазьләренә язылган. Әлеге кулъязмада, Мәүла Колый шигырьләреннән тыш, мөнәҗәтләр, гарәп телендә намаз тәртипләре аңлатылган «Шөрутес-саләт» текстлары бар. Алар караңгы төстәге көрән язу карасы белән нәстәгъликъ төрендә теркәлгән.

Җыентыкның Габделфәттах бине мулла Габделмәҗид исемле кеше тарафыннан күчерелгәнлеге күрсәтелгән. Сакланышы уртача. Язуы шактый бозык һәм хаталары күп. Аерым сүзләрне бик читенлек белән генә төшенергә мөмкин.

Бу кулъязма ядкяр хәзерге вакытта Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «8684т» шифры белән саклана. Аны Татарстанның Актаныш районындагы Яңа Балтач авылында Әкмәлетдин Гыйльметдин улы Гыйльметдиневтән (1896 елда туган) археограф Альберт Фәтхи 1976 елда алган. Шул хакта кулъязманың 3а кәгазендә кызыл төстәге кара белән гарәп хәрефләрендә А.Фәтхи тарафыннан «АЭ–1976...» дип башлап теркәп куелган.

Кулъязмада М.Колый хикмәтенең башында исеме юк. Ул «Бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим» дигән гыйбарә белән башланган.



*79 нчы хикмәт. «8684т» шифрлы кулъязма.*
*16а кәгазь*

اولوب بارسنگ کور ایچنده بولور راحت
قیامت کون حقا کورسیز رحمت جنتنی
اخلاص ایله حقه طاعت قیلمشگنزنی
آچماسونلار جهنمنی یارور بوسنگ نی
مشکل اولور تموغ ایچی سنگ حالوسنگ
حق عذاب آلوریلان آچیانکل تنغ سنگ
بو دنیاده فحشا ایمانکو کتمشنکه نی
ربایلارسنکا عذاب او حق
آدمیلار توکیب توروور قالورن یاشونی
حقا منحی رحمتدین کیتمش اوحق
بو دنیاده یا توبه قیلماغان کو کتمشنکه نی
ربایلارسنکا شفقت قیلما بسی نی
تموغ اهل اوچماح ایله هیچ قاطلاشماسی
توبه قیلمغل اوسنکا نوبه هوسنک توبه قلماسی
نفس گناه سنی یور قیلمشنکه نی
سکسان حقب جهنمده اولان بولغای نی

شش

16б кәгазь

17

شش اولتصنده کوب مشقت بسمله قیلدی
کورن لالار بسکا یاشع لتب قانغ اقجادی
هیچ علارسن نمالارک قوه لمشلر ایه
سولالا شور لما آی لره هیچ تلی فالماس
رحمت آلمش ملک لاروبه شفقت بولماس
یلان چیان هوحاب آلمشلر ءینا
تنلارینکه بر یانی یانالایت اوسبب
جواب بیردی رحمان کنی تاقشتر قیلب ءر
هم تنلارن بی وح ادلوب اوت یا نور
طاقت قالماس روح قوحم یو لمشلر ایه
بو لموسنگز او یاع لتوب یاشر تولارو سنگز
قولی قوی بوالاده کوب هشرو سنگز
الاق بولور جها نلبنا هدو ابل سنرو سنک
هیبت او لوم مخنا به ادلوب گیتمشلر ینا

تمت تمام بولدی

*17а кәгазь*

*16а кәгазь* 1 Үлүм сәңа һәмраһ[124] улмыш, ғақылға кил,
Тәүбә қыйлу, тағат қыйлу Хакға қол бул!
Үлүм сәңа гүргә таба күрсәтүр йул,
Хәсрәт тотғыл гүренә бармышыңдин.

2 Мескин адәм, гүр өйенә[125] төшде йулуң.
Нәтәк булғай гүр эчендә сәнең халең?..
Ачмасунлар тәмуғ сари барур йулың,
Хаққа[126] қоллық-тағатең аз булмышыңдин.

3 Қыйлмыш булсаң бу дөнйада[127] рузә-тағат,
*16б кәгазь* Үлүб барсаң гүр эчендә булур рахәт.
Қийамәт көн Хак күрсәтер рәхмәт – җәннәт,
Ихлас илә Хаққа тағәт[128] қыйлмышыңдин.

4 Ачмасунлар җәһәннәмгә барур йулың,
Мөшкил улур тәмуғ эчрә сәнең халүң[129].
Чолғаб алур йылан-чайан көлли тәнүң,
Бу дөнйадин хәфиф[130] иман күчмешеңдин.

5 Зөбанилар сәңа ғазаб қыйлған[131] өчүн
Адәмиләр түгеб торур қанын-йәшен.
Хаққа хазы рәхмәтдин китмеш өчүн,
Бу дөнйадин тәүбә қыйлмай күчмешеңдин[132].

---

[124] Кулъязмада бу сүз «кәмраһ» дип, хаталы теркәлгән.
[125] Кулъязмада: гүренә.
[126] Бу сүз кулъязмада бер генә «қ» хәрефе белән теркәлгән.
[127] Бу сүз кулъязмада «дөнйа» дип теркәлгән.
[128] «Хаққа» сүзе кулъязмада бер генә «қ» хәрефе белән теркәлгән, «тағәт» сүзе «тағийәт» рәвешендә язылган.
[129] Бу сүз кулъязмада «халәлүң» дип, ялгыш язылган.
[130] Кулъязмада бу сүз «хәйфаз» рәвешендәрәк теркәлгән. Аның дөресе «хифзы» булган дип фаразлаганда, «хифзы иман» (иман саклап) дигән гыйбарә текст мәгънәсенә туры килми. Шунлыктан, «хәфиф» (аз, җиңелчә, зәгыйфь) сүзе бозып язылгандыр дип гөманладык.
[131] «Қыйлған» сүзе кулъязмада юк, текстка безнең тарафтан өстәлде.
[132] Бу сүздәге «ч» хәрефенең өч ноктасы кулъязмада куелмаган.

6 Зөбанилар сәңа һич тә[133] шәфкәт қыйлмас,
Тәмуғ әһле оҗмах[134] илә һич қатланмас.
Тәүбә қыйлғыл! Үлгәндин соң нәүбәт[135] булмас,
Нәфс-ү-гөмраһ сәне ғорур қыйлмышыңдин.

7 Сиксән хөқеб җәһәннәмдә урун булғай,
*17а кәгазь* Алтысында[136] күб мәшәқәт сәҗдә қыйлғай.
Күзләренең[137] йәше бетүб, қаны ақғай,
Һич ғөзерсез намазларың қуймышыңдин.

8 Сүзләшүргә ағзында һич теле қалмас,
Рәхмәт алмыш мәләкләрдин шәфқәт булмас.
...[138]
Йылан-чайан сине[139] чолғаб алмышыңдин.

9 Тәнләренең бер йақы йанар ит үсеб,
Җаваб бирер[140] Рахман күни тавыш қыйлыб.
Һәм тәнләре мәҗрух улуб утта[141] йануб[142],
Тақәт қалмас зәһәр-зәққум йотмышыңдин.

10 Йатмассың[143], уйағ торыб йәш түгәрсәң,
Мәүла Қолый, бу арада күб хосрансың.

---

[133] «Һич тә» гыйбарәсе кульязмада юк, текстка безнең тарафтан өстәлде.
[134] «Әһле» сүзенең соңгы хәрефе кульязмада теркәлмәгән, «оҗмах» сүзе исә «очмах» дип язылган.
[135] Кульязмада бу сүз ялгыш «нәүб» дип кенә язылган.
[136] Бу сүз кульязмада «ултысында» дип теркәлгән һәм аның алдында язылган «шәш» (фарсы телендәге «алты» дигән мәгънәдәге) сүзе артык. Ул күчерүчеләр тарафыннан өстәлгән булса кирәк. Чөнки, беренчедән, шигъри үлчәм буенча бу юлга туры килми. Икенчедән, «алты» дигәнне белдергән фарсыча сүзнең монда язылуы урынсыз.
[137] «Күзләренең» сүзендәге «р» хәрефе өстенә ялгыш бер нокта куелган.
[138] Бу урында булырга тиешле шигъри юл кульязмада теркәлмәгән.
[139] Бу сүз кульязмада юк, текстка безнең тарафтан өстәлде.
[140] Кульязмада: бирде.
[141] Кульязмада бу сүз «ут» дип кенә теркәлгән.
[142] Бу сүз кульязмада «йанур» дип теркәлгән.
[143] Бу сүз кульязмада «йулмусаң» («булму сәнең») рәвешендәрәк, хаталы теркәлгән.

Азаҡ булур җиһандин чөн бел сәфәрүң,
Һәйбәт үлүм ғәзаб[144] улуб китмешеңдин.

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Үлем сиңа юлдаш булган, акылга кил,
Тәүбә кылып, тагать кылып, Хакка кол бул!
Үлем сиңа гүргә таба күрсәтер юл,
Хәсрәт тот син гүренә бармышыңнан.

Мескен адәм, гүр өенә төште юлың.
Ничек булыр гүр эчендә синең хәлең?..
Ачмасыннар тәмуг якка барыр юлың,
Хакка коллык-тагатең аз булганыннан.

Кылган булсаң бу дөньяда рузә-тагать,
Үлеп баргач гүр эчендә булыр рәхәт.
Кыямәт көн Хак күрсәтер рәхмәт – җәннәт,
Ихлас белән Хакка тагать кылганыңнан.

Ачмасыннар җәһәннәмгә барыр юлың,
Мөшкел булыр тәмуг эчендә синең хәлең.
Чолгап алыр елан-чаян бөтен тәнең,
Бу дөньядан аз иманлы күчкәнеңнән.

Зөбанилар сиңа газап кылган өчен
Адәмнәр түгеп торырлар канын-яшен.
Хакка өлеше рәхмәттән киткән өчен,
Бу дөньядан тәүбә кылмый күчкәнеңнән.

Зөбанилар сиңа һич тә шәфкать кылмас,
Тәмуг әһле оҗмах белән һич катышмас.
Тәүбә кыл син! Үлгәннән соң нәүбәт булмас,
Нәфес-бозык сине горур кылганыннан.

[144] Кулъязмада бу сүз «мәзаб» дип, хаталы теркәлгән.

Сиксән гасыр җәһәннәмдә урын булыр,
Алтысында күп мәшәкать сәҗдә кылыр.
Күзләренең яше бетеп, каны агар,
Һич сәбәпсез намазларың калдырганнан.

Сөйләшергә авызында теле калмас,
Рәхмәт алган фәрештәләрдән шәфкать булмас.
...[145]
Елан-чаян сине чолгаб алганлыктан.

Тәннәренең бер ягы янар ит үсеп,
Җавап бирер Рахман көчле тавыш кылып.
Тәннәре җәрәхәтләнеп утта янып,
Тәкать калмас ачы агу йотканыңнан.

Ятмассың, уяу торып яшь түгәрсең,
Мәүла Колый, бу арада күп үкенәсең.
Азагы булыр җиһаннан бел сәфәрең,
Куркыныч үлем газап булып киткәнеңнән.

*Искәрмәләр*

Бу хикмәт 2010 елгы басмада 9 дүртьюллык күләмендә урын алган[146]. Алда әйтелгәнчә, аларда аермалар бар.

Беренче строфаның икенче юлындагы «қыйлу» сүзе урынында басмада (166 биттә): «кыйлыб». Өченче юлдагы «гүргә таба» сүзләре урынында басмада (166 биттә): «күз тотубән».

Икенче строфаның беренче юлындагы «мескин адәм, гүренә» сүзләре урынында басмада (167 биттә): «имде белең, гүр өйенә». Дүртенче юлдагы «Хаққа қоллық» сүзләре урынында басмада (167 биттә): «Хакъ коллыгы».

Өченче строфадагы «қыйлмыш булсаң бу дөнйада» сүзләре урынында басмада (167 биттә): «тереклекдә кыйлган булсаң».

[145] Бу урында булырга тиешле шигъри юл кульязмада теркәлмәгән.
[146] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 165–167.

# ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК: МӘҮЛА КОЛЫЙНЫКЫ БУЛУЛАРЫ ИХТИМАЛ ШИГЫРЬЛӘР

Бу бүлектә тәкъдим ителгән шигъри әсәрләрдән кайберләренең авторлары киләчәктә төгәлрәк ачыкланырга мөмкин. Чөнки кайбер шигырьләрнең авторлары күрсәтелгән ахыргы строфалары хәзергәчә сакланмаган яисә күчереп язучылар аларны бөтенләй төшереп калдырганнар. Шундый мисаллар бу китапның икенче бүлегендә дә искәртелде (мәсәлән, Мәүла Колыйның 5, 17, 52 нче хикмәтләре). Шулай ук М.Колыйның 1873 елгы басма китапта чыккан 23 нче хикмәтенең ахырындагы автор исеме язылган строфалары юк. Әлеге мисаллар кебек үк, өченче бүлектә бирелгән текстларның авторлары теркәлгән башка кулъязма күчермәләре ачыкланса, алардан, бәлки, иҗат итүчеләренең исемнәре дә беленер.

### «Мөэмин...» хикмәте[1]

Әдәбиятыбыз тарихында авторлыгы төгәл ачыкланып бетмәгән бер әсәргә тукталыйк. Ул – Мәүла Колый шигыре буларак, 1963 елда бер кулъязма күчермәсенең факсимилесы белән 19 строфадан торган тексты басылган «Мөэминнәр, Халикъ сонгыны...» дип башланган хикмәт[2].

Галим Шакир Абилов бу хикмәт текстына беренчеләрдән буларак игътибар иткән. М.Колыйның 5 нче санлы хикмәтенең тексты да күчерелгән кулъязма җыентык уңаеннан

[1] Бу материал моңарчы өлешчә басылды: Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар ..., 2021. – Б. 59–69.

[2] Борынгы татар әдәбияты / төз.: Х.Мөхәммәтов, Х.Хисмәтуллин, Ш.Абилов, Ү.Беляева, С.Исәнбаев. – Казан: Татар. китап нәшр., 1963. – Б. 498–503.

ул болай дип язган: «1957 елның апрель аенда СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтының (Ленинград) кульязмалар бүлегендә шагыйрьнең ике хикмәте табылды... Бу ике хикмәтне Г.Сәгъдидә булган мисаллар белән чагыштырганның соңында яз һәм кошлар турындагысы Мәүла Колыйның 36 нчы хикмәтенә, мелла Мамайга багышланганы – 5 нче хикмәтенә караганлыгы беленде. Яз һәм кошлар турындагы хикмәттә барысы 19 строфа – 76 юл... Бу шигырьнең теле гади, күпләргә аңлаешлы. Әмма Сәгъди кулындагы өзекләр белән чагыштырып караганда, аның аерымлыклары да юк түгел. Бу төрлелекне – күчергәндә кертелгән үзгәрешләр нәтиҗәсе дип карарга кирәк»[3].

Әлеге кульязмадагы 5 нче хикмәт ахырында Мәүла Колый исеме урынында «Меллагол Кол» дип язылган. Бу уңайдан Камил Дәүләтшин «Ш.Абилов Мәүла Колый белән Меллагол Колның икесен бер шәхес санап, «Меллагол Кол» имзасы куелган хикмәтләрне дә фәнни кулланышка кертеп җибәрде» дип белдергән[4]. Әмма Ш.Абилов ике хикмәтнең берсе – Мәүла Колый имзасы белән аңарчы билгеле булган 5 нче хикмәт икәнлеген ачык күрсәткән. Менә шул хикмәт ахырында гына (бары тик бер кульязмадагы ялгыз очракта!) «Меллагол Кол» дип язылган. Ә Абилов 36 нчы хикмәт дип тәгаенләгәнендә «Меллагол Кол» дигән автор исеме юк. Димәк, К.Дәүләтшинның «Ш.Абилов «Меллагол Кол» имзасы куелган хикмәтләрне фәнни әйләнешкә кертеп җибәрде» дигән сүзләре төгәл түгел. Ул «Борынгы татар әдәбияты» китабында 36 нчы хикмәт исеме белән беренче мәртәбә басылган[5] текстны гына күздә тоткан. Ә анда, әйткәнебезчә, автор имзасы «Меллагол Кол» диелмәгән.

Шигырьнең соңгы строфасында «Кол Сөләйман яз күрде» дигән юлы бар. Моңа караганда, аның авторы

[3] Абилов Ш. Шагыйрьнең исеме Мәүла Колыймы әллә Меллаголмы // Совет әдәбияты. – 1958. – №11. – Б. 107–108.
[4] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 8.
[5] Борынгы татар әдәбияты ..., 1963. – Б. 498–503.

Сөләйман Бакыргани булырга тиеш кебек. Әмма галимнәр бу шигырьнең җидешәр иҗектән торган үлчәме Бакыргани-да юк дип белдергәннәр[6] һәм, шуңа да нигезләнеп, шигырь авторы М.Колый дип тәгаенләгәннәр.

Хакыйкатьтә, С.Бакырганиның җидешәр иҗек үлчә-мендәге шигырьләре аз түгел (мәсәлән, «Иске-оскы бүркем бар...», «Әй, дустлар, үлсәм мәнем...», «Мөэмин коллар иңрәйү...» дип башланган һ.б. шигырьләре[7]). Моны искә алганда, 1963 елгы китапны төзегән галимнәр ялгыш-кандыр кебек. Әмма, икенче яктан караганда, Мәүла Ко-лый хикмәтләренең ахырындагы строфаларында үз исеме белән бергә Кол Гобәйди һәм Кол Сөләйманны да бергә күрсәткән очраклары аз түгел бит[8]. Ә ике шигырендә, бө-тенләй үзенең исемен язмыйча, ахырда «Мескин Әхмәд» һәм «Кол Габди» дип кенә күрсәткән[9]. Шунлыктан, «Мөэмин, Халикъ сыйфатын» дип башланган шигырь, чынлап та, М.Колыйныкы булуы ихтимал. Тагын да өстәп әйтик, әлеге шигырьдә ике мәртәбә язылган «Тәңре» сүзен Бакыргани үз әсәрләрендә кулланмаган диярлек. Һәрхәлдә, аның кырыктан артык шигъри әсәрләренең берсендә генә («Ярым алма»да) бер мәртәбә «Тәңре» атамасын күрдек. Ә Мәүла Колый текстларында бу сүз еш очрый. Ике авторның әсәрләрен тел ягыннан тәфсилләп өйрәнгәндә, мәсьәлә төгәлрәк ачыкланыр иде.

---

[6] Шунда ук. – Б. 486.

[7] Бакырган. – Казан: Кукубин табыгханәсе, 1858. – Б. 10–11.

[8] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 50, 55, 74, 92, 106, 117. Бу китапта Кол Гобәйди исеме ялгыш Кол Габиди дип бирелгән.

Кол Гобәйди исемле авторның шигырь-хикмәтләре иске кульязма җыентыкларда очрый. Кайбер хикмәтләре «Бакырган» китабында да бар. Әлеге әдип исемен «Габиди» рәвешендә ялгыш итеп язуның беренче очрагын әдәбият галиме Габдрахман Сәгъдинең 1927 елгы мәкаләсендә (Сәгъди Г. Беренче дәвер татар әдәбиятыннан яңа материаллар // Мәгариф. – 1927. – №4. – Б. 69–70) күрдек. Совет чорындагы кайбер бүтән галимнәр дә Г.Сәгъди хатасына иярепме яисә үзләренең укылышлары буенчамы – Гобәйди исемен Габиди дип хаталандылар. Хәзергәчә шулай ялгыш язып килүчеләр бар әле (Шигъри ядкярләр: XII–XIX ..., 2021. – Б. 233–234).

[9] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 101, 190, 191.

Шунысы да мөһим, М.Колый шигырьләрендә (36 нчы сан белән билгеләнгән хикмәтендә) 1963 елгы әдәбият тарихы китабында басылган текстка якын һәм аваздаш юллар бар. Мәсәлән, М.Колый җыентыгында:

Күгәрчен әйтүр: «аһ-аһ», –
«Иң Сөбхан Раббел-әгъла»...

Үрдәк әйтүр: «Йә, Рахман»,
Казлар әйтүр: «Йә, Сөбхан!»...

Дуадакның өне йук,
Сүзләмәгә теле йук, ...

Карга әйтүр: «Йә Алла»,
Әңгут әйтүр: «Илля Алла»,
Ләк-ләк әйтүр: «Кольһу Алла»,
Коръән эчрә, солтаным[10].

1963 елгы китапта:

Күгәрчен әйтүр аңа:
Сөбханә рәббиәл-әгъла, ...

Үрдәк әйтер: я рахман,
Казлар әйтер: я сөбхан, ...

Тудак әйтер: өнем юк,
Сүзләмәгә телем юк, ...

Карга әйтер: я алла,
Әнкгут әйтер: илла алла,
Ләк-ләк әйтер: «Коль һөвәалла»,
Килде Коръән эчендә[11].

[10] Шунда ук. – Б. 103–104. Мондагы өземтәдә икенче юл башындагы «иң» дип китапта басылган сүзнең дөресе – гарәп телендәге «иннәкә», ул «чыннан да, син» мәгънәсенә ия.
[11] Борынгы татар әдәбияты..., 1963. – Б. 500, 502.

Чынлыкта да, Мәүла Колый 1963 елгы китапта басылган шигырьнең авторы булып, ул текст аның иҗатының бер варианты буларак таралыш алгандыр дип фаразларга мөмкин. Чөнки әлеге текстның кулъязмаларда охшашлары һәм кайбер аермалары булган вариантлары шактый очрый. Әлеге шигырьнең Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә һәм Казан университетының Фәнни китапханәсендә саклана торган ике дистәгә якын күчермәсе безгә мәгълүм. Шигырьнең чагыштырмача җиңел аңлаешлы гади теле һәм кызыклы тасвирлары күчерүчеләрнең игътибарын яулагандыр, күрәсең.

Бу шигырьнең берничә күчермәсендә строфалар саны артыграк. Мәсәлән, Казан университеты китапханәсендәге «7301т» кулъязмасындагы тулы булмаган тексты да 26 строфадан тора. Анда исә күпчелек күчермәләрдә аталган кошлардан башка, тагын 10 кош (әтәч, былбыл, саргыш, сыерчык, чарлак, бүдәнә, алатүбә, тормыртка, тартай, баркылдык) исемнәренә бәйле шигъри юллар бар. Мәсәлән,

Әтәч әйтер зикрене:<br>«Йад итәйен Тәңрене...»

Төп мәгънәви кыйммәтеннән тыш, борынгы төрки һәм иске татар телләрендәге кошлар исемнәрен өйрәнү өчен дә бу әсәр бик кызыклы.

Түбәндә бирелгән текстның 16 нчы дүртьюллыгы башындагы «күке» сүзе кайбер кулъязмаларда «киек» (кыр кәҗәсе) дип язылып, өченче юлында «кузыларым асраган» (ягъни, «бәрәннәрем...») диелгән. Ләкин башка строфаларда кошлар турында гына сүз барганга күрә, «киек» белән аның «кузылары» – күчерүчеләр тарафыннан үзгәртелгәне аңлашыла. Кайбер күчермәләрдә бу строфа башында «күке» дип һәм «балаларым асраган» (берничә кулъязмада: «балаларым очырган») рәвешендә теркәлгән. Шулай да, аерым кулъязмаларда (мәсәлән, Татарстан Милли китапханәсендәге «7419т» нөсхәсе, 33а кәгазендә) ялгышлык белән «киек» диелсә дә, шунда ук «балаларым очыр-

ган» дип язылган. Бу исә «күке» һәм «киек» сүзләренең язылышы берникадәр охшаш булганга күрә генә төрлечә язып йөртелгәненә дәлил булып тора.

1963 елгы басмадагы хаталы гыйбарәләр төрле кулъязмалар ярдәмендә ачыклана. Мәсәлән, ул басмадагы «Сөләйманга көстахмын» дигәннең бүтән күчермәләрдәге «инакмын» варианты дөресрәк. Чөнки, «инак – инанычлы, ышанычлы, киңәшче» мәгънәсендә, ә «көстах – әрсез, әдәпсез, кыю» дигәнне белдерә һәм контекстка яраш-мый. Ә шул ук китаптагы «язны алты ай яратты» дигән гыйбарә кайбер күчермәләрдә «Җирне алты көн яратты» (ягъни, Аллаһы Тәгалә алты көндә барлыкка китерде) дип теркәлгән. «Яз алты ай» дигәне исә ялгышлык түгел. Чөнки Мәүла Колыйның 29 нчы хикмәтендә Аллаһы Тәгалә кодрәте белән «алты ай яз» һәм «алты ай кыш»ның яшьлек белән картлыкны белдергән символик мәгънәләрен күздә тотып язылган фикерләре бар[12].

Югарыда М.Колый җыентыгыннан мисаллар китерелгән 36 нчы хикмәте күләме ягыннан шактый зур һәм анда кошлар гына түгел, агачлар, агымсу, җанварлар һәм бүтән җан ияләре – бөтенесенең Аллаһы Тәгаләгә зикер-мактау укып торулары тасвирланган. Кызганыч ки, Мәүла Колый әсәрләрен төзеп бастырган галим Камил Дәүләтшин 1963 елгы китапта чыккан шигырьгә карата фикерен ачык итеп белдермәгән һәм җыентыгында ул текстны бирмәгән. (М.Колый иҗатын тәфсилләп өйрәнгән галимнең карашы бәхәсле мәсьәләне чишү өчен хәлиткеч булыр иде). Үзе әзерләп бастырган Мәүла Колый җыентыгына кертмәгәч, бу шигырьне анык буларак танымаган дип аңлашыла. Ләкин әдәбият тарихында урын алган мәсьәлә булганлыктан, бу шигырьнең М.Колыйныкымы-түгелме икәнлеге төгәлрәк әйтелүе зарур иде.

[12] Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 89.

Мәсьәләнең шул ягын да искәртик, бу шигырь Сөләйман Бакырганиның һәммә әсәрләре бергә тупланган дип билгеләнгән, 2009 елда нәшер ителгән «Борынгы әдәбият» җыентыгында да юк. Бакыргани шигырьләре урын алган «Бакырган» китабының XVIII–XIX гасырлардагы күчермәләрендә, XIX гасыр һәм XX гасыр башындагы күпсанлы басмаларында да бу шигырь юк. Димәк, әлеге хикмәтне Бакырганига нисбәт итәрлек ачык дәлил дә табылмаган диярлек.

Шигырьнең авторы М.Колый булган очракта ул үзенең 36 нчы хикмәтендәге кошлар тасвирланган өлешен соңрак камилләштергән һәм өстәп язган дип уйларга мөмкин. Бу гаҗәп түгел, чөнки аның бер үк темага, аерым мәсьәләгә кабат-кабат мөрәҗәгать итүе бүтән әсәрләрендә дә күренә.

***

Әдәбият галиме Марсель Әхмәтҗанов бу шигырьнең 1907 елгы кулъязма җыентыктагы вариантын бастырганлыгын[13] да искә алырга кирәк. Анда 1963 елда Мәүла Колыйныкы дип басылган шигырьнең дәвамы рәвешендә «Кеми Мәҗнүн, кеми услы...» сүзләре белән башланган 31 юл күләмендәге текст башка шигырьдән икәнлеге ачык күренеп тора. Сигезәр иҗекле шигъри юлларның эчтәлеге дә бүтәнчә.

Барлыгы 92 юллы шигъри текст биреп, аның ахырында М.Әхмәтҗанов болай дип язган: «Бу шигырь XVII гасыр татар шагыйре Мәүла Колый әсәредер. Ул фәндә мәгълүм, фәнни хезмәтләрдә басылып чыккан (Борынгы татар әдәбияты. – Казан: Татар. китап нәшр., 1963. – Б. 498–503). Ләкин кулъязма текст басмадан (20 строфа, 80 юл) зуррак. Анда 23 дүрт юллык, барсы 92 юл бар»[14]. Мондагы 92 юл

---

[13] Әхмәтҗанов М. Татар археографиясе: соңгы елларда археографик экспедицияләр вакытында тупланган кулъязмаларның тасвирламалары. Сигезенче кисәк. – Казан, 2011. – Б. 155–156.
[14] Шунда ук. – Б. 157.

диелгән текстның ахырына ялгыш ялганган 31 юлыннан гайресе 61 юл кала. Ә 31 юллы шигъри өзек, дөреслектә, XVIII гасыр төрек шагыйре Әхмәдинең татарлар арасында яратып укылган «Гыйбрәтнамә вә шөкернамә» исемле популяр әсәреннән[15].

Татар кульязма истәлекләрендә Әхмәди әсәре еш очрый. Халык тарафыннан яратып кабул ителгәнлектән, татар наширләре аны кечкенә китапчык рәвешендә, 1918 елга кадәр Казанда күп мәртәбә бастырганнар. XIX гасырда яшәгән татар шагыйрьләре Һибәтулла Каргалый һәм Габделҗәббар Кандалый әсәрләрендә (бигрәк тә, рифмалар төзелешендә) Әхмәди иҗатының тәэсире сизелүенә игътибар иткән идек.

Әхмәди китабыннан күчерелгән 31 юлдан башкасы (61 юл күләмендәге шигырь) 1963 елгы китапта М.Колыйга нисбәт ителгән шигырьгә туры килә. Дөреслектә, анда басылган тексттан 15 юлга кимрәк, ә Әхмәтҗанов белдергәнчә «зуррак» түгел. 1963 елгы басмада, М.Әхмәтҗанов әйткәнчә, «20 строфа, 80 юл» булмыйча, чынлыкта – 19 строфа һәм 76 юл. (Анда строфалар саннар белән белдерелгән, ләкин 8 саныннан соң, ялгыш 10 дип дәвам иткән һәм ахыргы строфага 20 саны куелган).

«Татар әдәбияты тарихы» хезмәтенең 2014 һәм 2022 еллардагы басмаларында Мәүла Колыйга багышланган бүлектә әлеге шигырь турында бер сүз дә юк. Ягъни, ул М.Колый әсәреме-түгелме дигән сорауга җавап күрмибез. Мәгәр шул ук китапларның берсендә М.Әхмәтҗанов әлеге әсәрне «яз бәйрәме Нәүруз каршылау хөрмәтенә чыгарыл-

[15] Һәзиһи гыйбрәтнамә вә шөкернамә мин әбйати Әхмәдийә. – Казан: Кукубин табыгханәсе, 1878. – Б. 7–8. Шул ук әсәрнең башындагы 10 шигъри юлын биреп, М.Әхмәтҗанов аны «татар телендәге поэтик әсәр» һәм «суфый татар шгыйре иҗаты, ләкин, анда исмен телгә алмагал» дип, бүтән кульязма тасвирында да язган иде (Әхмәтҗанов М. Татар археографиясе: соңгы елларда археографик экспедицияләр вакытында тупланган кульязмаларның тасвирламалары (1972–2012 еллар). Алтынчы кисәк. – Казан, 2016. – Б. 55). Әлеге өземтәдә автор имлясы һәм өслүбе сакланды.

ган шигырь» дип сыйфатлап, 1963 елгы китап текстына сылтама биргән һәм «бу шигырьдә авторлыкка нисбәтле Мәүла Колый исеме юк. Бәлки, аны Мәүла Колыйның остазы Һәмдәми язгандыр?» дип белдергән[16]. Шул рәвешле, шигырьнең авторлыгы турында яңа фараз әйтелгән.

Анда «Яз каршылау бәйрәменә бәйле булырга мөмкин» дип, өзек рәвешендә «Йабалак әйтер ыгым йук, Сүзләшергә телим йук...» дип башланган дүртьюллыкка ялгап дәвам иткән 9 шигъри юл бу әсәргә һич тә бәйле түгел. Чөнки «Буны йаздым йад улмак өчен» дигән, кульъязмаларга хас һәм «Йазыйм микән, йитәр микән...» рәвешле мөнәҗәт юллары монда урынсыз. Өстәвенә, «Айа хәннам вә йаманнан» дигән юллары гаять хаталы (дөресе – «Әйа, Ханнан вә йа, Мәннан» дип, Аллага мөрәҗәгать итү).

Һәмдәми мәсьәләсенә килгәндә, Мәүла Колый үз шигырьләрендә остазлары дип атаган кешеләр арасында мондый исемлесен күрсәтмәгән. «Һәмдәми» имзасы белән шигъри «Нәсыйхәтнамә» әсәрен язган, әүвәлгерәк чорда яшәгән башка бер шагыйрьне М.Колыйның остазы дип М.Әхмәтҗанов тәкъдим иткән фаразларның дәлилләре ышанырлык түгел. (Бу хакта шушы китапның ахырындагы мәкаләдә тәфсилләп язылды). Гомумән, галим тарафыннан шигырьдәге Кол Сөләйман исеме турында бер фикер дә белдерелмәгән хәлдә, авторлык мәсьәләсенә Һәмдәми дигән исемне дә катыштырып, мәсьәлә тагын да катлауландырылган. Өстәвенә, «Нәүруз»га бәйләгән шигырьне М.Әхмәтҗанов үзе үк 2011 елгы хезмәтендә Мәүла Колыйныкы дип язганлыгы турында монда берни дә әйтмәгән.

***

Түбәндә тәкъдим ителгән шигырьнең төп нигезе Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «4343т» шифры белән саклана торган, XVIII гасыр ахыры белән да-

[16] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Т. 2: XV–XVIII гасырлар..., 2014. – Б. 200.

таланган кулъязмадан[17] алынып, кайбер урыннары шул ук китапханәдәге «1818т» һәм «4341т» кулъязмалары буенча үзгәртелде.

Бу шигырьнең төп өлгесе Әхмәд Ясәвинең:

Халикымны эзләрмен
Төн-көн җиһан эчендә.
Түрт яшемдин юл инде
Көн-ү-мәкян эчендә[18],

– дип башланган хикмәтенә нигезләнгән. Аның беренче строфасындагы сүзләре үк Ясәви хикмәтенә аваздаш.

***

1 Мөэмин, Халиқ сыйфатын
Күрең җиһан эчендә!
Җәмиғ төзмеш ғаләмне
Көн-төн мәкян эчендә.

2 Бақың аның фиғленә,
Аның қөдрәт әленә:
Унике ай йылына
Дәүран-заман эчендә!

3 Йазны өч ай йаратди,
Көнне төндин озайтди,
Йир йөзени бизәтди
Төрлүк чәчәк эчендә.

4 Йазиларны үстергән,
Қошларны силк кыйлыр.
Бәндә ғафилләр ойыр
Төн-көн хыйал эчендә.

[17] Кулъязманы, Татарстанның Кукмара районындагы Уразай авылында яшәүче Васыйл Закировтан алып килеп, Гөлназ Гарипова 1999 елның 29 апрелендә тапшырган иде.
[18] Диване хикмәт гаусел-васыйлин хәзрәти солтанел-гарифин Хуҗа Әхмәд ..., 1896. – Б. 234–235.


باقنك انك نيلنه انك قدرت الينه
ادج ايكى اى ييلنه دوران زمان اچنده
دنيانى ايلكى كونده يارالتدى كوننى توندين آيرا ايتدى
يير يوزنى بير ايتدى تورلوك چچك اچنده آسمان
يارزى لارنى اوستوركان توش قورتلارنى اوستور
بلبل لارنى سايراتقان خوش كلستان اچنده
طوررغاى اوقسز هنك آيد طوطى آنكا بولور شاد
ولى لار اوتدين آزاد آخر زمان اچنده
الهم اوقسز تارلوغاچ اى عاقل كوزنك آچ
نه ايتورسن يالانفاج توش كون خيال اچنده
تارى ايتور يا الله آنكوك ايتور الا الله
لك لك ايتور تسل هو الله كلدى تيران اچنده
درج ايتور يادى يان اوردك ايتور يا رحمان

*Татарстан Республикасы Милли*
*китапханәсендә «4343т» шифры белән саклана торган кулъязма.*
*19а кәгазь*

5 Таң салқынын иснәтеб,
Былбылларны сайратыб,
Гөл қошларын игәртеб
Хуш гөлстан эчендә.

6 Турғай уқыр бер мең ад,
Тутый аңа булыр шад,
Вәлиләр утдин азад
Ахры заман эчендә.

7 «Әлхәм» уқыр қарлығач,
Әйа, ғафил, күзең ач!
Нә йатырсән йаланғач
Төн-көн хәйлә эчендә?!

8 Қарға әйтер: «Йа, Аллаһ!»
Әңут әйтер: «Иллә Аллаһ»,
Ләкләк әйтер: «Қул Һу Аллаһ» –
Килде Қөръән эчендә.

9 Дәрраҗ әйтер: «Йа, Дәйян!»
Үрдәк әйтер: «Йа, Рахман!»
Қазлар әйтер: «Йа, Сөбхан!»
Абе рәван эчендә.

10 Күгәрчен әйтер анда:
«Сөбханә Раббил-әғля!»
Һәм ахшамда һәм таңда
Килде Бәйан эчендә.

11 Тавык Тәңресен таныр,
Төн-көн тәсбихен уқыр,
Мөэминләр ғафил йатыр
Йази-йапан эчендә.

12 Байғыш төн-ү-көн йығлар,
Тәсбихға телен бағлар,
Қийамәт эшләрен таңлар –
Йөрәге қан эчендә.

13 Дуадақ әйтер: «Өнем йуқ,
Сүзләргә һәм телем йук.
Хақ зикерен әйтәрмән
Төн-көн күңлем эчендә».

14 Қарчыға әйтер: «Уш килдем,
Адәмгә бәндә булдым.
Хақ зикерен әйтер идем –
Азақым бағ эчендә».

15 Лачын әйтер: «Очармән,
Һаман диңез кичәрмән,
Тән тишеб, қан эчәрмән,
Хәлем фөрйад эчендә».

16 Күке әйтер: «Йа, Җәббар!
Сәндин үзгә кемем бар?
Балаларым асраған
Йази-йапан эчендә».

17 Һөдһөд әйтер: «Таҗым бар,
Тәңре берлә разым бар,
Сөләйманға инақмын
Барча қошлар эчендә».

18 Торна әйтер: «Очармән,
Сансыз қошлар башымән,
Һиндыстанда қышлармән
Мәрғызарлар эчендә».

19 Тавис – оҗмах қошыдыр,
Барча қошлар башыдыр.
Биш намазны қыйлғаннар –
  Мөждә җиһан эчендә.

20 Қол Сөләйман наз күрде,
Қошлардин нийаз күрде.
Кәндү разын аз күрде,
  Сүзе бәйан эчендә.

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Мөэмин, Халикъ[19] сыйфатын
Күр син җиһан эчендә!
Барын төзегән галәмне
  Көн-төн урын эчендә.

Кара аның фигыленә,
Аның кодрәт-көченә:
Унике ай елына
  Дәвер-заман эчендә!

Язны өч ай яратты,
Көнне төннән озайтты,
Җирнең йөзен бизәтте
  Төрле чәчәк эчендә.

Болыннарны үстерер,
Кошларны тәсбих кылыр,
Ваемсыз коллар йоклар
  Төн-көн хыял эчендә.

[19] *Халикъ* – дөньяны барлыкка китерүче (АллаһыТәгалә).

Таң салкынын иснәтеп,
Былбылларны сайратып,
Гөл кошларын ияртеп
    Хуш гөлстан эчендә.

Тургай укыр бер мең ат[20],
Тутый аңа булыр шат,
Изгеләр уттан азат
    Ахыр заман эчендә.

«Әлхәм»[21] укыр карлыгач,
Әй, ваемсыз, күзең ач!
Ник ятасың ялангач
    Төн-көн хәйлә эчендә?!

Карга әйтер: «Йә, Аллаһ!»
Тилгән әйтер: «Иллә Аллаһ»,
Ләкләк әйтер: «Коль Һу Аллаһ» –
    Килде Коръән эчендә.

Божыр әйтер: «Йә, Дәйан[22]!»
Үрдәк әйтер: «Йә, Рахман!»
Казлар әйтер: «Йә, Сөбхан!»
    Агымсуның эчендә.

Күгәрчен әйтер анда:
«Сөбханә Раббил-әгъля[23]!»
Һәм ахшамда һәм таңда
    Килде Коръән эчендә.

---

[20] *бер мең ат* – Аллаһы Тәгаләнең бер мең мактаулы исемнәре һәм сыйфатлары. «Алла – бер мең ат», «Мең бер атың» гыйбарәләре М.Колыйның хикмәтләрендә очрый (Дәүләтшин К. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый ..., 2010. – Б. 80, 102).
[21] *«Әлхәм»* – Коръәннең «Фатиха» сүрәсе.
[22] *Дәйан* – һәркемгә яхшы яки яман җәзасын бирүче (Аллаһы Тәгалә).
[23] *«Сөбханә Раббил-әгъля»* – Бөек Раббыма дан.

Тавык Тәңресен таныр,
Төн-көн тәсбихен укыр,
Мөэминнәр аңсыз ятар
    Болын-сахра эчендә.

Байгыш төн һәм көн елар,
Тәсбихка телен баглар,
Кыямәт эшенә таң калыр –
    Йөрәге кан эчендә.

Ялгыз каз әйтер: «Өнем юк,
Сөйләргә дә телем юк.
Хак зикерен әйтәм мин
    Төн-көн күңлем эчендә».

Карчыга әйтер: «Килдем,
Адәмгә мин кол булдым.
Хак зикерен әйтер идем –
    Аягым баг эчендә».

Лачын әйтер: «Очам мин,
Һаман диңгез кичәм мин,
Тән тишеб, кан эчәм мин,
    Хәлем зар-моң эчендә».

Күке әйтер: «Йә, Җәббар[24]!
Синнән башка кемем бар?
Балаларым асраган
    Болын-кырлар эчендә».

Һөдһөд әйтер: «Таҗым бар,
Тәңре белән серем бар,
Сөләйманга киңәшче мин
    Барча кошлар эчендә».

---
[24] *Җәббар* – үз хөкемен ирештерүче көчле (Аллаһы Тәгалә).

Торна әйтер: «Очамын,
Бик күп кошлар башы мин,
Һиндстанда кышлыйм мин
Болынлыклар эчендә».

Тавис – оҗмахның кошы,
Барча кошларның башы.
Биш намазны кылганнар –
Шатлык җиһан эчендә.

Кол Сөләйман наз күрде,
Кошлардин нияз[25] күрде.
Үзенең серен аз күрде,
Сүзе бәян эчендә.

## «Рухел-әмин»

Мәүла Колыйның моңарчы билгесез булган «Дәрвишләр сохбәтендә» шигыренең тексты бу китапның беренче бүлегендә бирелде. Ул Казан университеты китапханәсендә «8689т» шифры белән саклана торган кулъязмада теркәлгән. Кулъязма җыентыкның гомуми тасвирламасы да шунда – беренче бүлектә язылды. Шул ук җыентыкта теле һәм тасвирлау чаралары буенча М.Колый хикмәтләренә бик якын һәм охшаш тагын бер шигырь бар. Аның башында «Хикмәте хәким» дип язылган. Һәр строфасының ахырында кабатланып килгән рефрены буенча без аны шартлы рәвештә «Рухел-әмин» дип атадык.

Бу хикмәтнең тексты, ни сәбәптәндер, ике өлешкә бүленеп, башыннан дүрт ярым строфасы кулъязманың 2а кәгазендә язылган һәм шуннан соң «тәммәт тәмам булды» дип, гүяки, ахыры белдерелгән. Ә чынлыкта, аның дәвамы

[25] *нияз* – ялвару.

5а, 5б кәгазьләрдә теркәлгән һәм аның да 5а кәгазендәге дәвамы башында, яңа бер шигырь кебек, «Хикмәте хәким» дип язылган. 5б кәгазьдәге ахырында «тәммәт тәмам булды» диелгән. Бер үк хикмәтнең икегә аерылып язылуы, бәлки, бу кулъязманың протографыннан килгән булгандыр[26]. «Рухел-әмин» тексты тәгәлләнгән биттә Мәүла Колыйның «Дәрвишләр сохбәтендә» хикмәте язылган.

Ундүрт строфадан торган хикмәт, ихтимал, бу шигырьнең тулы тексты түгелдер. Аның кайбер строфалары һәм юллары күчерүче тарафыннан төшереп калдырылган булуы мөмкин. Болай уйларга нигез – 6 нчы строфаның икенче юлыннан соң кулъязмада теркәлгән «Һәрберсе һавада йөзәр» дигән бер юлның барлыгы. Аны, ихтимал, шигырьнең тагын бер строфасыннан булып, шуннан калган дип фаразларга мөмкин. Шулай ук, иң ахыргы – 14 нче строфасында хикмәт авторы кебек аталган «Сөләйман» исеме бу очракта «Кол Сөләйман», ягъни Сөләйман Бакыргани икәнлеге аңлашыла. Әмма Бакырганиның билгеле хикмәтләре арасында мондые юк. Шунлыктан, «Рухел-әмин» хикмәтенең тагын да бер (соңгы) строфасы булып, анда чын авторы белдерелгәндер дип фаразларга мөмкин. Мәсәлән, Мәүла Колыйның 23 нче, 52 нче хикмәтләре ахырларында автор исеме язылган строфаларның төшереп калдырылган очраклары турында икенче бүлектә язып үттек. Ә «Рухел-әмин» текстының бер үк кулъязма җыентыкта икегә бүленеп, һәр ике өлешенең «Хикмәте хәким» дип аталуларын һәм ахырларында «тәмам» сүзе кабатланганын искә алганда, андый хәл бик ихтимал кебек. Бу кулъязманың протограф җыентыгында буш урын булмаганга күрә генә текст ахыры теркәлмичә калуы мөмкин.

Кулъязма җыентыкта бу текст теркәлгән өлешенең палеографик үзенчәлекләре белән танышыйк. Шушы ук кулъ-

---

[26] Татар кулъязмаларында кайбер текстларның берничәгә бүленеп теркәлгән очракларының сәбәбе – җыентыкның төрле битләрендәге буш калган урыннарга өстәп язуга бәйле булган.

язмадагы «Дәрвишләр сохбәтендә» хикмәтенең тексты өч багана итеп язылганлыгын һәм андый күренешнең сәбәбен искәрткән идек. «Рухел-әмин» хикмәте дә нәкъ шулай – өч баганада язылган. Имлясы, нигездә, төзек диярлек. Ләкин бу текстта хаталар бар. Хикмәтнең текстында рефрен буларак кабатланып килгән «Рухел-әмин» атамасы ике урында бик бозылып – «Урхел-әмликъ» һәм «Уры зәмин» дип язылган. Текстның берничә урынында сүзләр, иҗекләр һәм хәрефләр язылмыйча, төшеп калган. Үзенчәлекләрдән «б» хәрефе урынына «п» язылган очраклар бар, мәсәлән, «бирйан» сүзенең беренче хәрефе «п» белән теркәлгән. Кайбер сүзләрдәге «уау» хәрефе өстендә өчәр нокта куелган.

«Рухел-әмин» – Коръәндә күп мәртәбә тасвирланган Җәбраил фәрештәнең бер исеме. Коръәннең «Әш-Шөгара» сүрәсендәге 193 нче аятьтә ул нәкъ шулай – «Рухел-әмин» дип аталган.

Әдәбият галиме Әлфинә Сибгатуллина хезмәтендә Җәбраил – Аллага якын дүрт фәрештәнең берсе һәм пәйгамбәрләргә вәхи китерүче дип әйтелгән, аның төрле исемнәре күр-сәтелгән. Шулай ук «Җәбраил, башка фәрештәләр кебек үк, Аллага түгел (Аллаһы Тәгалә аларның ярдәменә мохтаҗ түгел), ә адәм балаларына хезмәт итә, аларга иң авыр вакытларда ярдәмгә килә. Кешеләргә шайтан вәсвәсәсеннән котылырга [булышучы], икеләнгән-шөбһәләнгән мизгелләрдә үгет-нәсыйхәт бирүче дә Җәбраил... Суфичылыкта бу образ еш кулланыла. Аллаһ илчесе Җәбраил дәрвишкә Хакның чакыруын белдерә, моны кабул иткән дәрвиш яры (Хак) хозурына җәяү барырга теләр. Суфичылыкта Җәбраил «акыл» символы булып та килә»[27] дип язылган һәм болар мисаллар белән аңлатылган.

Беренче бүлектә Мәүла Колыйның «Дәрвишләр сохбәтендә» исемле хикмәте алдында язылган керештә «Һу» сүзе турында әйтелде һәм ул хикмәтнең «Бакырган» кита-

[27] Сибгатуллина Ә. Суфичылык серләре: төрки-татар шигъриятендә дини-суфичыл символлар, образлар, атамалар. – Казан: «Заман» нәшр., 1998. – Б. 152–154.

бындагы Кол Шәриф шигыренә якын булуы турында да искәртелде. «Рухел-әмин» текстындагы «Һу бәхрегә чумганлар» дигән гыйбарәдә, шулай ук бүтән тасвирларда Кол Шәрифнең шул ук шигыренә аваздашлык күренә.

*2а кәгазь* *Хикмәте хәким*

1 Һу, Һу берлә йөзгәнләргә[28],
Пөрнур улур Рухел-әмин.
Қөръән кәлям қыйлғанларға
Пөрнур улур Рухел-әмин.

2 Кичә-көндүз уқы Қөръән,
Ғашиқлар дик улуб бирйан,
Қыйла күр жаныңны[29] қорбан –
Пөрнур улур Рухел-әмин.

3 Пайдар улуб дөрунләр,
Қөръән кәлям қыйланлар,
Мәғнәсен хас беләнләр
Пөрнур улур Рухел-әмин.

4 Қөръән кәлям қыйла күрең,
Мәғнәсен хас белә күрүң,
Төзүк хилқа сари барың,
Пөрнур улур Рухел-әмин.

5 Қөръән кәлям қыйланлара,
Төндә пайдар уланлара[30],

---

[28] Кулъязмада бу сүзнең «гә» кушымчасы язылмаган, текстка безнең тарафтан өстәлде.
[29] Кулъязмада: йаның.
[30] Кулъязмада шушы сүздән соң «тәммәт тәмам булды» дип теркәлгән. Ләкин дәвамы 5а кәгазьдә икәнлеге аңлашыла. Күчерүче ялгышлыгы белән ул биттәге текст дәвамы алдында «Хикмәте хәким» дип язылган.

*5а кәгазь* Һу бәхрегә чумғанларға
Күршә килүр Рухел-әмин[31].

6 Андан ләззәт татғаннарға
Өч мәляик төшәр анға[32],
Ихласлар күрүлүр дидар –
Күршә килүр Рухел-әмин.

7 Ғадулар қыйлмас[33] ихтилят,
Әгәр булсаң сән хәқиқәт,
Мостафадин тот тариқат,
Күршә килүр Рухел-әмин.

8 Бу дөнйада ғадулардан,
Фәриқ улғул фөҗүрләрдән,
Хақ кичрүр зәвале иман,
Ләғнәт уқур Рухел-әмин[34].

9 Һу бәхрегә чуманлара,
Төнлә уйағ торанлара,
Хаққа[35] ғашиқ уланлара
Күршә килүр Рухел-әмин.

10 Бу дөнйада нәдүр чара,
Күб адәмнең[36] йөзе қара,

---

[31] «Рухел-әмин» гыйбарәсе кулъязмада бик хаталы итеп «Урхыл-әмлиқ» дип теркәлгән.

[32] «Анға» сүзе кулъязмада юк, текстка безнең тарафтан өстәлде. Кулъязмада бу юлдан соң «Һәрберсе һавада йөзәр» дигән тагын бер юл бар. Аны, ихтимал, шигырьнең тагын бер строфасы булып, шуннан калган дип фаразларга мөмкин.

[33] Бу сүздәге соңгы хәреф кулъязмада теркәлмәгән.

[34] «Рухыл-әмин» гыйбарәсе кулъязмада хаталы итеп «Уры зәмин» рәвешендәрәк теркәлгән.

[35] Бу сүз кулъязмада «Хақ» дип кенә теркәлгән.

[36] Бу сүз кулъязмада «азәм» дип язылган.



*«Рухел-әмин» хикмәте.*
*«8689т» шифрлы кулъязма.*
*2а кәгазь*

Хаққа[37] ихлас тотмағанға
    Ләғнәт уқур Рухел-әмин.

11 Уқы Қөръән, торма мәғрүр,
*5б кәгазь* Рәхмәтендән улмаң мәһҗүр,
Кәлүр сәңа үлүм-қөбур,
    Йулдаш улур Рухел-әмин.

12 Қөръән сәңа пөрнур улур,
Қәлбенә Һуны тултурур,
Мөнкир-Нәкир өйлүб торур,
    Җаваб вирүр Рухел-әмин.

13 Бу дөнйада ула фани
Чөн мәкянедүр зольмани[38].
Уқы кинәнеч илә Қөръән,
    Саваб бөтәр Рухел-әмин.

14 Аңла моны адәми җан,
«Һу» дәйү, күз ачыб[39] уйан,
Аңла моны, әй, Сөләйман –
    Күршә кәлүр Рухел-әмин.

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Аллаһ белән йөзгәннәрне,
Нурга күмәр Рухел-әмин.
Коръәнне укыганнарны
    Нурга күмәр Рухел-әмин.

---

[37] Бу сүз кулъязмада «Хақ» дип кенә теркәлгән.
[38] Кулъязмада бу сүздәге «з» хәрефенең ноктасы куелмаган.
[39] Бу сүз кулъязмада «ачаб» дип теркәлгән.



حق یاندی لیلی مجنون بر بری مجلس قیلوب کاسه لارون جمله و طاب
باطن شرابی اچوب حق یاندی لیلی مجنون چلوب تمام ریضاتی ص
قریق کون دور فرحاتی سکز کون دور حلاوتی خال قراشدی لیلی مجنون
اوچان قوشلار اوتلادی طوقوز وسینه کیلیه آلمادی هو هو ذکری الیه احلادی
حق ایاندی لیلی مجنون ملائکلار حضور طابوب اوطور دیلار خلق قوروب
طاقت سزدان صیقلاب قیلوب حق یاندی لیلی مجنون هو هو ذکرو سنی قیلوب روا
هالدوننه بولماک ریا ایکولاسی بر خلقه دای حق یاندی لیلی مجنون
ایا آدم هو هو دیب یان قوللوق ایرور اوشبوران ایکولاسی بر خلق دای
حقا یاندی لیلی مجنون الطیف سرور اولوب ایکولاسی مشغول اولوب
بر قبرده مدفون اولوب حقا یاندی لیلی مجنون ایا صفای ایز او یان
حق قیلغول جانوننی قربان انکلا موی شریف لقا ان حق یاندی لیلی مجنون

حکمت حکیم

هو بحر بیکا جومغانلاره کورشکلور اوروح الاعلیق الذآن لذت طاتغنلار که
اوج ملائکلر توشار هر برسی هو ادیون ار اهل اصلار اکور ولور دیدار
کورشکلور روح الامین عدولار قیلما اصطیلاط اگر بولسانک انسان حقیقت
مصطفی دین طوت طریقت کورشکلور روح الامین بو دنیاده احلاولار دان
فریق اولغول فجور لاردان حق کیبی رهبر اوغل ایان لعنت اوقور اوری زمین
هو بحر کا جومانلا را توتار او یاع طورنلارا حق یاشیق اولانلارا
کوروشکلور روح الامین بو دنیاده اندورها را کوب آدم سنک یوزی قرا
حق اخلاص تعمانف لعنت اوقور روح الامین اوقی قرآن طور مامور

*5а кәгазь*

Төн һәм көндез укы Коръән,
Гашыйклардай куырылып
Кыла күр җаныңны корбан –
Нурга күмәр Рухел-әмин.

Һәрчак уяу булырлар
Коръәнне укыганнар,
Мәгънәсен хас белгәннәр –
Нурга күмәр Рухел-әмин.

Коръәнне син укый күрче,
Мәгънәсен хас белә күрче,
Төзек божра якка барчы –
Нурга күмәр Рухел-әмин.

Коръәнне укыганнарга,
Төндә даим булганнарга,
Хак диңгезенә чумганнарга
Күрешә килер Рухел-әмин.

Аннан ләззәт алганнарга
Өч фәрештә төшәр аңа,
Ихласлар күрерләр дидар –
Күрешә килүр Рухел-әмин.

Дошманнар кылмаслар дуслык,
Әгәр тапсаң син хакыйкать,
Мөхәммәттән тот тугры юл –
Күрешә килүр Рухел-әмин.

Бу дөньяда дошманнардан,
Ерак бул син бозыклардан,
Хак кичерер түбәнлектән,
Ләгънәт укыр Рухел-әмин.

Хак диңгезенә чумганнарга,
Төнлә уяу торганнарга,
Хакка гашыйк булганнарга
    Күрешә килүр Рухел-әмин.

Бу дөньяда нидер чара,
Күп адәмнең йөзе кара,
Хакка ихлас тотмаганга
    Ләгънәт укыр Рухел-әмин.

Укы Коръән, торма мәгърур,
Рәхмәтеннән булмас ерак,
Килер сиңа үлем-кабер,
    Юлдаш булыр Рухел-әмин.

Коръән сине нурга күмәр,
Күңлеңә Хакны тутырыр,
Мөнкир-Нәкир иелеп торыр,
    Җавап бирер Рухел-әмин.

Бу дөньяда була фани
Чөнки урыны караңгы.
Укы кинәнеп син Коръән,
    Савап өстәр Рухел-әмин.

Аңла моны адәми җан,
«Хак» диеп, күз ачып уян,
Аңла моны, әй, Сөләйман –
    Күрешә килер Рухел-әмин.

## «Шәфәгать шәмгыны яндыр... »

Бу шигырь Казан университеты китапханәсендә «8685т» шифры белән саклана торган кулъязмадан алынды. Аның гомуми тасвиры II бүлектә тексты бирелгән 22 нче хикмәт алдында язылды. «Шәфәгать...» шигыре кулъязмада М.Колыйның 22 нче хикмәте алдындагы биттә теркәлгән. Текстның кулъязмада имля бозыклыгы һәм хаталары юк.

Шигырьдә телгә алынган күбәләк һәм шәм – суфичылык әдәбиятында киң кулланылган символик тасвир чарасы. «Пәрванә»не галимнәр ут янында очып йөри торган күбәләк дип язалар. Суфичылык серләренә багышланган хезмәттә аның турында болай диелгән: «Пәрванә, күбәләк – төнге күбәләк дип тә йөртелә торган бөҗәк, үз-үзен яккан-чыга кадәр, ут яктысында бөтерелеп очар. Күзләре кечкенә булганга, көндезләрен ул караңгыда яши, караңгы төшкәч яктыга таба оча, ут яктысында күзләре камашканга күрә ... шәм кебек нәрсәләрдән аерыла алмый, канатларын, соңрак бөтен гәүдәсен утта яндыра. Шәрык әдәбиятында пәрванә – шәмнең, ягъни яктылыкның гашыйгы. Үз-үзен ягуның сәбәбе – гыйшкыннан: утны яратуыннан үзен-үзе корбан итә. Дини-суфичыл әдәбиятта шәм-күбәләк парлы символы еш очрый. Шәм – мәгъшукны, сөйгән ярны, ниһаять, Алланы, күбәләк – гашыйкны, суфины, дәрвишне аңлата. Шәм янында йөргән күбәләк ничек янып бетеп, юкка чыкса, суфи да Алла гыйшкында янып-көеп бетеп, үзлеген югалтып, Аның белән кушылырга хыяллана. ... Суфичылык әдәбиятында шәм-күбәләк парлы символы гаять киң таралган. Бу очракта күбәләк – суфины, дәрвишне, Алла белән кавышырга теләүче гашыйкны аңлатса, шәм, мәңге сүнмәс ут – ул Аллаһ»[40].

[40] Сибгатуллина Ә. Суфичылык серләре ..., 1998. – Б. 245, 246, 348.

*3б кәгазь* Шәфәғәт шәмғене йандур
Җәмалең нурына қаршу,
Ки пәрванә[41] улам, аңа
Кичәм тақ мосалләдән.

Күңел бер синә эстәр кем,
Фирақ удына йанмышдур,
Ки шәрхә-шәрхә улмышдур
Йаныб дәрде диларәдән.

Һәмишә ғишықның[42] уды
Җан-җәһан йақа килмешдүр.
Йана пәрванәләр шәмғға –
Әверүрләр җана утдан[43].

*Хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе:*

Шәфәгатьнең шәмен яндыр
Йөзеңнең нурына каршы,
Ки күбәләк булам, аңа
Кичәм ялгыз намазлыктан.

Күңел бер күкрәк теләр ки,
Аерылуның утына янган,
Хәтта парә-парә булган
Янып гүзәл газабыннан.

[41] Кәгазь читендә: «пәрванә – күбәләк мәгънәсендә» дип искәртелгән.
[42] Кульязмада: ғишық.
[43] Кульязмада «утдан» сүзе урынында «йарәй» дип теркәлгән. Ләкин ул күчерүчеләр тарафыннан өстәлгән. Аның урынында булырга тиешле сүз шигырьнең алдагы строфа ахырларындагыча «дән» кушымчасына бетәргә тиешлеге аңлашылып тора.
*«Йарәй»* – борынгы татар җырларына һәм көйләп укылган мөнәҗәтләргә хас эндәш сүз (аның турында фикер белдерелде: Шигъри ядкярләр ..., 2021. – Б. 87–89).



*«8685т» шифрлы кулъязма.*
*3б кәгазь*

Һаман гыйшыклыкның уты
Җан-җиһан ягып килгәндер.
Яна күбәләкләр шәмгә –
　　Әйләнәләр җанга уттан.

# ҺӘМДӘМИ МӘСЬӘЛӘСЕ

Әдәбиятыбыз тарихында «Нәсыйхәтнамә» исемле әсәр һәм аны иҗат иткән Һәмдәми тәхәллүсле әдип булганлыгы мәгълүм. Урта гасырлардагы күпчелек авторларныкы кебек үк, аның төгәл исеме һәм тормыш юлы, кызганыч ки, билгесез.

Һәмдәми әсәре XII–XIII гасырларда яшәп иҗат иткән фарсы шагыйре Фәридеддин Гаттарның «Пәнднамә» («Нәсыйхәтнамә») дип аталган шигъри китабын иреклe тәрҗемә итү нигезендә, авторның үз өстәмәләре белән – нәзыйрә буларак әдәби мәйданга чыгарылган. Ләкин кайсы елда язылганлыгы күрсәтелмәгән, авторы да текст эчендә «Һәмдәми» дип кенә белдерелгән.

Бу әсәр татарлар арасында кульязма рәвешендә шактый таралган, XIX гасырда Казанда басылып та чыккан. Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә һәм Казан федераль университетының Фәнни китапханәсендә егерме кульязма күчермәсе барлыгын ачыкладык. (Алар татарлар яши торган төрле төбәкләрдән тупланганнар). Казан һәм Уфа, С.-Петербург шәһәрләрендәге башка оешмаларда саклана торганнарын кушып исәпләгәндә, хәзерге вакытка Һәмдәми «Нәсыйхәтнамә»сенең утызга якын күчермәсе бар.

Соңгырак чор галимнәребез тарафыннан Һәмдәмине шагыйрь Мәүла Колыйның остазы Мелла Мамай белән тәңгәлләштерү, хәтта Һәмдәми белән Мәүла Колый – бүтән бер кешенең ике тәхәллүсе дип аңлатырга омтылулар пәйда булды. Баштарак фараз рәвешендәрәк белдерелгән версияләр, акрынлап, гүяки, төгәл хакыйкать дәрәҗәсенә ирешә.

Мондый фараз-ачышлар нинди дәлилләргә нигезләнгән, алар ышанычлымы, Һәмдәми – Мәүла Колыйның остазы-

мы яисә чынлап та үземе? Чамадан тыш катлауландырылган мәсьәлә йомгагының кайбер җепләрен сүтәргә һәм хәлне аңларга омтылыйк.

## Бу исем фәндә кайчаннан һәм ничек мәгълүм

Татар әдәбияты тарихы белән кызыксынган җәмәгатьчелек Һәмдәми дигән шагыйрь исемен Нил Юзиев белән Альберт Фәтхинең 1963 елгы мәкаләсе аша белгән[1]. Һәмдәми әсәре турындагы беренче фикерне алар әйткән. «Нәсыйхәтнамә»нең 1781 елгы күчермәсеннән әсәрнең аерым юлларын биреп, мәкалә авторлары болай дигәннәр: «Урта гасырлардагы татар әдәби телен өйрәнүдә Һәмдәми әсәре кыйммәтле чыганак булып тора. Һәмдәминең сүз һәм шигырь белән оста эш итүенә, шигъри культурасына карап, аны борынгы татар әдәбиятының күренекле шагыйре булган дип бәяләргә мөмкин. Тәрҗемәдән тыш, аның үз әсәрләре дә булырга тиеш. Аларны эзләү, табу – киләчәк эше. Ә хәзергә Һәмдәми бу әсәре белән дә татар әдәбияты тарихында лаеклы урынны алырга хаклы»[2].

Һәмдәми һәм аның «Нәсыйхәтнамә» әсәре турында 1990 нчы еллар башыннан Фәрит Яхин, 2000 нче елларда Марсель Әхмәтҗанов аерым мәкаләләр яздылар. Ике галимнең фикерләре ике төрле булды. Аларның каршылыклы карашлары дәвам иткән арада Һәмдәмине Себер шагыйре дип атаган кандидатлык диссертациясе язылып, Г.Талипова һәм Ф.Сәйфуллина әдәбиятчы Ф.Яхинның фаразын үстерүне дәвам иттеләр[3].

---

[1] Юзиев Н., Фәтхи А. Уралда сакланган хәзинәләр // Совет әдәбияты. – 1963. – Б. 117–124.

[2] Шунда ук. – Б. 119.

[3] Талипова Г. Образ праведного человека в произведении XVIII века поэта-суфия Амдами «Насыйхатнаме» // Югары һәм урта һөнәри уку йортларында татар әдәбиятын укытуның мөһим мәсьәләләре. – Казан: ун-т нәшр., 2006. – Б. 54–56; Талипова Г. Тобольский поэт Амдами и его книга наставлений «Насихатнамэ»: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Тобольск. 2007. – 23 с.; Сайфуллина Ф., Талипова Г. «Насихатнамэ» Амдами – литературный памятник средневековья (текстологический анализ). – Тобольск: ТГСПА им. Д.И.Менделеева, 2009. – 180 с.;

Татар әдәбияты сигезтомлыгының 2014 елда дөнья күргән икенче томында М.Әхмәтҗановның «Һәмдәми (Мамай мелла)» дигән мәкаләсе дөнья күрде[4]. Анда Һәмдәми – ул Мәүла Колыйның остазы булган Мелла Мамай дигән фикер үткәрелгән. Әдәбият тарихының яңартылган икенче басмасына (2022 ел) М.Әхмәтҗановның андый мәкаләсе бөтенләй кертелмәгән, фәкать бер җөмлә белән генә искә алынган[5].

Казанда 2018 елда Һәмдәми әсәре Ф.Яхин тарафыннан аерым китап итеп чыгарылды[6]. Аннотациясендә мондый юллар бар: «Китапның кереш сүзендә Һәмдәминең Тубыл (Тобольск) шәһәрендә яшәгән XVII–XVIII гасырлар шагыйре икәнлеге сөйләнелә, «Нәсыйхәтнамә» поэмасына кыскача анализ ясала, тарихи урыны аңлатыла...». Бу басмада 1872 елда Казанда нәшер ителгән «Нәсыйхәтнамә» әсәренең хәзерге графикадагы тексты һәм факсимилесы урын алган.

Мәүла Колыйга багышлап 2022 елда уздырылган конференция материалларында Һәмдәми һәм Мәүла Колый аерым шагыйрьләр булмыйча, әлеге тәхәллүсләр бер үк шагыйрь – Хуҗам Шөкер Гаваз-байга нисбәтле дип, Ф.Яхин белдергән фикер дә бар[7].

«Нәсыйхәтнамә» әсәренә һәм аның авторы Һәмдәмигә багышланган төп хезмәтләр менә шулардан гыйбарәт. Алар-

---

Сайфуллина Ф. Духовно-нравственные проблемы в татарской средневековой литературе. – Тобольск: ТГСПА им. Д.И.Менделеева, 2009. – 128 с.

[4] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Т. 2: XV–XVIII гасырлар / төз. Р.Рахмани. – Казан: Татар. китап нәшр., 2014. – Б. 223–241.

[5] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 2 т.: XV–XVIII гасырлар / төз. һәм фәнни мөх. Г.Дәүләтшин. Яңарт. 2 нче басма. – Казан: Татар. китап нәшр., 2022. – Б. 22.

[6] Һәмдәми (Хуҗам Шөкер бине Гаваз-бай). Нәсыйхәтнамә / текстны әзерләүче, кереш сүз авторы – профессор Ф.З.Яхин. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 160 б.

[7] Яхин Ф. Мәүла Колый – XVII гасыр шагыйре // Человек и природа в бассейне реки Мёша и Пестречинском Заказанье в историческом развитии. Уроженец Пестречинской земли Мауля Колый: жизнь, деятельность, наследие и его вклад в духовно-культурную жизнь татарского народа («Вторые Пестречинские научно-краеведческие чтения»). Материалы Всероссийской научно-практической, историко-краеведческой конференции. – Серия «Восток–Запад: диалог культур и цивилизаций Евразии». Вып. 22. Под ред. А.А.Бурханова. – Казань: Отечество, 2022. – Б. 309.

ның аермасы: бер галим Һәмдәмине М.Колыйның остазы Мелла Мамай дип тәгаенләсә, икенче галим Һәмдәми тәхәллүсе белән Тубыл татары Хуҗам Шөкер бине Гаваз-бай иҗат иткән дип аңлатуда. «Нәсыйхәтнамә» әсәре, М.Әхмәтҗанов фикеренчә, XVII гасырның беренче яртысында (1621–1630 еллар арасында) иҗат ителгән, ә Ф.Яхин карашынча, 1703 елда язып төгәлләнгән. Боларны дәлилләргә тырышсалар да, кызганычка каршы, нигезле фәнни расламалары юк. Ике фикер-караш та фаразларга гына корылган.

## Яхин версиясе

Фәрит Яхинның «Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә» әсәре» дип аталган махсус мәкаләсе 1992 елда дөнья күргән иде[8]. Мәкалә авторы Әлмәт шәһәре мәчетеннән 1990 елда үзе тапкан 1787 елгы кульязма уңаеннан фикерләрен бәян иткән. Текст ахырындагы «тарих мең дә ут» дип, сүзләр белән язылган датаның «ут» сүзен «ун» дип танып, аны һиҗри 1010 елга, милади 1628 елга туры килүен әйтеп, үзенчә, әсәрнең иҗат ителгән елын тәгаенләгән[9]. «Тарих мең дә...» сүзләре янында ук күчерелгән вакыты – «сәнә 1787 елда ирде» дип язылган. Кульязманың бер битендә язылган исемне авторы дип тә гөман кылган[10]. Мәкаләнең ахырында болай диелгән: «Хәзергә нәтиҗә шул: Һәмдәми – XVII гасыр башында яшәгән татар шагыйре, аның тормыш юлы, шәхесе хәзергә билгесез булып кала бирә. Һәмдәми тәхәллүсен Мәүлүдгол исемле шагыйрьнеке дип фараз итәргә мөмкин. «Нәсыйхәтнамә» әсәренең 1628 елда тәмамлануын һәм аның әдәбиятыбыз тарихында дәрәҗәле үз урыны булуын ачык итеп әйтә алабыз. Аны яхшылап өйрәнергә кирәк»[11].

---

[8] Яхин Ф. Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә» әсәре // Әдәбият чыганаклары һәм текстология: җыентык. – Казан: ТФА Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият, тарих ин-ты, 1992. – Б. 13–24.

[9] Шунда ук. – Б. 21.

[10] Кульязмадагы дата һәм Мәүлүдгол исеме язылган битләренең факсимилелары мәкалә белән бергә 18–19 битләрдә бирелгән.

[11] Яхин Ф. Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә» әсәре ..., 1992. – Б. 22. Мәкалә авторының игътибарсызлыгы аркасында Н.Юзиев һәм А.Фәтхи мәкаләсе басылган журнал исеме бер үк биттә (21 бит) ике төрле: «Совет әдәбияты» һәм «Совет мәктәбе» дип күрсәтелгән.

Әдәбият галиме Фәрит Яхинның урта гасырлар татар әдәбиятына багышланган, 2000 елда дөнья күргән китабының[12] бишенче бүлегендәге икенче параграф Һәмдәмигә багышланган. Шактый күләмле (224–239 битләр) әлеге параграф «Һәмдәми һәм аның «Нәсыйхәтнамә» поэмасында дини мифологик күзаллауларның үстерелеше» дип атала. Галим Һәмдәминең шәхесен ачыкларга омтыла һәм ул Ризаэтдин Фәхретдиннең «Асар» хезмәтендә телгә алынган Хуҗам Шөкер бине Гаваз-бай булган дигән фаразын үткәрә. Ә үзе үк 1992 мәкаләсендә белдергәнчә, әсәрнең датасын (1628 ел) һәм гөман ителгән авторын искә алмый. Бары тик 1990 елда «Нәсыйхәтнамә»нең кульъязмасы табылуы һәм аның күчерелгән вакыты турында язу белән чикләнә.

«Асар» китабында, чынлыкта, 1703 елдагы үгет-нәсыйхәтле мөрәҗәгать рәвешендәге язма текстны (ул, бәлки, хат булгандыр) Р.Фәхретдиннең нәсыйхәтнамә дип атавына карап, аны Ф.Яхин «китап булган» дип ышандырырга тели. «Асар»дагы текстта әйтелгән даталарны күчереп, «Шулай булгач, Хуҗа Шөкер бине Гаваз-бай үзенең «Нәсыйхәтнамә»сен 1703 елның 26 гыйнварында Табул шәһәрендә тәмамлаган» (226 бит) дип, Ф.Яхин үзенчә нәтиҗә ясаган.

Бу параграф ахырына таба (239 бит) автор: «Һәмдәминең 1703 елда Табулда «Нәсыйхәтнамә» язган Шөкер бине Гавазбай булуы әһәмияткә лаек», «Р.Фәхретдинов телгә алган «Нәсыйхәтнамә» әсәре нәкъ менә шушы Һәмдәминеке булырга кирәк» дип, күбрәк кабатлап ышандыру ниятеннәнме, кат-кат язган. Иң соңгы абзацта ул: «Нәсыйхәтнамә» поэмасының авторы Һәмдәми булуында һичбер шик юклыгы аңлашылып тора. Минемчә, шушы Һәмдәми имзасы ар-

[12] Яхин Ф. Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. – Казан: ТДГИ нәшр., 2000. – 268 б. Бу китап 2003 елда кабатлап басылды (Яхин Ф. Урта гасырлар татар әдәбияты: татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. – Казан: «Раннур» нәшр., 2003). Һәмдәмигә багышланган параграф 350–376 нчы битләрдә, үзгәрешсез диярлек, урын алган.

тында Табул татары, әлеге дә баягы Хуҗа Шөкер бине Гавазбай булырга тиеш. «Нәсыйхәтнамә» поэмасының да, шулай итеп, 1703 елның 26 нчы январендә, аның каләме белән, Табул шәһәрендә тәмамлануын тәкрарларга тиешбез» дип, мәсьәләне хәл итеп куйган. Әлмәттә табылган кульязманың бөтен һәм шактый төзек булуына нигезләнеп, «шагыйрьнең үз нөсхәсеннән күчерелгән дигән фикер калдыра» (226 бит) дип тә бәяләгән Ф.Яхин.

Авторның бу китабындагы ялгыш-хаталарының һәммәсенә тукталу ихтыяҗы юк. Шулай да, кайберләрен искәртәбез. Мәсәлән, даталар турында. Әлмәт кульязмасындагы «1787» елның катлаулырак итеп язылган саннарына күрә Ф.Яхин аны «1606 ел» (226, 239 битләр) дип тә фаразлаган. Тик, бу очракта, андый фараз асылда дөрес түгел, автор рус хронологиясендә император Пётр Беренче тарафыннан 1700 елдан башлап кертелгән яңача исәпләүне игътибарга алмаган. Билгеле булганча, аңа хәтле еллар дөнья яратылышыннан алып саналган һәм шундый иске календарь буенча 7208 нче (яңача 1699) елда рус хронологиясенә Пётр патша үзгәртү карарын керткән[13]. Шул сәбәпле, Яхин белдергәнчә «1606 ел» дигән датаның язылуы һич мөмкин булмаган.

Даталар төрлелегенең тагын берсе – китапның 225 нче битендәге «1703 ел» дип язылган бер үк тарих 226 нчы биттә «1702 ел» дип бирелгән. Әсәр турында сүз алып барганда «Әлмәттә табылган кульязмасы, Урал кульязмасыннан аермалы буларак, 1787 елда ук төзелгән булса кирәк» (226 бит) дигән җөмләнең дә хилаф икәнлеген әйтеп үтмичә булмый. Соңгы җөмләдәге «1787 елда ук» гыйбарәсе Урал кульязмасыннан элеккерәк вакытка карый дип аңлашыла. Ә, хакыйкатьтә, Н.Юзиев белән А.Фәтхи мәкаләсендә 1781 елгы кульязма турында сүз барган.

Китаптагы иң тупас хаталарның берсе – «әл-Мәликел-

---

[13] «Гәүһәр Болгарга килдем...»: тарихи бәетләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2013. – Б. 28; Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кульязмаларының палеографик үзенчәлекләре. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2024. – Б. 80–81.

Ваһһап ул – кульъязмалар төзүче шәхес. XVIII йөздә яшәгән...» (227 бит) дигәнен дә искә алыйк. Шундый ук мәгънәдәге сүзләр әлеге китапның башка бүлекләрендә дә бар (105 һәм 185 нче битләр). «Әл-Мәлик» (Бар нәрсәләрнең хуҗасы) һәм «Әл-Ваһһаб» (Юмарт) – Аллаһы Тәгаләнең күркәм исемнәре. Татар һәм, гомумән, мөселман китапларының ахырларында – бетем өлешләрендә бу исемнәр еш телгә алынган һәм алар «бар нәрсәләрнең хуҗасы һәм юмарт Аллаһның ярдәме белән бу китап тәмам булды» дигән җөмләдә кабатланган. Иске кульъязмалар белән эш итүче галимнәрнең (шул исәптән, Ф.Яхинның да) Аллаһы Тәгалә исемнәрен кеше исемнәре дип ялгышулары турында үзебез 2010 елдан бирле язып киләбез[14].

Сүз бара торган хезмәттә (229 биттә) Гаттарның «Пәнднамә»сеннән тәрҗемә ителгән башка бер текст дип Камал улы Әхмәтнең XVIII гасыр ахыры кульъязмасы телгә алынган. Чынбарлыкта, ул – татарлар арасында кульъязмалары күп очрый торган һәм Казан матбагаларында XIX гасырда басылган «Шуридәи халь» әсәре[15]. Аның тәрҗемәче-авторы Камал угылы Әхмәд икәнлеге 1895 елгы басмасының ахырында – 72 нче битендә күрсәтелгән. Бу әсәр – Ф.Гаттарның фарсы телендәге «Әсрарнамә» әсәреннән төрки-татарчага тәрҗемә. Телендә борынгы сүзләр, лексик һәм палеографик архаизмнар шактый. Китап барлыгы 39 кечкенә кыйссадан тора, алар саннар белән билгеләнгән. 11 нче һәм 30 нчы кыйссаларда «Мәхмүд хан» һәм «солтан Мәхмүд» исемнәре бар[16]. Менә бу хөкемдар исеме Гаттар текстыннан ук килгәнме, әллә аны тәрҗемәче өстәгәнме? Тарихтан билгеле булуынча, урта гасырлардагы мөселман ил-дәүләтләрендә Мәхмүд исемле хан-солтаннар (шул исәптән Казан ханлыгының бер ханы) идарә-хакимлек иткәннәр.

---

[14] [Мөхәммәтәмин]. Кыйссаи Мансур. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2010. – Б. 20–21; Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кульъязмаларының палеографик үзенчәлекләре ..., 2024. – Б. 67–70.

[15] Шуридәи халь китабы. – Казан: Чирков хатынының вәрәсәләренең табыгханәсе, 1895. – 72 б.

[16] Шунда ук. – Б. 24, 60.

Ул китапның «Шуридәи халь» исеме белән басылганлыгын һәм «Әсрарнамә»дән тәрҗемә икәнлеген С.Гыйлаҗетдинов язган иде инде[17]. «Татар әдәбияты тарихы» китабының 1985 елгы 2 нче томында (41 биттә) әйтелгән ялгыш фикерне Ф.Яхин үз хезмәтләрендә һаман дәвам итә. Мәсәлән, 2018 елда чыккан Һәмдәми китабында да (12 биттә) шул ук хата кабатланган.

Һәмдәми белән Мәүла Колыйга бәйле элекке фаразларын камилләштереп, Ф.Яхин соңгырак елларда тагын да яңа нәтиҗәләргә ирешә. 2022 елның 1 апрелендә М.Колыйга багышлап үткәрелгән фәнни-гамәли, тарихи конференциянең материаллары җыентыгында Ф.Яхинның шактый үзенчәлекле чыгышының тексты бар[18]. Ул М.Колыйның 5 нче хикмәтендә үз остазы турында язганга карата «Галимнәр «Сембер-Казан» сүзләренең кулъязмаларда төрлечә язылуын һәм аның «Себер-Казан» варианты да барлыгын искәртәләр» (304 бит) дигән. Әмма кайсы галимнәр һәм кайда искәртүләрен белдермәгән, чыганакка сылтамасы юк. Һәрхәлдә, Мәүла Колый хикмәтләренең Ф.Туйкә күчермәсендә «Сенбер, Казан» дип язылган, ә Петербургтагы кулъязмада ачык итеп «шәһри Казан» диелгән. Шуннан башка вариантлар юк. «Сенбер» дигәне, аңлашылуынча, «шәһри» сүзеннән элекке күчерүчеләр тарафыннан бозылган. Ләкин Ф.Яхин мәкаләсендә Сембер урынына Себер икәнлеге һәм, ни гаҗәп, Казан атамасы да Себергә бәйле, ягъни Себердәге Казан турында сүз барган дип аңлатыла.

Мәүла Колыйның шул ук 5 нче хикмәтендә остазы Мелла Мамайның «Балгым хуҗа» (С.-Петербург кулъязмасында – «Балгылым хуҗа») каберенә астанә төзеткәнлеге әйтелгән. Ф.Яхин бу мәсьәләне шулай ук үз фаразына туры китереп җайлый: «Сөйләм телендә «Балголым Хуҗа» «Балгым Хуҗа», «Багым ишан» рәвешендә кыскартып йөртелә тор-

[17] Гилязутдинов С. Персидско-татарские литературные связи (Х – начало ХХ в.). – Казань: ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова АН РТ, 2011. – С. 87–88.
[18] Яхин Ф. Мәула Колый – XVII гасыр шагыйре ..., 2022. – С. 303–309.

гач, бүгенге көнгә «Баиш» хәленә килгән. Тубыл шәһәреннән Иртеш буйлап көньякка таба күтәрелгәндә изгеләр күмелгән Баиш зираты бар. Баиш авылыннан төньякта. Ул Вагай районына карый. Мулла Мамай менә шул зиратта Балголым Хуҗа кабере барлыгын ачыклап, анда астана төзетеп, шунда мөҗавирлек кылган» (305 бит)». (Шаккаткыч тарихлар ачылуына, «менә ничек икән бит!» дип гаҗәпләнеп, сокланмыйча хәл юк). Алга таба галим болай ди: «Мәүла Колыйның Казанда укыганлыгын искәртеп үтмичә мөмкин түгел. Әмма XVII гасырда Казан шәһәрендә мәдрәсә һәм мәчет булу факты тарихка мәгълүм түгел. Димәк, сүз башка бер Казан, яки Казан исемен йөрткән кала яисә авыл хакында бара. Ул Баиш авылы булырга да бик мөмкин!» (305 бит). Шуннан соң Ф.Яхин Мәүла Колыйның остазы турында сүз алып баргач, «Хәер, Мәүла Колыйның асыл исеме, кайдан һәм кем булуы безгә күптән ачык мәгълүм» (306 бит) дип, кызыксынучылар күңелен, гүя, кытыклап куя. М.Колый хикмәтендә телгә алынган «Болгар» атамасын да «Тубыл булуы ихтимал»лыгын белдерә һәм «бу мәсьәлә әлегә ачык кала» (306 бит) дип искәртә. Тубыл елгасы һәм шәһәре турында кыскача әйткәннән соң галим-филолог, сүз остасы буларак, «Шулай итеп...» ди һәм тирән мәгънә салынган күпнокталар куеп, башлаган сүзен хәзергә дәвам итмичә, детектив жанрында иҗат итүче мәшһүр каләм әһелләредәй, янә бер ымсындырып куя.

Фәрит Яхин Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә» әсәре кульязмасын 1990 елда Әлмәттә табуы турында язып, «поэмасын шагыйрь 1703 елның 26 гыйнварында тәмамлаган. Ә «Әлмәт кульязмасы», күчерүченең белдереп калдыруына күрә, XVII йөз ахырында язылган 1787 елгы нөсхәдән күчермә булып чыкты» (308 бит), – ди. Гәрчә әсәр текстында 1703 ел турында бернинди дә сүз юк. Галимнең монда китерелгән икенче җөмләсе бик катлаулы икәнлеген дә искәртик.

Ахырга таба ул «Тагын да дәвам иткән фәнни эзләнүләребез «һәм- дәми» имзасы Тубыл шәһәрендә яшәп

иҗат иткән Хуҗа Шөкер бине Гаваз-бай исемле кешенеке булуын ачыкларга ярдәм итте»[19] дип дәвам иткән. Чыгыш авторының татар кешесе өчен җиңел генә аңламаслык итеп төзелгән тагын бер җөмләсе мондый: «Менә шуңа да «Әлмәт кулъязмасы»нда әсәрнең авторы әмир булуы хакында хәбәрне ни өчен бирүен төшенеп алу зиһенне хәйран итми калдырмады» (309 бит). Аннары чыгышта Тубылга, Тубыл шәһәреннән Баиш әүлиялар зиратына бару әйтелгәч, хәлиткеч нәтиҗә ясалган: «Хәер, барысы да аңлашылды кебек: бернинди Мәүла Колый да, һәмдәми дә юк. Алар бары тик имза-псевдонимнар гына. Җитмәсә – бер үк кешенекеләр. Шагыйрьнең чын исеме – Хуҗа Шөкер Гаваз-бай... Иҗатын яшьли башлаган... Соңыннан аларны «Хикмәте хәким...» исеме белән бергә туплап, җыентык итеп төзегән... Кабере – Баиш зиратында, «Хаким-ата астанасы» буларак билгеле. Татар әдәбияты тарихы фәненең «Мәүла Колый»га бәйле бер гасырлык эзләнүләре менә шуларны ачыклау белән тәмамланды. Күңелемдәге йөкләрем дә тәмам бушап калды кебек» (309 бит).

Бу чыгышның М.Колый турындагы, тыңлаучыларны киеренкелектә тотып килгән өлеше шулай төгәлләнгән. Китерелгән өземтәдәге «Мәүла Колый да... юк» дигәне белән, һәркем дә килешә. Чөнки алар хәзер юк, гомумән, күптәннән юклар – инде өч гасырлап элек үк вафат булган бит алар. Бәлки филология фәннәре докторы дигән мәртәбәле гыйльми дәрәҗә иясе галимнең «алар булмаган» диясе килгәндер?

Конференция материалларындагы чыгышының иң ахырында (309 биттә) Ф.Яхин «Әлмәт төбәгенең атаклы шагыйре Габдеррәхим Утыз Имәни» турында сүз башлап, «сабый чагыннан ул томана ятим кала, кардәшлек хис» дип, текст сәер генә рәвештә тукталып калган. Менә монда китерелгән өзектә дә тел-әдәбият белгеченең «томана

[19] Шунда ук. – Б. 309. Авторның язу стиле һәм имлясы китаптагыча сакланды.

ятим» сүзләре хәйран калырлык. Билгеле булганча, татар әдәби телендә «томана» сүзенең бары тик «надан, аңсыз» дигән мәгънәләре генә бар. Әдәбият галименең үзе сүз алып барган, зур иҗади мирас калдырган шагыйрьгә карата шулхәтле тупас сүз куллануы – үткәндәге олуг шәхесләргә игътибарсызлык күрсәтү генә түгел, хөрмәтсезлек билгесе булса кирәк.

Ф.Яхин дәлилләре тотрыклымы?

Әлмәттә табылган кулъязма китаптагы тулысынча язылып бетмәгән дата саннарыннан фаразлап, «Нәсыйхәтнамә» әсәрен галим башта 1628 елда иҗат ителгән һәм авторы Мәүлүдгол дип язган иде. Чынлыкта, Яхин «мең дә ун» дип таныган язу кулъязманың факсимилесында «мең дә ут» икәнлеге ачык күренә һәм аның язып бетерелмәгән дата булганлыгы аңлашылып тора. Фәрит Яхин 1010 дигән һиҗри елны милади белән 1628 елга тәңгәлләштереп, тагын бер хата ясаган. Чөнки 1010 һиҗри ел, дөреслектә, 1601/1602 елларга туры килә. Бу фараз бөтенләй нигезсез булгангадыр, галим ул мәсьәләне дәвам итмәде. Аннан соң Ризаэтдин Фәхретдиннең «Асар» хезмәтендә бер тарихи шәхескә бәйләп әйтелгән «нәсыйхәтнамә» дигән сүзгә нисбәт итеп, «Нәсыйхәтнамә» дип аталган зур шигъри әсәрне иҗат иткән кешенең кем икәнлеген дә, әсәрнең елын һәм урынын да башкача «ачыклап», шул турыда күп язды. Үзе фараз иткән версияне чын хакыйкать дип инандырырга тырышты, мәкаләләр һәм китаплар чыгарды. Бу әсәрнең әүвәлгерәк чорга караганлыгын, кулъязмалар да шуңа ишарә итүен искәрткән фикерләргә колак салмады, аларны кире кагу белән дә вакланмады.

Хуҗам Шөкер бине Гаваз-байга нисбәт итүенә килсәк, бу шәхес турында Р.Фәхретдиннең «таб халкына язган нәсыйхәтнамәсен һәм күрдек»[20] дигән юлларында

[20] Фәхреддин Р. Асар: үз мәмләкәтемездә улан ислам галимнәренең тәрҗемә вә табәкаләре, тарихе вилядәт вә вафатлары вә башка әхвәлләре хакында язылмыш бер китаптыр. 1 җөзъә. – Казан: тип.-лит. ун-та, 1900. – Б. 30.

«нәсыйхәтнамә» сүзе 1900 елгы басмада куштырнакларга алынмаган. Гәрчә ул хезмәттә китап исемнәре һәр очракта да куштырнакларга алынган, Хуҗам Шөкер турында язылган урында да өземтә-цитаталар куштырнаклар эчендә бирелгән[21]. Димәк, нәсыйхәтнамә сүзе бу очракта әсәр исемен белдермәгән, ә аерым бер түрәнең халыкка үгет-нәсыйхәтле язма мөрәҗәгате турында сүз барган. Тарихчы Р.Фәхретдиннең «таб халкына язган» дигән сүзләре шуны аңлата. «Асар»да Хуҗам Шөкер нәсыйхәтнамәсенең шигъри калыпта икәнлегенә дә бернинди ишарә юк. Ф.Яхин үзе дә моны искәртеп: «...шигырь белән язылганмы-юкмы икәнлеген ачыклап әйтмәгән»[22], – ди. Өстәвенә, Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә» әсәре текстында аның бернинди халыкка аерым атап язылганлыгы турында сүз бармый, кулъязма күчермәләренең берсендә дә андый нәрсә юк.

Ф.Яхин «Нәсыйхәтнамә» әсәренең авторы Һәмдәмине Себер татарына нисбәт итеп язса да, аның тагын кайбер шөбһәләрен искә алыйк. Мәсәлән, 2003 елгы китабында ул «...Бу әсәре аркасында авторының «Асар»га аерым мәкалә итеп кертелүе бу язмасының аерым бер кәгазь кисәге генә түгел, бәлки китап булганлыгын төшенергә ярдәм итә...» дип, әмма шул ук вакытта «Р.Фәхретдинов телгә алган «Нәсыйхәтнамә» әсәре нәкъ шушы Һәмдәминеке булырга кирәк. Әмма галим «Асар»ының бу бүлекләрен язганчы ук Һәмдәминең китабы Казанда берничә кат басылып чыкканлыгы, Р.Фәхретдинов кебек киң кырлы һәм татар халкының басма китапларын гына түгел, хәтта кулъязмаларын да яхшы белгән галимнең аңа игътибар итми калуы шикләндерә. Чөнки ул шушы үзе бәян иткән Шөкер бине Гаваз-байның

[21] Фәхреддин хезмәтенең соңгы чор басмаларында да Хуҗамшөкернең нәсыйхәтнамәсе турында сүз барганда куштырнаклар юк (Фәхреддин Р. Асар. 1 том / төз.: Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, С.Рәхимов. – Казан: Рухият, 2006. – Б. 35; Фәхреддин Р. Асар. 1 һәм 2 томнар. Төзәтелгән 3 нче басма / төз.: Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, С.Рәхимов, С.Хафизова, И.Гыймадиев. Әлмәт: «Татнефть» хәйрия фонды, 2024. – Б. 41.

[22] Һәмдәми (Хуҗам Шөкер бине Гаваз-бай). Нәсыйхәтнамә ..., 2018. – Б. 7.

«Нәсыйхәтнамә»се басылып чыкканлыгын искәртми»[23], – дип тә язды.

«Асар» хезмәтенең 1900 елгы, гарәп хәрефләрендә дөнья күргән беренче басмасында «Хуҗамшөкер» дип язылган исем соңгырак чор галимнәре тарафыннан «Хуҗам Шөкер» дип аерып язылуы ялгыш икәнлеген дә искәртергә кирәк. Чөнки татарларда икешәр компонентлы кеше исемнәре кушылып языла. Хуҗамшөкернең әтисе исеменең «бай» дигән өлеше дә Тимербай һәм Миңлебай исемнәрендәгечә үк, кушылып Гавазбай дип язылса – дөресрәк кебек. Хәер, бу исемнең «бай» өлеше Әлфрид Бостанов хезмәтендә, башка язма чыганаклар нигезендә, «бакый» (ягъни, «Гавазбакый») дип бирелгән[24].

Татар әдәбияты тарихының 2022 елда чыккан икенче томында Ф.Яхин версиясе турында аерым сүз булмаса да, аның карашына ияреп, «Нәсыйхәтнамә» авторы Шәкүр бине Гаваз»[25] дип теркәлгән. Бу сүзләр язылганнан ике бит алгарак киткәч (216–217 битләрдә) Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә» әсәре, аның кулъязма күчермәләре турында мәгълүмат бирелгән. Әсәргә күзәтү ахырында (217 биттә) «Һәмдәми (Мамай мелла)» дип аталганны күрәбез.

Иң хикмәтлесе – Ф.Яхин үзен татар әдәбияты тарихы фәненең Мәүла Колыйга бәйле бер гасырлык эзләнүләрен ачыклап, бөтен сорауларга җаваплар табып бетерүче итеп, зурлап бәяләгән. Моңа карата бик зур рәхмәттән башка сүз юк.

Йомгаклап әйтсәк, Ф.Яхинның «Һәмдәми» псевдонимы кемгә нисбәтле икәнлеген ачыклаудагы төп дәлиле – «Асар» дип аталган тарихи, биобиблиографик хезмәттәге «нәсыйхәтнамә» дигән бердәнбер сүз генә. Әйтеп үткәне-

---

[23] Яхин Ф. Урта гасырлар татар әдәбияты: татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология ..., 2003.– Б. 353, 375.
[24] Бустанов А. Книжная культура сибирских мусульман. – М.: Изд. дом Марджани, 2013. – С. 18–21.
[25] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 2 т. ..., 2022. – Б. 214.

безчә, бу сүз анда китап һәм әсәр атамасы буларак кулланылмаган. «Асар»да мәгълүмат теркәлгән Тубыл татарының әдәби иҗат белән шөгыльләнгәнлеген, аның Һәмдәми дигән тәхәллүскә ия булганлыгын белдергән бернинди ишарәфәлән дә юк. Ә фәндәге, авторлыкны ачыклау кебек, аеруча катлаулы мәсьәләләрнең төпле (бер генә түгел, ә комплекслы) дәлилләр белән раслануы шарт.

Димәк, Ф.Яхинның Һәмдәми дигән тәхәллүсне Тубыл татарына туры китерергә тырышкан бөтен омтылышлары – буш фаразлар белән артык мавыгу нәтиҗәсе. Һәмдәми әсәренең авторын билгеләүдәге уңышсыз омтылышы – галимнең бердәнбер хатасы түгел. Әдәбият тарихында исемнәре киң мәгълүм әсәрләрне Ф.Яхинның төрле чорга һәм төрле авторларга (мәсәлән, «Кисекбаш китабы»н бер очракта XI гасырда, ә икенче вакытта XIII гасырда яшәгән аерым әдипләргә) нисбәт итүе, каршылыклы фикерләре турында элегрәк тә язылды[26]. Ә алда әйтелгән «әл-Мәликелваһһап...» мәсьәләсен искә алганда, галимнең квалификациясе ачык күзаллана.

Себер татарларының китапчылык тарихын өйрәнгән Әлфрид Бостанов Һәмдәми тәхәллүсле кеше Хуҗамшөкер булган дигән гипотезаның нигезсез икәнлеген 2013 елда ук язган иде. Ул әлеге фаразның бары тик «нәсыйхәтнамә» дигән сүзгә генә корылган булуын, башка аргументлар юклыгын әйткән[27]. Китап авторы, дәлилләр булмавына карамастан, Ф.Яхин фаразының Себер татарлары тикшеренүчеләре арасында бик хуплануы турында да белдергән[28]. Ә.Бостанов,

---

[26] Раиф Мәрданов. Гарәп хәрефле татар кульязмаларының палеографик үзенчәлекләре ..., 2024. – Б. 192–194.

[27] Бустанов А. Книжная культура сибирских мусульман ..., 2013. – С. 18–19. Китапның үзендә болай диелгән: «...было бы уместно поделиться скептицизмом относительно широко распространившейся с лёгкой руки Ф.З.Яхина (г.Казань) гипотезы о том, что тобольский ахунд Хваджам-Шукур б. Авваз-Бакы носил поэтический псевдоним – тахаллус – Амдами (Һәмдами)... Однако, помимо совпадения в названии этих двух сочинений, к тому же не столь редкого, иных аргументов для отождествления Хваджам-Шукура и Амдами нет».

[28] Шунда ук. – Б. 19.

шулай ук, борынгы әсәрнең ун күчермәсен телгә алып, аларның берсендә дә Һәмдәминең Себергә бәйлелеге әйтелмәгәнен искәрткән[29].

Бу урында Фәрит Яхинның үз фаразына туры килми торган башка фикерләргә гомумән игътибар биреп тормаганлыгын искәртү урынлы булыр. Мәсәлән, Һәмдәми «Нәсыйхәтнамә»сенең 1659–1660 еллардагы кәгазьдә күчермәсе булу фактына күрә, аны авторы 1703 елда иҗат иткәнлеге бик шикле булуы турында Р.Мәрданов 2002 елда «Казан утлары» журналында (№3, 129–130 битләр) язганны, шулай ук С.Гыйлаҗетдиновның 2011 елгы хезмәтендәге «Шуридәи халь» китабы турында мәгълүматны, Ә.Бостановның Хуҗамшөкер белән Һәмдәминең бер үк шәхес түгеллеге турында 2013 елда әйткәнен Ф.Яхин исәпкә-санга алмады. Боларга карата бернинди аңлатмасын һәм мөнәсәбәтен белдермәде. Югыйсә, фән дөньясындагы тәртипләр буенча, ул үз карашын шик астына алган фикерләргә дә дәлилле җавабын әйтергә тиеш иде кебек.

## Әхмәтҗанов версиясе

Галим Марсель Әхмәтҗановның «Шагыйрь Һәмдәми яки Мелла Мамай» дип аталган күләмле мәкаләсе 2012 елда басылып чыкты[30]. Анда Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә» әсәре күчермәләре фәнгә тугыз кульязмада мәгълүм булуы әйтелгән[31]. Автор Ф.Яхин фикерләре белән килешми, ул язган даталар турында үз карашын җиткерә, Яхин фаразларына карата гомуми рәвештә: «...галимебез, эш процессында тупас хаталар җибәреп, аның язылу тарихы турында буталчык фикерләр язды һәм соңыннан бу темага кагылышлы язмаларында аларны тагын да тирәнәйтте»[32], – дип белдерә.

[29] Шунда ук. – Б. 19. Китапта болай язылган: «Во всех списках какая-либо связь переводчика – Амдами – с Сибирью, отсутствуют».
[30] Әхмәтҗанов М. Шагыйрь Һәмдәми яки Мелла Мамай // Чын мирас. – 2012. – №6. – Б. 54–66.
[31] Шунда ук. – Б. 55.
[32] Шунда ук. – Б. 55.

Әхмәтҗанов Әлмәт кулъязмасыннан Ф.Яхин 1010 ел дип укыган датаның ялгышлыгын әйтеп, аның 1601–1602 елларга туры килүен искәрткән. Бу датаның дөресе – «мең дә ут» датасы язылып бетмәгәнлегенә әһәмият биреп, ул 1030 һиҗри елга туры килә, шунлыктан әсәрнең язылган датасы 1621–1630 еллар булырга тиеш[33], – ди. Шул рәвешчә, М.Әхмәтҗанов бу әсәрнең иҗат ителгән вакытын тәгаенләп куйган.

Мәкалә авторы Һәмдәми «Нәсыйхәтнамә»се белән идеяләре уртак булган Мәүла Колый әсәрләрен гомуми чагыштыру рәвешендә күздән кичергән. Җыеп әйткәндә, М.Әхмәтҗанов ике шагыйрь иҗатында дөньяның фанилыгы, аны игелекле эшләр белән уздыру нәсыйхәтләре, тәкәбберлек сыйфатларының зыян салуы, икейөзлелек, Аллаһка мәхәббәт, юмартлык, әүлиялар һәм дәрвишләр, сабырлык кебек уртаклыкларны санап үткән (57–58 битләр).

Шулардан соң мәкаләдә XVII гасырда яшәгән күренекле шәхесләр, шул исәптән, Мелла Мамай – М.Колыйның остазы турында шактый тарихлар бәян ителгәннән соң, «Мелла Мамайның «Нәсыйхәтнамә» әсәре татар поэзиясен XVII йөздә яңа биеклеккә күтәрде...» дигән үзенчәлекле нәтиҗә ясалган. Гәрчә мәкаләдә Һәмдәми һәм Мелла Мамай бер үк кеше икәнлеген раслый торган һичбер төрле дәлил дә, хәтта шулай дип белдергән җөмлә дә юк.

Галимнең бу мәкаләсе «Татар әдәбияты тарихы»ның 2014 елда чыккан икенче томында да үзгәрешсез диярлек урын алган иде[34]. Ә әдәбият тарихының 2022 елгы басмасына М.Әхмәтҗанов мәкаләсе тулаем хәлендә кертелмәгән. Бары тик икенче томның гомуми кереш мәкаләсендә генә телгә алынган. Анда «М.Әхмәтҗанов Һәмдәминең иҗатын Мәүла Колый иҗаты белән чагыштырып, бик күп уртаклыкларны билгели, алар остаз-укучы булганнармы икән дигән фараз әйтә» дип, 2014 елгы басмага ишарә ителгән[35].

---

[33] Шунда ук. – Б. 56.

[34] Әхмәтҗанов М. Һәмдәми (Мамай мелла) // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Т. 2 ..., 2014. – Б. 233–241.

[35] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 2 т.: XV–XVIII гасырлар ..., 2022. – Б. 22.

М.Әхмәтҗанов дәлилләре тотрыклымы соң?

«Нәсыйхәтнамә»нең тугыз күчермәсе билгеле булуы, шулардан XVII гасырның икенче яртысына нисбәтле өч кульязмасы барлыгы турында әйтелүе[36] – Һәмдәми әсәренең Ф.Яхин фаразлаганнан элеккерәк чорда иҗат ителгәнен раслый торган какшамас фактик дәлил. Монысы белән килешмичә булмый.

Әлмәттә табылган «Нәсыйхәтнамә» күчермәсенең ахырындагы «тарих мең дә ут» дип, теркәлеп бетмәгән дата буенча Ф.Яхинның нигезсез фаразына ияреп, М.Әхмәтҗанов бик ялгышкан. Гәрчә үзе Яхинның «мең дә ун» дип укыган хатасын «мең дә ут» (утыз) итеп дөресләсә дә, әлеге датаның әсәр иҗат ителгән вакытны белдерүе турындагы ялгыш фикерне үстереп, үз фаразын да әлеге дата белән дәлилләргә омтылган.

Әлмәт кульязмасындагы тулаем язылып бетмәгән датаны белдергән сүзләрнең әсәр текстын күчерү этапларында элеккерәк протографларның берсеннән-икенчесенә күчеп килгән дата икәнлеге аңлашыла. Моңа охшаш мисаллар татар археографиясендә билгеле, мәсәлән, Мөхәммәдьяр әсәрләренең күчермәләрендә шундый очраклар бар[37]. Монысы – беренчедән. Ә икенчедән – урта гасырлар әдәбиятыбыз тарихында билгеле булганча, тезмә әсәрләрнең иҗат ителгән еллары текстның үз эчендә, гадәттә, ахыргы шигъри юлларында белдерелгән. Мәсәлән, Кол Гали язган «Кыйссаи Йосыф»ның бетем өлешендә (1010 дүртьюллыктан торган әсәрнең 1009 нчы строфасында) «тарих чөн алты йөз тукызындан / бу зәгыйфь бу китабы дөзде имди» диелгән, Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасының иҗат ителгән вакыты текстның башындарак (69 нчы бәйтендә) ачык әйтелгән, ә ахырында

[36] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Т. 2: XV–XVIII гасырлар ..., 2014. – Б. 234.

[37] Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кульязмаларының палеографик үзенчәлекләре ..., 2024. – Б. 77–78.

(792 нче бәйттә) төгәлләнгән датасының ае күрсәтелгән[38]. Мәүла Колыйның үз әсәрләрендә аталган бердәнбер дата – 5 нче хикмәтенең ахыргы дүртьюллыгы эчендә – «сиксән сигез ирде ул көн тарих мең дә» дип белдерелгән. Бу мисаллардан күренгәнчә, мөселман-татар шигърияте традицияләре буенча әсәрнең иҗат ителгән вакыты текстның эчендәге шигъри юлларда әйтелгән. Әлмәт кульязмасындагыча, текст өлеше беткәннән соң «тарих...» рәвешендә язылган сүзләр – төп тексттан тыш, кульязманың күчерелүенә генә бәйле мәгълүмат. Алар әсәр текстының иҗат ителгән датасын белдерми. Ике галимнең дә, борынгы әсәрләрнең иҗат ителгән вакытлары текст эчләрендә күрсәтелү фактлары белән исәпләшмәүләре өстенә, утызга якын күчермәсе булган «Нәсыйхәтнамә»нең бары тик берсендә генә – Әлмәт кульязмасында гына булган һәм аңлаешлы итеп язып бетерелмәгән ел-дата буенча фаразлар корулары – җитди ялгышлык.

Марсель Әхмәтҗановның мәкаләләрендә Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә» әсәре «язылуына төп сәбәп булып Рус дәүләтенең XVII гасырдагы эчке сәясәтенә реакция тора» дип белдерелгән. Бу фикерне дәлилләү өчен шул чордагы катлаулы тарихи-иҗтимагый хәлләр тасвирланган булса да, болар – әсәргә карата ышанычлы раслама түгел. Чөнки «Нәсыйхәтнамә» текстындагы гомуми үгет-нәсыйхәтчелекне аерым бер гасырга гына нисбәт итеп булмый. Киресенчә, шундый ук сәяси һәм тарихи хәлләрне башка гасырларга, гомумән, бүтән чор-дәверләргә дә нисбәт итәргә мөмкин. Димәк, бу дәлил – ышанычсыз.

Мәүла Колый иҗаты белән уртаклыклар турындагы сүз М.Әхмәтҗановның бу мәкаләсендә «Һәмдәми әсәрләренә охшатып язучылардан Мәүла Колый дигән шагыйрь иҗаты кызыклы» дип башланган. Галимнең ике шагыйрь арасында бәйләнеш дип тәкъдим иткәне – урта гасырлардагы төрки-татар әдәбиятына хас гомуми мотивларны күрсәтүдән

[38] Мөхәммәдьярның «Нуры содур» әсәре / төз. Р.Мәрданов. – Казан, 2025. – Б. 15–20, 129, 188.

гыйбарәт. Андый уртаклыкларны башка күп авторлар иҗатында да ачык күрергә мөмкин. Мәсәлән, XVI гасыр татар шагыйре Мөхәммәдьяр әсәрләре белән Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә»се арасында охшашлыклар тагын да күбрәк.

Әхмәтҗанов Һәмдәми турында сүз алып барганнан соң, «Мәүла Колыйның 5 нче хикмәте бу ике шагыйрьнең бәйләнешен һәм яшәү рәвешен күрсәтә торган бер чыганак булып тора»[39] дисә дә, ул хикмәттә М.Колый үзенең остазы итеп Мелла Мамай исемен генә атаган. Кызганычка каршы, Һәмдәми тәхәллүсле шагыйрьне Мәүла Колыйның хикмәтендә телгә алынган Мамай мелла (Мелла Мамай) исеменә турыдан-туры бәйли торган бүтән дәлил-чыганак автор тарафыннан күрсәтелмәгән.

Гомумән, М.Колыйның бер генә хикмәтендә дә Һәмдәми дигән исем аталмаган, шулай ук аңа ишарә дә юк. Димәк, Һәмдәми – Мәүла Колыйның остазы дигән караш шулай ук ышанычлы фактик дәлилләргә нигезләнмәгән.

Нәтиҗәдә, М.Әхмәтҗанов мәкаләсендә Һәмдәминең кайсы чорда яшәп иҗат иткән шагыйрь булуы, аның Мелла Мамай һәм Мәүла Колый исемнәренә мөнәсәбәте ышанырлык дәлилләр һәм чыганаклар белән фәнни расланмаган.

## Һәмдәми әсәренең кулъязмалары

Һәмдәми тарафыннан иҗат ителгән «Нәсыйхәтнамә» әсәренең кулъязма күчермәләре турында галимнәр язганнарга гомуми бер күзәтү ясап, үзебездән өстәмәләр теркәп кую да файдалы булыр.

Алда әйткәнебезчә, әлеге әсәрнең 1781 елгы күчермәсе турында Н.Юзиев һәм А.Фәтхи язганнар. Аннан соң Ф.Яхин 1990 елда үзе тапкан 1787 елгы күчермәне «икенче кулъязмасы» дип атаган. Гәрчә, аңарчы Ленинградтагы СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү

[39] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Т. 2: XV–XVIII гасырлар..., 2014. – Б. 239.

институтында Һәмдәми әсәренең дүрт күчермәсе саклануы турында мәгълүмат 1980 елда ук чыккан иде[40]. Бу тасвирламада Һәмдәми исеме ялгышлык белән «Хамди» диелгән булса да, шунда ук текстының беренче юлы гарәп хәрефләре белән басылган – ә аннан нинди әсәр икәнлеген танырга мөмкин.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә Һәмдәми әсәренең ике күчермәсе барлыгын без дә хәбәр иткән идек. Аларның берсе Европада 1659–1660 нчы елларда эшләнгән кәгазьгә теркәлгән булуы искәртелде[41].

Галим С.Гыйлаҗетдинов 2011 елгы хезмәтендә Һәмдәми әсәренең 6 кульъязма күчермәсе билгеле дип язган иде[42]. Шулардан дүртесе Петербургтагы нөсхәләр, берсе 1962 елда Пермь өлкәсендә һәм тагын берсе 1990 елда Әлмәттә табылган күчермәләр дип белдерде. (Милли китапханәдәгеләре бу исәпкә кермәгән).

Марсель Әхмәтҗанов 1980 елда табылган тагын бер күчермәне кушып, 2012 елгы мәкаләсендә «бүгенге көндә «Нәсыйхәтнамә» әсәренең тугыз күчермәдә булуы

---

[40] Дмитриева Л.В. Описание тюркских рукописей Института востоковедения. Т. III: поэзия и комментарии к поэтическим сочинениям, поэтика. – М: «Наука», 1980. – С. 142. Шул ук мәгълүмат 2002 елгы басмада кабатланды: Дмитриева Л.В. Каталог тюркских рукописей Института востоковедения Российской Академии наук. – М: Вост. лит., 2002. – С. 367–368.

[41] Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – №3. – Б. 130; Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары... – Казан: «Милли китап» нәшр., 2010. – Б. 61.

Әйтелгән XVII гасыр кульъязмасыннан бер битенең фотокүчермәсе, XV–XVI гасырларда иҗат ителгән әсәр буларак, беренче мәртәбә 2013 елда басылган иде (Татар китабы = Татарская книга: альбом / төз.-авт. Р.Мәрданов, И.Һадиев; рәс. Ш.Насыйров. – Казан: Татар. китап нәшр., 2013. – Б. 93), аннан соң «Татар әдәбияты тарихы»ның 2014 һәм 2022 елларда нәшер ителгән икенче томнарындагы фототупламнарда күчерелеп басылды. Шулай ук басылды: Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кульъязмаларының палеографик үзенчәлекләре ..., 2024. – Б. 193.

[42] Гилязутдинов С. Персидско-татарские литературные связи (X – начало XX в.). ..., 2011. – С. 145.

мәгълүм»[43] дип язды. Алардан тыш, М.Әхмәтҗанов Башкортстанда 1690/1691 елларга караган тагын бер күчермәсе булуын телгә алган. Димәк, Һәмдәми әсәре 2012 елга ун кульязма күчермәдә билгеле булган диярга мөмкин.

Әлфрид Бостанов 2013 елгы хезмәтендә Һәмдәми әсәрләренең ун күчермәсе[44] билгеле булуын әйтеп, Ф.Яхин икесен генә искә алган дип язган иде[45]. Бостановның Һәмдәми «Нәсыйхәтнамә»се күчермәләреннән икесе Себердә саклануы турында язган хәбәре игътибарга лаек. Аларның берсе Омск университетында (XVIII гасыр ахыры күчермәсе), ә икенчесе (XIX гасыр башына нисбәтлесе) Төмән өлкәсенең Тубыл районындагы Япанчы (Хуча Йалан) авылы мулласында саклана икән[46].

Боларга өстәп, үзебез исәпләгән тулырак мәгълүматны белдерү урынлы булыр. Хәзерге вакытта (2025 елның ахырында) Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә» әсәре күчермәләре Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә барлыгы 13 кульязмада, Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә 7 берәмлек. Аларның күләмнәре төрлечә: берничә битледән алып тулы текстлыларга хәтле. Димәк, ике китапханәдә бу әсәрнең 20 күчермәсе бар. Боларга Россия Фәннәр академиясенең С.-Петербург шәһәрендәге Көнчыгыш кульязмалары институтында саклана торган 4 берәмлекне, Ф.Яхин кулланган

[43] Әхмәтҗанов М. Шагыйрь Һәмдәми яки Мелла Мамай // Чын мирас. – 2012. – №6. – Б. 55. Шул ук мәгълүмат кабатланды: Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Т. 2: XV–XVIII гасырлар ..., 2014. – Б. 233–234.

[44] Китап авторы Ә.Бостанов бу санга карата астөшермәдә алда әйтеп үтелгән ике хезмәтне: Л.Дмитриеваның 2002 елгы каталогын һәм С.Гыйлаҗетдиновның 2011 елгы китабын күрсәткән. Ләкин авторның, ун күчермә дигәндә, төгәл кайсыларын күздә тотканлыгы аңлашылмый. Чөнки Дмитриева Петербургтагы дүрт күчермә турында мәгълүмат биргән булса, Гыйлаҗетдинов шул ук дүрткә өстәп тагын икене атаган, ягъни бу ике галим китапларында әсәрнең алты күчермәсе турында сүз бара. Ә.Бостановның ун дигән саны эчендә икесе – Себердәге, моңарчы телгә алынмаган күчермәләр. Димәк, барлыгы 8 күчермә генә килеп чыга. Бостановның «ун» дигәненә тагын ике күчермә җитми.

[45] Бустанов А. Книжная культура сибирских мусульман ..., 2013. – С. 19.

[46] Шунда ук. – Б. 19.

Әлмәт нөсхәсен, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтындагы (1980 елда табылган[47]) берәмлекне, шулай ук Себердә саклана торган ике күчермәне, Башкортстандагы бер нөсхәне[48] кушып исәпләгәч, Һәмдәми язган «Нәсыйхәтнамә» әсәренең фәнгә билгеле кульязма күчермәләре барлыгы 29 данәне тәшкил итә.

Кульязмаларның университет китапханәсендәге берсе һәм Татарстан Милли китапханәсендәге берсе XVII гасырның икенче яртысына, Башкортстандагысы 1690 (1691) елга нисбәтле. Калганнарының унысы: Казан университеты китапханәсендәге җиде, Петербургтагы бер һәм Әлмәттә табылганы, Милли китапханәдәге берсе – XVIII гасырда күчерелгән нөсхәләр. Шулардан дүртесе XVIII гасырның башына карый: Петербургныкы 1720 нче елларныкы, Казан университеты китапханәсендәге берсенең кәгазе 1700 нче елгы, тагын икесе шулай ук XVIII гасыр башы күчермәләре. Һәмдәми әсәре 1703 елда язылган дип дәгъвалаучы Ф.Яхин борынгырак күчермәләрне ачыклап, аларны тикшергән булса, һич тә зарар итмәс иде. Ул үзе белдергән версияне тәмам ачыклау өчен авторның үз кулы белән язылган нөсхәсен табарга тырышып эзләнергә тиеш булгандыр.

Нинди дә булса әсәрнең авторын ачыкларга алынучылар иң әүвәл беренчел чыганакларның мөмкин кадәрле күбрәк күчермәләрен өйрәнә. Ләкин Ф.Яхин һәм М.Әхмәтҗанов алай итмәгәннәр. Галимнәр Һәмдәми әсәре теркәлгән кульязмаларның һичьюгы Казандагылары белән кызыксынсалар, мәгълүматлары, һичшиксез, тагын да киңрәк һәм тулырак булыр иде. Казан университеты китапханәсендә саклана торган 13 берәмлек күчермәнең берсе 1930 нчы елларда, калганнары 1962–1988 еллар арасында тупланганнар бит. Шуларның берсен 1974 елда М.Әхмәтҗанов үзе тапшырган булган. Ә Республика Милли китапханәсендәге

[47] Әхмәтҗанов М. Шагыйрь Һәмдәми яки Мелла Мамай // Чын мирас. – 2012. – №6. – Б. 55.
[48] Шунда ук. – Б. 55.

7 берәмлек ядкяр 1995–1998, 2015 һәм 2017 елларда фондка кергән. Болары да әлеге тема буенча галимнәр актив эшләгән чорга туры килә, һәрхәлдә, Ф.Яхин 2018 елда Һәмдәми китабын бастырганчы ук китапханә киштәләрендә белгечләрне «көтеп ятканнар».

Шуны да әйтү зарур, санап үтелгән күчермәләрнең барысы да диярлек Идел-Урал төбәгендә табылганнар. Төгәлрәк итеп әйтсәк, Казан университеты күчермәләренең өчесе Казан шәһәрендә, икесе Пермь өлкәсендә, берәр кульъязма Свердловск һәм Горький өлкәләрендә, өч күчермә Татарстанның Актаныш, Кама Тамагы, Чирмешән районнарында һәм икесе Мөслим районында археограф галимнәр тарафыннан тупланганнар. Берсенең генә кайда табылганлыгы теркәлмәгән. Петербург күчермәләренең дүртесе дә, гомуми рәвештә, Идел буеннан дип күрсәтелгән. Татарстан Милли китапханәсендәге күчермәләрнең дүртесе Арча, берсе Тәтеш һәм берсе Балык Бистәсе районнарыннан, берсе исә Уфа шәһәрендә табылган.

Әгәр дә Һәмдәми, Яхин ышандырырга теләгәнчә, чынлап та, Тубыл татары булса, әсәр күчермәләренең күпчелеге, һичшиксез, Себер якларында күбрәк таралган, сакланган һәм табылган булыр иде. Ә хәзергә Һәмдәми әсәренең Себердә ике кульъязма күчермәсе барлыгы турында Ә.Бостанов язган буенча гына билгеле.

Һәр кульъязма истәлек үзе аерым хасиятләргә ия булган кебек, «Нәсыйхәтнамә» күчермәләрендәге текстларда үзенчәлекләр аз түгел. Әсәрнең кульъязмалары белән өстән-өстән генә танышканда да текстлардагы төрлелек күзгә чалына. Элеккерәк нөсхәләрдә дөрес язылган сүзләрнең XIX гасыр күчермәләрендә инде архаиклашкан һәм күчерүчеләр тарафыннан ялгыш танылганлыклары сәбәпле, әсәр текстының бик бозылган урыннары шактый. XIX гасырда басылып чыккан нөсхәсендә андый очраклар тагын да күбрәк. Шигъри юлларда текст аерымлыклары булу белән бергә, кайберләрендә бүлек исемнәре

башкача аталганлыгы игътибарны җәлеп итә. Бүлекләрнең кайберсе гарәп телендәге гыйбарә белән белдерелгән, ә башкалары татарча исемләнгән. Мәсәлән, «Түрт нәрсә бәдбәхетлек галәмәтедүр», «Фи кыйссаи мөселман», «Түрт нәрсә падишаһларга зыян улмак бәяны», «Гыйлемнең кадерене белмәк бәяны» һ.б. Күләмле шигъри әсәрләрдәге бүлекләрнең мондый рәвештәге – «... бәяны», «... бәяныдыр», «... бәян кылыр», «... бәян итәр» кебек исемнәр белән аталуы төрки-татар әдәбиятында электән үк – Вафаи, Мөхәммәдьяр, Аллаһъяр Суфи кебек шагыйрьләрнең әсәрләреннән килгән һәм хәтта XIX гасырда Габдерәхим Утыз Имәни белән Габделҗәббар Кандалый иҗатларында да бар. «Нәсыйхәтнамә» әсәренең кайбер күчермәләрендә текстлар бүлекләргә аерылмыйча, тоташтан теркәлгән.

Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә» әсәре белән бер үк чорларда диярлек (һәрхәлдә, XVI гасыр уртасына кадәр) иҗат ителгән башка бер, күләме ягыннан кечерәк, ләкин шундый ук исемдәге әсәрнең кулъязма күчермәләре дә сакланган. Менә ул «Нәсыйхәтнамә»нең авторы билгесез, тәлхәллүсе һәм язылган елы да күрсәтелмәгән. Гәрчә шигъри теле күркәм һәм анда да борынгылыклар шактый.

## Нәтиҗә

Югарыда тасвирлап үтелгән версияләрдә нигезле һәм ышанычлы дәлилләр булмавы сәбәпле, Һәмдәми турында моңарчы Ф.Яхин һәм М.Әхмәтҗановның киң җәмәгатьчелеккә китапларда һәм мәкаләләрдә чынбарлык сыйфатында тәкъдим иткән фикерләрен татар әдәбияты тарихы өчен яраксыз дип бәялибез. Борынгы чорларда кем тарафыннан иҗат ителгәнлеге билгесез әсәрләрнең авторларын ачыкларга омтылып, ялгыш нәтиҗәләр ясалуы – сөйләп үтелгән версияләр мисалында әдәбият тарихы фәнендәге катлаулы мәсьәләләрне җиңелчә хәл итәргә омтылу очраклары.

«Нәсыйхәтнамә» әсәренең авторын ачыкларга тырышкан галимнәрнең фаразлары, кызганыч ки, уйдырма дәрәҗәсендә генә. Мондый очраклар фәндә фальсификация дип тә атала. Ышанычлы итеп расланмаган, уйдырма катыш фаразлар фәнни яңалык буларак кабул ителә алмый. Хәер, кайчакта дәлилсез булса да, күп мәртәбә кабатлап язып килгәннән соң, ялгыш икәнлеге ачык фактлар белән расլангач та, аерым хаталар дәвам итеп килә. Мәсәлән, «Сөй гомерне, сөй халыкны...» шигыре Сәгыйть Сүнчәләй имзасы белән XX гасыр башындагы матбугатта – Казанда нәшер ителгән «Йолдыз» газетасында 1912 елда басылган булуына һәм галимнәрнең дәлилләп язуларына[49] карамастан, аны хәзергәчә Габдулла Тукай шигыре дип йөртү гадәте күпләргә таныш. Кайбер әдипләр һәм галимнәр «фәнгә шулай кереп киткән инде» дип, бу хәлгә күз йомарга дәгъвәт иткәлиләр. Әмма чын фән дөньясында мондый мөнәсәбәт булырга тиеш түгел.

Һәмдәми әсәре турында Ф.Яхин һәм М.Әхмәтҗанов үз фаразларына тарихи хезмәтләр һәм язма чыганаклар аша исемнәре билгеле булган шәхесләрне үткәндәге вакыйгалар белән аралаштырып-кушып, әдәби мәсьәләләрне дә катыштырып яздылар. Андый ысул белән эш итеп һәм шул ук бер мәгълүматны, Шомбай бишмәте кебек кабат-кабат әйләндереп, кайбер уйдырма детальләр өстәп, еш кабатлап торгач, җәмәгатьчелекнең, шул исәптән галимнәрнең дә бер өлеше хакыйкать дип кабул итте диярлек.

Ике төрле версия авторларының, үзләре филологлар буларак, Һәмдәми – Мелла Мамай – Мәүла Колый – Хуҗамшөкер текстларын тел-стиль, шигърият мәсьәләләрендә тәфсилле гыйльми тикшерүләре юк. Аның булуы мөмкин дә түгел, чөнки Мелла Мамай белән Хуҗамшөкернең бер генә җөмләсе, хәтта бер генә сүзләре теркәлгән язма чыганак та

---

[49] Сүнчәләй С. Әсәрләр һәм хатлар / төз. З.Рәмиев. – Казан: Татар. китап нәшр., 2005. – Б. 106, 329; Габдулла Тукай. Энциклопедия. – Казань: ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова, 2016. – С. 217.

юк һәм алар дәлил итеп китерелмәгән. Шуңа карамастан, галимнәр аптырап тормыйча, «тисә – тиенгә, тимәсә – ботакка» ысулы белән хәлиткеч нәтиҗәләр чыгарып, үзләренчә ачышлар ясадылар. Гомумән, бик кызыклы манзара хасил булды: язма сүзләре хәзергәчә килеп ирешмәгән хәлдә, аерым шәхесләрнең авторлыклары «дәлилләнде». Бу, кызганыч ки, абсурд дәрәҗәсендәге, һәрхәлдә, фәннилектән ерак бер нәрсә.

Хәтта иҗади мираслары билгеле булган Һәмдәми белән Мәүла Колыйны да остаз-шәкерт буларак яисә, Ф.Яхин фикеренчә, икесе бер үк кеше дип каралган очракта, ышанырлык итеп чагыштырылган, төпле һәм детальле нәтиҗәләр тәкъдим ителмәде. Мәгълүм ки, остазның шәкертенә йогынтысы булмыйча калмый һәм ул соңгысының иҗатында берникадәр чагыла. Ә язма истәлекләрнең бер үк авторныкы икәнлеген раслау өчен дәлилләр күп була. Тәҗрибәле әдәбият галимнәренә андый тикшеренүләр әлләни кыен да түгел кебек.

Гомумән, тел һәм лексика ягыннан, шулай ук шигъри үзенчәлекләре белән Һәмдәми әсәре Мөхәммәдьяр иҗатына күбрәк якын. Әгәр галимнәр тарафыннан шундый фараз белдерелгән булса, бәлки ышанычлырак дәлилләр тапкан булырлар иде. Асылда фарсы сүзе булган «Һәмдәми» тәхәллүсенең «иң якын дус, тугры яр, ихласлы иптәш» мәгънәләренә игътибар итсәк тә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең иң якын дусты – яры исеменә ия татар шагыйре Мөхәммәдьяр күздә тотылган дип уйларга мөмкин бит. Мөхәммәдьяр иҗатында Гаттар йогынтысы көчле булуын башка галимнәр дә язды. Мәсәлән, Сәлим Гыйлаҗетдиновның Мөхәммәдьяр язган «Нуры содур» поэмасы Фәридеддин Гаттарның «Пәнднамә» әсәренә якын тора дигән фикерен искә алыйк[50].

Һәмдәми «Нәсыйхәтнамә»сенең кулъязма күчермәләрендә борынгырак чорда иҗат ителгән әсәрләргә хас пале-

[50] Гилязутдинов С. Персидско-татарские литературные связи (Х – начало XX в.) ..., 2011. – С. 95.

ографик үзенчәлекләр дә бар. Мәсьәләнең менә ул ягына да иске кулъязма белгечләре әһәмият бирмәгәннәр.

Элеккерәк чорда һәм иҗат ителгән вакытлары белән берберсенә якынрак заман әсәрләренең бер үк җыентыкларга тупланган булу җәһәтеннән тикшерү дә мәсьәләне төшенүгә азмы-күпме файда иткән булыр иде. Югыйсә, иҗат ителгән вакытлары билгеле булган XV–XVI гасырлардагы Вафаи, Раушани, Мөхәммәдьяр әсәрләре белән бер үк җыентыкларда Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә»се саклангалыгы да фикер йөртергә нигез булып тора. Кызганычка каршы, Һәмдәми иҗат иткән «Нәсыйхәтнамә»нең кулъязма нөсхәләрен тулырак өйрәнмәү генә түгел, галимнәребез аларның санын-исәбен дә тиешенчә барламаганнар.

Шулай ук фарсы әдәбиятының шигъри җәүһәрләреннән төрки-татарчага тәрҗемәләр нигездә татар ханлыклары (Алтын Урда дәүләте, Казан һ.б.) чорларында башкарылган булуын искә төшерик. Ирекле тәрҗемәләр белән бергә, татар әдипләре нәзыйрә рәвешендәге үз иҗат җимешләрен дә тудырганнар. Безнең фикеребезчә, Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә»се дә, һичшиксез, XVI гасыр уртасына кадәрге чорда иҗат ителгән[51]. Аның күпсанлы кулъязмалары төрле төбәкләрдә табылуы – бу әсәрнең татарлар арасында бик популяр булганлыгын күрсәтә. Ә кулъязмаларының XVII–XVIII гасырларда күчерелгән нөсхәләре хәзергәчә сакланганлыгы – әсәрнең борынгылыгына ачык дәлил. Ә аннан да әүвәлгерәк нөсхәләре булмавы гаҗәп түгел, чөнки татар әдәби истәлекләреннән XIII гасырда иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» әсәре күчермәләренең дә XVII гасырдан элеккерәкләре хәзергәчә сакланмаган[52].

Димәк, безнең фикеребезчә, Һәмдәми тәхәллүсе белән «Нәсыйхәтнамә» әсәрен иҗат иткән шагыйрьнең үз исеме

[51] Бу турыда моннан ун ел элек искәртеп узган идек ([Мөхәммәтәмин]. Гыйлем Хакка илтер / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2016. – Б. 41).
[52] Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кулъязмаларының палеографик үзенчәлекләре ..., 2024. – Б. 31–32.

билгесез һәм, ышанычлы чыганаклар булмавы сәбәпле, аны ачыклау мөмкин түгел. Әсәре исә, XVI гасыр уртасына хәтле чорга карый. Һәмдәми һәм XVII гасырда яшәгән Мелла Мамай – икесе дә бер үк кеше дигән караш ялгыш. Шулай ук, Һәмдәми – Тубыл татары Хуҗамшөкер бине Гавазбай дигән фараз фәнни дәлилләр белән расланмый.

XVII гасырда яшәп иҗат иткән, хәзерге вакытка күпсанлы шигырь-хикмәтләре һәм өч поэмасы билгеле булган шагыйрь Мәүла Колый шәхесен Һәмдәми белән тәңгәлләштерү һич дөрес түгел. Гомумән, Һәмдәми һәм Мәүла Колый – икесе бер үк кешенең – Хуҗамшөкер бине Гавазбай исемле Себер татарының псевдонимнары дип ышандырырга тырышуларның бернинди нигезе юк, мондый фараз – шагыйранә уйдырма гына.

# РЕЗЮМЕ

Тридцать шестой выпуск серии «Татарская археография» посвящён новым находкам, относящимся к творчеству известного татарского поэта XVII века Мавля Кулый.

Первая глава книги включает в себя неизвестные до настоящего времени два текста произведений поэта: поэму, посвящённую пророку Адаму и один хикмет-стихотворение «Дэрвишлэр сохбэтендэ» («В сообществе дервишей»). Текст поэмы неполный, сохранившаяся часть составляет более 70 двустиший. Список поэмы обнаружен в рукописном сборнике I половины XIX века. Имя автора – Мавля Кулый – указана в двух местах текста. (В том же сборнике имеются тексты пяти хикметов М.Кулый). А хикмет «Дэрвишлэр сохбэтендэ», состоящий из десяти строф, в последней из которых также указано имя автора, сохранился в другом сборнике XIX в.

Кроме вышеназванных произведений в одиннадцати рукописных источниках, относящихся к XIX веку, были обнаружены новые списки ранее известных и опубликованных семнадцати хикметов М.Кулый. Четыре из них являются полными текстами, остальные – неполные. Хотя в последних содержатся новые строфы, дополняющие тексты. Например, в списке хикмета, ранее известного как 79-й, имеется семь строф, неизвестных до сего времени. Тексты новых списков хикметов М.Кулый представлены во второй главе книги.

Большая часть рукописных источников, в которых выявлены тексты произведений М.Кулый, хранятся в Научной библиотеке им. Н.И.Лобачевского Казанского федерального университета (почти все они были приобретены в архео-

графических экспедициях Альбертом Фатхи в 1972–1977 годах), некоторые списки хранятся в Национальной библиотеке Республики Татарстан.

В результате нововыявленных текстов творчество Мавля Кулый пополнилось ранее неизвестными 210 стихотворными строками и стали известны ещё 11 рукописных источников, которые являются существенным дополнением к известным шести сборникам, содержащим произведения поэта.

В третьей главе книги представлены три текста хикметов, авторство которых ещё полностью не установлено, но предполагаемые, что им был М.Кулый. К сожалению, в них отсутствуют строфы, где традиционно указывалось имя автора. Возможно, они не сохранились, точнее не были включены в списки переписчиками.

Книга содержит вступительную статью, общие описания рукописных источников, тексты произведений и факсимиле рукописей. В отдельной статье рассмотрен вопрос о несостоятельности двух версий учёных по поводу установления ими личности автора средневекового произведения «Насихатнамэ», известного под псевдонимом Хамдами. Если по одной версии Хамдами был наставником поэта М.Кулый, то по другой – Хамдами и Мавля Кулый – оба являлись псевдонимами одного и того же автора. Эти версии являются лишь умозрительными предположениями, не имеющими научной доказательной базы, что в итоге вносит лишь большую путаницу в историю татарской литературы.

# «ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ» СЕРИЯСЕНДӘ ЧЫККАН КИТАПЛАР

(Төзүчесе – археограф, текстолог Раиф Мәрданов;
«Милли китап» нәшрияты)

**Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты».** – Казан, 2008. – 88 б. – (1 нче китап). Шул ук. Икенче басма. – Казан, 2011. – 88 б.

**Түләк китабы: дастан.** – Казан, 2008. – 76 б. – (2 нче китап).

**«Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар.** – Казан, 2009. – 92 б. – (3 нче китап).

**Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы: әсәрнең Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмалары.** – Казан, 2009. – 128 б. – (4 нче китап).

**Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары...** – Казан, 2010. – 92 б. – (5 нче китап).

**[Мөхәммәтәмин]. Кыйссаи Мансур.** – Казан, 2010. – 128 б. – (6 нчы китап).

**[Фәезханов Хөсәен]. Кыскача татар тарихы.** – Казан, 2011. – 68 б. – (7 нче китап).

**Сәяхәтнамәләр.** – Казан, 2011. – 84 б. – (8 нче китап).

**Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте.** – Казан, 2012. – 184 б. – (9 нчы китап).

**Кыз хикәяте.** – Казан, 2012. – 184 б. – (10 нчы китап).

**Сөрген хатлары.** – Казан, 2013. – 103 б. – (11 нче китап).

**«Гәүһәр Болгарга килдем...»: тарихи бәетләр.** – Казан, 2013. – 128 б. – (12 нче китап).

**«Без плиндә ятамыз читлектәге кош кебек...»: Беренче бөтендөнья сугышы бәетләре.** – Казан, 2014. – 119 б. – (13 нче китап).

**Гали авылы тарихы.** – Казан, 2014. – 164 б. – (14 нче китап).

**Тинчурин К. Каракүз: музыкаль мелодрама; Нәни абый: комедия.** – Казан, 2015. – 192 б. – (15 нче китап).

**Тинчурин К. Чит илләрдә: хыялый комедия.** – Казан, 2015. – 108 б. – (16 нчы китап).

**[Мөхәммәтәмин]. Гыйлем Хакка илтер.** – Казан, 2016. – 124 б. – (17 нче китап).

**Сугыш һәм солдат бәетләре.** – Казан, 2016. – 264 б. – (18 нче китап).

**Дастане җайә (Мәликә китабы).** – Казан, 2017. – 148 б. – (19 нчы китап).

**Матрос Әхмәдулла дәфтәре: 1898–1906 еллар.** – Казан, 2017. – 140 б. – (20 нче китап).

**Алдым каләм, яздым сәлам...: хатлар.** – Казан, 2018. – 180 б. – (21 нче китап).

**Солдат Ярулла дәфтәре: бәетләр һәм мөнәҗәтләр. 1905–1906 еллар.** – Казан, 2018. – 92 б. – (22 нче китап).

**«Чыңгызнамә»: тарихи дастаннар.** – Казан, 2019. – 288 б. – (23 нче китап).

**Халык җырлары: XVII–XX гасырлар.** – Казан, 2019. – 146 б. – (24 нче китап).

**Бөек Ватан сугышы хатлары, солдат хатирәләре: Җиңүнең 75 еллыгына.** – Казан, 2020. – 276 б. – (25 нче китап).

**Бакый Урманче көндәлекләре: 1965–1976 еллар.** – Казан, 2020. – 218 б. – (26 нчы китап).

**Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар.** – Казан, 2021. – 252 б. – (27 нче китап).

**Шәҗәрәләр. – Казан, 2021.** – 196 б. – (28 нче китап).

**«Утызынчы елларда...»: халык тормышының фаҗигале сәхифәләре.** – Казан, 2022. – 180 б. – (29 нчы китап).

**Милли китапханәнең археографик экспедицияләре: 30 еллык тәҗрибә.** – Казан, 2022. – 250 б. – (30 нчы китап).

**Җәбәли Минһаҗетдин. Тәварихы Болгарийә вә татарийә.** – Казан, 2023. – 234 б. – (31 нче китап).

**Килешү-хокук язмалары (XVIII–XX гасыр башы).** – Казан, 2023. – 224 б. – (32 нче китап).

**Нигъмәтулла Солтанбәков әсәрләре.** – Казан, 2024. – 248 б. – (33 нче китап).

**Раиф Мәрданов. Гарәп хәрефле татар кульязмаларының палеографик үзенчәлекләре.** – Казан, 2024. – 248 б. – (34 нче китап).

**Мөхәммәдьярның «Нуры содур» әсәре.** – Казан, 2025. – 316 б. – (35 нче китап).

# ЭЧТӘЛЕК

БАЙ ИҖАТ ЯДКЯРЛӘРЕ ....................................................3

БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК: МОҢАРЧЫ БИЛГЕСЕЗ БУЛГАН ӘСӘРЛӘР ....................................................19

«Адәм пәйгамбәр кыйссасы» ....................................................19

«Дәрвишләр сохбәтендә» ....................................................54

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК: МОҢАРЧЫ БАСЫЛГАН ТЕКСТЛАРНЫҢ БИЛГЕСЕЗ КҮЧЕРМӘЛӘРЕ ....................................................66

1 нче хикмәт ....................................................69

2 нче хикмәт ....................................................72

3 нче хикмәт ....................................................77

4 нче хикмәт ....................................................79

5 нче хикмәт ....................................................82

16 нчы хикмәт (беренче текст) ....................................................86

16 нчы хикмәт (икенче текст) ....................................................93

17 нче хикмәт ....................................................97

22 нче хикмәт ....................................................100

23 нче хикмәт ....................................................103

25 нче хикмәт ....................................................115

52 нче хикмәт ....................................................121

Ике хикмәтнең кушылмасы ....................................................125

68 нче хикмәт ....................................................131

74 нче хикмәт ....................................................134

78 нче хикмәт ....................................................139

79 нчы хикмәт ....................................................144

ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК: МӘҮЛА КОЛЫЙНЫКЫ БУЛУЛАРЫ ИХТИМАЛ ШИГЫРЬЛӘР ....................................................153

«Мөэмин...» хикмәте ....................................................153

«Рухел-әмин» ....................................................169

«Шәфәгать шәмгыны яндыр...» ....................................................179

ҺӘМДӘМИ МӘСЬӘЛӘСЕ...............................................182

РЕЗЮМЕ.........................................................................210

«ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ» СЕРИЯСЕНДӘ
ЧЫККАН КИТАПЛАР .....................................................212

**ТВОРЧЕСТВО МАВЛЯ КУЛЫЙ:
НОВЫЕ НАХОДКИ**

(на татарском языке)

Ответственный редактор: Ирек Хадиев
Оформление: Ирина Мещанинова

Басарга кул куелды 17. 11. 2025. Форматы 60х84 1/16.
Тиражы 100 данә. Заказ № 506.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420015, Казан шәһәре, Пушкин ур., 86.

Подписано к печати 17. 11. 2025. Формат 60х84 1/16.
Тираж 100 экз. Заказ № 506.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420015, г. Казань, ул. Пушкина, 86.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият бүлегендә басылды.

Отпечатано в редакционно-издательском отделе
Национальной библиотеки Республики Татарстан.

[illegible]

اول زاهید بو احوالنی بیله بیلدی

[illegible] اوزی [illegible]

[illegible] یوسفنی آرزو [illegible]

[illegible] اوزیدین غم زوالی قیلدی

آنگا وحی پیغمبر [illegible] بیلدی

[illegible] یوسف جمالی کورگل [illegible]

[illegible] اول زاهید اول قیلیب

[illegible] اجازه دعا قیلدی اول [illegible]

[illegible]

اول زاهید حق حضرتیغه دعا قیلدی

[illegible] اوزیدین غم [illegible]

اول زاهیدنینگ دعاسی بیر قبول [illegible]

اول زاهیدی مقصود [illegible]

[illegible] عادتی قیلیب سینه [illegible]

یوسف آنده [illegible]

[illegible] طاعت قیلدی [illegible]

یوسفنی [illegible] آرزو [illegible]

[illegible]